Сажидә Сөләйманова

Тормыш, исәнме!





РУХИ ЯНАРЫШ ФОНДЫ
ФОНД ДУХОВНОГО ВОЗРОЖДЕНИЯ
RUHIAT РУХИЯТ
ТАТНЕФТЬ

Сажидә Сөләйманова

Тормыш, исәнме!

Шигырьләр,
поэмалар

Казан
"Рухият" нәшрияты
1998

ББК 84(2Р-Тат)-5
С-74

Басманың мөхәррире
Әдип Маликов

Төзүчеләр
Әнвәр Маликов, Асия Маликова

Җаваплы мөхәррир
Илсөяр Хәйруллина

Әдәби киңәшче
Галимҗан Гыйльманов

Сажидә Сөләйманова
Тормыш, исәнме!

Бу җыентыкка вакытсыз арабыздан киткән күренекле татар шагыйрәсе Сажидә Сөләймановананың төрле елларда ижат ителгән сабырлык, моң, наз белән өретелгән лирикасы, гражданлык пафосы белән сугарылган эпик шигырьләре, җырлары, кайбер поэмалары тупланды.

Издательство "Рухият". Тел.: (8432) 380202. Лицензия № 190

ISBN 5-89706-005-3

© "Рухият" нәшрияты, 1998

Табулар, югалтулар

Мин аны беренче тапкыр 1933 елның җәендә Аксәет авылы клубында очраттым. Сәхнәдә оча-куна биегән сары чәчле нәни кызга гөрләтеп кул чаптылар. Таныш йөзле абый биючене сәхнәдән үрелеп алды да үз янына утыртты.

"Таныш" дигәнем әле кичә генә безне, ягъни яңа укытучы гаиләсен елмаеп каршы алган, әзер йортка урнаштырган авыл советы председателе Сөләйманов булып чыкты. Биюче кызның исеме Сажидә икән.

Сентябрь җиткәч, бер кулына чәчәкләр, икенчесенә сумка тоткан кечкенә буйлы гөрүр кызны мәктәп юлында күрдем.

Физкультура түгәрәгенә йөрүләр... Хәтта мәктәп балалары куйган "Павлик Морозов" пьесасында да бергәләп уйнадык. Бер елдан соң Сажидә юкка чыкты.

Әтиенең якын дустына әйләнгән Гаделша абый Сөләймановны Тәтешле район советы председателе

итеп күтәргәнгәр икән. Иренен матур итеп, сизелер-сизелмәс тырсайта белгән зәңгәр күзле кыз күңелемнең кайсыдыр почмагында посып калды шикелле.

Сажидәнең биографиясеннән: "Мин 1926 елның 3 октябрендә Башкортстанда, Яңавыл станцасында туганмын. Станса янында Йобанай дигән авыл бар. Әнкәм Галимә шул авыл кызы, кышын тимер юл себерүдә эшләгән. Ә әткәй исә Чакмагыш ягыннан килгән "зимагор", тимер юлда грузчик; кара бөдрә чәчле, зәңгәр күзле, ут чәчеп торган егерме биш яшьлек егет. Алар шунда очрашып өйләнешкәнгәр...

Гаделша Сөләйманов – егермебишменче – "Восток" артелен оештыручыларның берсе була...

Мәктәп елларым авылда үтте: Урады, Сарашты, Аксәет, Тәтешле..."

Икенче тапкыр Сажидәне, һич уйламагандакөтмәгәндә, Тәтешле мәктәбендә очраттым. Мин - педучилище тәмамлаган укытучы. Ә ул – алтынчы сыйныф укучысы, алдан икенче рәттә утыра. Шунда ук бер-беребезне танып алдык...

Армиягә китәсе көзем булгач, миңа калдык-постык сәгатьләрне генә бирделәр: җыр дәресе, физкультура...

– Нинди җырлар беләсез, укучылар?

– "Без кабызган утлар"! – диде шаянлыгы йөзеннән чыккан сипкелле малай артқы партадан, – аны этисе кызы Сажидә Сөләйманова башлап җырлый. Ул безнең

староста да. Тәртип бозсак – тибешә-ә...

– Житте сиңа! – диде Сажидә, кыюланып.

Бала чактан истәлек итеп саклаган җиде басмаклы гармуным үзем белән иде. Мин беренче аккорд бирүгә, Сажидә моңлы һәм күтәренке тавыш белән башлап та җибәрде. Аны бөтен сыйныф элеп алды:

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр жилләрдә!

Ә физкультура дәресендә, буе җитмәгәч, мин аны, биленнән тотып, турникка күтәрдем...

Берничә көннән Армиягә китәргә военкоматтан чакыру килде. Тарантасларга төялгән такыр башлы егетләрне бөтен Тәтешле озата чыкты. Аксәеттән әти-әниләр дә кабалана-кабалана килеп җитте. Мәктәп укучылары арасында Сажидә дә бар иде.

Ул, һаваны йомшак кына сыйпаган сыман итеп, кул болгап калды. Миңа булгандыр дип уйладым. 1939 елның көзе иде бу.

Җиде елга сузылган солдат тормышы, хәвефле заманнар. Рәхимсез сугыш... Кайларда гына булсам да, шул "староста" кыз күз алдымнан китмәде...

Сажидә: "... Әткәй, минем өчен, халык эшенә чиксез бирелгән туры, гадел кеше. Сугыш елларының ачы җиле аңа иң беренче булып кагылгандыр... Үземнең мөстәкыйль биографиям кайчан башланды икән?

Әткәй тәэсире, аның халык арасындагы абруе һәрвакыт янәшә бирәндыр, каршылыкларны җиңелрәк үтәргә ярдәм иткәндер...

1944 елда унынчыны тәмамладым, Шулган (Тәтешле районы) мәктәбендә ике ел рус телен укыттым...”

1946 елның җәендә кораллы көчләр сафыннан Аксәеткә, кадерле туганнарым янына кайткач, эти бер арада Сөләймановлар турында сүз чыгарды: “Күрешеп торабыз, – диде, – Гаделша сугыштан бик бетерелеп кайтты...”

Нидер әйтеп бетермәде эти. Шуннан ул Сажидә исемен телгә алды:

– Уфа пединститутына керергә җыена икән...

Ун яшьлек сеңелем Лена да сүзгә кушылды:

– И чибәрлеге аның, абый.

Эни борынын тартып кына куйды. Зурлар сүзенә кысылма, янәсе.

Минем адрес Казанга тутырылган иде шул. Тизрәк шунда ашыктым. Радиокомитетта эшләгән өч елым, ташкын су сыман, акты да китте.

Аннары Мәскәүдәге әдәбият институтында уку. 1950 елда беренче курсны тәмамлап, Язучылар Союзы биргән бер айлык җәзат командировкасыннан соң каникулга кайтканда Оркыяды (Куеда) станцасында мине эти каршы алды. Вагоннан төшүгә үк поездым кузгалып та

китте. Ике генә минут торганын белә идем.

– Китте шул, – диде әти, уфтанган сыман, – Сөләйманов кызы Урал ягына эшкә китте. Институтны тәмамлаган. Яңа адресын сорап алдым...

Их, поезд тагын ике генә минут торса да, – дип уфтанып куйдым мин дә.

Мәскәүдән язган беренче хатыма дустанә җавап килде. "Әдип абый" димәгән, просто "Әдип!" дип башлаган хатын. Шунсына бигрәк тә сөендем.

Ун ай буе ике арада йөргән куанычлы да, кайчагында бәхәсле дә хатлар Мәскәүдә кавыштырды безне.

Сәҗидә: "...Институтны тәмамлагач, Әбъялил районы Аскар авылында башкорт мәктәбендә бер ел тарих укыттым. 1951 елда Әдипкә кияүгә чыгып, Татарстанга килдем. Минзәлдәге Вахитов исемендәге татар урта мәктәбендә дүрт ел тарих укыттым. Укытучыларның комсомол оешмасы секретаре вазыйфасын үтәдем.

1955 елдан без Әлмәттә. Кичке нефть техникумында тарих укытучысы. Партиянең шәһәр комитеты лекторы. Әлмәт радиосының редакторы."

1963 елда беренче шигырь китабым чыкты. Шул ук елдан Язучылар Союзы члены. Еш кына "Ничек яза башладыгыз?" – дигән сорау бирәләр... Әдәби атмосфераның тәэсире булмый калмады..."

Сәҗидәнең шигърияткә килүенә зур этәргеч ясаган

бер вакыйганы мин "Җырлы җир" шигыремдә искә алып үткән идем:

Килде бер мәл Туфан, Сибгат,
Зурлап табын остасын,
Мактый болар Сажидәнең
Кылдай нечкә токмачын.

Мәй урнына — шигырь өеме,
Өстәл тулы кулъязма.
Гажәпсенеп калды Туфан:
— Бу шигырьне кем язган?

"Үз энҗемне эзлим һаман,
Көн туса — йөрим йөдәп...
Ач, шигърият, серләреңне,
Тылсымлы сүзләр өйрәт.

Гөл серләрен тыңлар идем,
Чәчәк атса бер гөлем.
Таңда торып, сандугачтан
Өйрәнимме жыр телен..."

Күп исемнәр арасында
Монсы — исем-имзасыз.
— Ялгыш кергән бу өемгә,—
Ди акланып хужасы.

— Рәхмәт, сеңлем!—
Хәсән абый
Сөя аны куанып.
Китте алар Сажидәнең
Төнге йокысын алып.

Киттеләр
Уллар анасын

Татлы уйларга салып;
Шагыйрьлеккә хөкем итеп,
“Яшә, дип, тоташ янып.”

Сажидәнең чын-чынлап иҗатка бирелүенә Әлмәттәге әдәби хәрәкәтнең дә йогынтысы зур булды. Биредә ул егермеләп шигырь һәм проза китаплары иҗат итте. Русчага тәрҗемә ителгәннәрен Мәскәү нәшриятлары күтәреп алды.

Сажидә: “... Шигырь бер үк вакытта фикергә дә, хискә дә бай булсын... Соңгы елларда үзем өчен тагын бер яңа шагыйрь, димәк, яңа дөнья ачтым. Марина Цветаеваның шигырьләр китабын табып укыдым. Фикер һәм хисне укмаштырган яшен ташы.

Бездә (татарда) хатын-кыз шагыйрьләрне аерым исемлеккә теркәү кагыйдәләшкән... Ә менә Маринаны мин форма һәм фикер бердәмлегенең көче ягыннан хәзерге бик күп ир шагыйрьләрдән өстен куям. Яраткан шагыйрьләреңә ирексездән ияреп була торгандыр. Сибгат Хәкимгә дә, Хәсән Туфанга да ияреп алдым бугай. Аз гына. Гомумән, мин ияреп ягында түгел.”

Радиодагы эшеннән бушагач, Сажидә иҗатка чумды, очрашуларда, әдәбият атналыкларында күп катнашты: Минзәлә яклары, Уфа, Мәскәү, Ленинград, Пермь шәһәрләре, Төмән өлкәсе... Болгария һәм гарәп илләренә сәяхәтләр... Һәркайдан яңа шигырьләр, истәкләкләр, әдәби парчалар ияреп кайта иде. “Әс-сәлами, Суфият!”

повесте дә юлларда туды.

1976-1980 елларда каты авыру хәлендә яшәде. Әмма бирешмәскә тырышты. Беренче катлаулы операциядән соң сәнгать әһелләре, врачлар тормышыннан "Гөлбадран" повестен язарга алынды. Тәмамлап калыйм дип ашыкты ул. Максатына иреште дә.

Аннары соңгы операция...

Нәкъ шул елларда Сәҗидә Сөләйманованың поэзиясе ике тапкыр Тукай бүләгенә тәкъдим ителде. Шигырьләре, җырлары, поэмалары вакытлы матбугатта да, радио, телевидение тапшыруларында да югары бәя алды. Кызганычка каршы, Сәҗидә Сөләйманова кандидатурасы икесендә дә кире кагылды. "Сабыр канатлары" дигән җавап шигырендә мондый юллары бар Сәҗидәнең:

Сабыр канатларым, сабыр канатларым...
Кулым сузып калдым, чапты пар атларым!
Тик ымсынып калдым, кыенсынып калдым,
Сөйгәнемнән гүя нахак талак алдым.

Сәҗидә Сөләйманова намуслы тормышын кешеләр бәхетенә багышлады. Бөтен иҗат байлыгын туган халкына бүләк итеп китте. Шигырьләре күңелләрдән күңелләргә күчеп йөри. Шагыйрь өчен шуннан да зур тагын нинди бүләк бар!

Әдип Маликов
31/III-98ел.

I бүлек

Кыр казлары





Тормыш, исәнме!

Үлән булып җирдә үсәмме мин,
балык булып суда йөзәмме?
Җилләр исә... Төш икән бу дисәм,
өн икәнсең, тормыш,
исәнме!

Бу язда да тагын, бу язда да
Шомырт чәчәкләре иснәдем.
Чәчәк алып килде кем бу дисәм,
Син икәнсең, тормыш, исәнме!

Артта торсын тормыш исәбе дә,
Арта торсын еллар исәбе.
Сахраларга чыксаң, җырлап туймас
Җыр икәнсең, тормыш, исәнме!

Гомер озын дисәм, рас булырмы,
Сиздерми дә узды, дисәмме?
Күп тә түгел, гомер, аз да түгел,
Бер икәнсең, — тормыш, исәнме!

1979.



Кеше

Лачын диләр,
канат кагып горур очканга.
Лачын булсам, җирне сөймәс идем.
Мин — кеше.
Ут шикелле диләр,
кулы тисә — эш яна.
Ут булсам, соң әллә сүнмәс идем? —
Мин — кеше.
Алтын диләр,
бик кирәгем чыкса, куштаннар,
алтын булсам, бер сатылар идем.
Мин - кеше!
Ярага — тоз, арага ут сала
дошманнар,
корыч булсам да бер эрер идем, —
Мин — кеше.

1969.



Бәхет

Дөньяда шатлык нихәтле,
яшәсәң ямен табып!
Су белән кара икмәкнең
ашасаң тәмен табып.

Маңгайга язганын сөртеп,
тир белән суга салам.
Язмышны үзем язам мин,
бәхетне үзем табам.

Шау яфраклы тирәк үсә,
кадасам җиргә таяк.
Бер эндәшсәм карурманга,
ишетәм күпме җавап!

Йөргән жирләрем хикмәтле —
түшәлгән яшел келәм.
Язмышны күрә,
икмәкне
үзем үстерә беләм!

1963.



***

Кеше барыбер кошлар нәселеннән!
Төшләремдә очам кош булып.
Ничә очып, ничә мәтәлсә дә,
кеше барыбер сайлый кош юлын.

Ачылмаган йолдызлары белән
заман һаман үргә чакыра.
Үрләр менми җырлар тумас иде
жирнең матурлыгы хакында.

1967.



Җан атып кайтып килəм

Исəнме, Əлмəт, исəнме!
Җан атып кайтып киләм.
Ни гомер тəбрикләмәдем
хəерле иртəң белəн.

Җилләр иссə, ялкын исеннән
җиксенə идем бер мəл,—
факеллар җилфердəвенең
җегəрен җилгə бирмəм.

Инанган һөнəрем синдə,
уяу үткəн төннəрем,
һəр өйдə миңа сүз биргəн
радио дулкыннарым:

Хəерле иртə!
Хезмəтең
бəрəкəт бирсен һəм дəрт.
Һəр көнең — тирəнлек аша
биеклек яулау, Əлмəт!

Бәхәскә керер агайлар:
— Бик алай түгел, кызым, —
Кайсы көн атнадан озын,
кайсы көн уттан кызу.

Утлардан төтен чыкса да,
ут йотып яшәү әйбәт.
Ялкынлы яшьлегең белән
кабындың жанда, Әлмәт.

Язларым, көзләрем синдә,
сызганып юл сузганым.
Жан атам дулкыннарына:
— Хәерле көн, дусларым!

1977.



Көзләр якты быел

Көзләр якты быел, язлар сыман!
Гел үзенчә ямьле көз яме, —
Сабан туйгамыни җыелганнар
табигатьнең бөтен төсләре.

Ак каеннар сары шәл бөркәнгән,
кызыл чулпы таккан усаклар.
Яшь миләшләр мәрҗәннәрен кигән, —
бәйрәм, туйлар чоры бу чаклар!

Йөзләр якты!
Нурлы кояш төсле
кайнар икмәк бизи өстәлне.
Баллы, майлы мул табыны белән,
ил байлыгы белән көз ямьле.

Дулкын-дулкын иген кырларыннан
амбарларга күчкән арышлар.
...Төсләргә бай, хисләргә бай көздә
әллә нинди генә сагыш бар.

Кызыл төймә таккан яшь миләшләр,
ак алъяпкыч япкан каеннар,
Шәлләренең сары чугын сүтеп,
таралыша Сабан туеннан.

— Язга чаклы! Сау бул! — дигән сыман
чылтыр-чылтыр чулпы тавышы...
Су өстендә казлар тавышы да,
ахры, аерылышу сагышы.

Бай хисләре, ай йөзләре белән
ник көзләрнең ямен азсынам?
Кояш тулы күзләр тирә-ягым,
көзләр якты быел, яз сыман.

1968.



Гел синең белән

Урамнар буш калган,
Йолдызлар сүнгән,
ә яңгыр кыекка
алкалар элгән.
Ялгызым мин бүген
уйларым белән.
Урамның иң аулак
юлларын беләм.

Җил төннең күренмәс
кылларын чиртә,
үзендә күпме көй,
күпме сер йөртә!
Төшенеп серенә,
тыңлыйсы килә,
кушылып, тын гына
җырлыйсы килә.

Омтылса күңелем
җыр булган җиргә,
бу мине онытты,
ташлады димә.

Кайчакта күңелсез
давылсыз, җилсез;
ә җилләр, давыллар
бик шыксыз синсез.

Син китсәң еракка,
моңнарым арта.
Өйләрдә ямансу,
кырларга тарта.
Ялгызым мин бүген
күңелем белән.
Ә күңел син юкта
гел синең белән.

1961.



Туган илгә булган тугрылыкны

Ниләр сөйли, ниләр саный икән,
белсәң иде сәгать телләрен...
Казан, Казан,
сиңа килгән саен
керфек какмый уза төннәрем.

Трамвайларның чыелдавын өзеп,
“Ча-ча-ча” сын узып кичләрнең,
урам бакчасыннан бер көй килә,
бер сын тора тыеп хисләрен.

Йә”Зиләйлүк”, йә “Тәфтиләү” булып,
Казан күкрәгеннән саркыла.
Моңлы сазын уйнап чатта тора,
кемне көтә, кемне чакыра?

Сулыгып-сулыгып Идел дулкыннары
кага булыр уяу җаннарга.
Ярдан-ярга берәү хәбәр сала,
утлар ягып ага салларда.

Караңгыга күзне йомдырмыйча
самолетлар оча төн ярып.
Ир-егетләр дингез-таулар кичә,
канатына алып дөньяны.

Очар күкләр, агар сулар белән
биеклеге илнең, киңлеге
йөрәкләргә бәреп килеп керә,
йөрәкләрнең сынап җирлеген.

Таң яктысы салып күңеленә,
төн карасын алып иңенә,
уяулыкка сакчы Тукай тора
җырлар өстәп вакыт геренә.

Туган илгә булган тугрылыкны
үлчи алмый нинди герләр дә!
"Пар ат" чаба
тугры Тукай җырын
яңгыратырга төрле телләрдә.

Сиңа, Казан, яңа җырчыларны
Тукай тарта, гүя кисәтә:
- Гөлбакчага керсәң, күңел кошы,
и алданма купшы бизәккә,
Һәр мизгеле елның исәптә.

Сулыгып-сулыгып ярга дулкын кага,
сугып-сугып сәгать кисәтә.

1976.



*Аланнарда балан**

Аланнарда балан ак чәчәктә, —
яшь гомернең баллы тәлгәше.
Болыннарга, күңелләргә патша
чәчкә тажы кигән җәй башы.

Җил искәндә, сайрар кош очканда
өскә ява чәчәк тәңкәсе.
Аланнарда балан төймә-төймә,
мөлдерәмә алсу тәлгәше.

Аланнарда балан кызыл тамчы,
ачы бит ул, нигә өзәсең?
Сөнечләренә түзмәсәң дә,
ачысына, күңел, түзәсең.

Аланнарда балан тамчы-тамчы.
Ак чалмалы салкын кыш башы.
Янып тора балан, тамып тора
кышлау кошлар язга чыкканчы.

1976.

---

*З.Мөхәммәтшин музыкасы



***

Мин Зөһрәсе жырның, ә син — Таһир.
Бәет кайда өзелсә дә бәхил.
Сихерләндем күзләренә багып,
юк та иде шуннан олы бәхет.

Ә ул күзләр җир һәм күк йөзендә,
карый елга-күлләр көзгесеннән.
Йолдыз яна төннәр гөмбәзендә,
күзләрендә утлар сүнмәсенгә.

Өзелмәсен, тукталмасын вакыт —
гашыйклыгым шул ук, җырым шаһит —
янам-көям, җирне-күкне багып,
шуннан артык юк та инде бәхет.

1977.



***

Кайчагында кеше сау чагында
сүз куерта үлем хакында.
Үз-үзеңне әгәр сыныйм дисәң,
Син күр аны, бер күр якыннан.

Үлем — көндәш,
жан һәм кан дошманы!
Сизсәң аның синнән узасын —
телгә алмыйсын,
сүз катмыйсың ана,
эчтән янып,
яшерен сызасың.

1976.



***

Сайланып кала чын дуслар,
илдәге жырлар сыман —
югалу-табылуларга,
табынуларга чыдам.

Кичәрмен ташкыннарын да
йә кичүләрен табып.
Калкынып карар артымнан
мина үлчәнгән табут.

Ярларны ярга ялгарга
күпергә калсын нарат.
Кичүләр эзләп китәм мин
яр буйлап яланаяк.

Күпергә агыла халык,
кичүләр кичүче юк.
Кичерәм, китсән, сине дә —
көзге су бозлы, суык.

1976.



Яшь ана

Җанын салган, гүя, беләгенә,
күкрәгенә кыскан күз нурын —
дөньядагы бөтен зиннәтләрнең
иң нәниен һәм дә иң зурын.

Ике бит алмасы сулып калган,
алсулыгын биргән сабыйга.
Ак челтәрне кабат-кабат ача —
минут күрмәсә дә зарыга.

Арнап-баглап өмет-хыялларын,
көн бага да ана, төн бага,
кулларында — илнең киләчәге,
аннан газиз ни бар дөньяда!

1979.

Ә без...

Денсез мулла, надан ишаннарга
агуланган уктай
сүзләр аттың, Тукай.

Гаделлекне яклап, җан атарга
антлар эчтең кат-кат...
Без, ахрысы, тукран.

Безнең җанны кайгырткансың,
Тукай,
атлы бүләк калдыргансың, юкка —
без, ахрысы, куркак.

Һәр тарафта битарафлар арта,
гарип җаннар уза, жыен юха,
ә без, чукрак.

Ә бүләгең, бәлки, түгел юкка —
сикереп менеп атланырга атка,
атылырга чорның күкрәгенә,
синең кебек, Тукай.
Ә без туклар.

1978.



***

Вакыт үзенекен эшли тора,
һәм мин эшли торам вакытка.
Ә ул ерак узып киткәч кенә
үзе узган юлны яктырта.

Яктысында аның минем рәвеш —
үрмәләүме, очу, йөзүме?
Их, вакытны миңа эшләтергә
жир тырмалап жыям түземлек.

1973.



Сөюмени

Юл йөрүме, тузан кунмаса,
каршы җилләр битең кисмәсә.
Кайнарлыгын көннең тоймасаң,
татлылыгын суның сизмәсәң.

Йөзүмени, кинлек кичкәндә
беләкләреңарып-талмаса.
Аргы якны кочып шатлыктан,
яшь үләнгә башың салмасаң.

Күз яшеңнең саф һәм ачысы
йөрәгеңне уеп төшмәсә,
сөюмени,
бәхет каршына
канатланып күңелең очмаса.

1958.



Туган җирем дә түгел

Туган җирем дә түгел,
үскән җирем дә түгел,
Әлмәт, Әлмәт, ник сине
якын итте бу күңел?

Кулга көрәк алдык без,
жил, кояшта яндык без.
Әлмәт дигән шәһәргә
башлап нигез салдык без.

Хезмәт белән зур даны,
ерак балкый утлары.
Бергә булды шатлыгы,
кайгылы минутлары.

Шулай үсте таш кала.
Шунда туды баш бала.
Аның тәүге адымы,
Әлмәт, синнән башлана.
Тәпи баскан туфрагың
жанга якын, яшь кала!

1959.

Унсигез

Унсигез яшь!
Кемнән кичмәгән,
татлы шәраб кемнәр эчмәгән —
дөнья гүзәл,
юллар тип-тигез,
тормыш алда —
бары унсигез!
Ярны сөйсәң —
булсын гомерлек,
берең өчен берең үләрлек.
Сөеп-сүрелеп йөрсә —
ялынма!
Сүрелмәсне ничек танырга?
Унсигез яшь!
Табар эзләгән.
Узган чагын беркем сизмәгән...
Абынганда гүя ястык бар,
хәл алырга, туктап — картлык бар.

Бүген миңа — ике унсигез.
Үткән юллар түгел тип-тигез.
Узгач килә борылып карыйсы,
ал тасмалы кызны таныйсы...

1962.



Елга ага

Ярларына тулып елга ага,
яулыгымны салдым юарга,
яшь киленнәр төшә кер чайкарга,
таң атканда кызлар су ала.
Саф гәрәбә кебек су ага.

Каплар булса юлын карлы бозлар,
ярсына да елга, болгана.
Кар сулары белән җыен чүп-чар
агып төшә язын елгага.
Җир яшәрә, елга болгана.

Тормыш!
Син дә Идел-елга кебек,
ярлар тулса, ярып яңасын,
бозлар туңса, ватып,
кайнап,ярсып,
агасың да һаман агасың,
агым көчен кайдан аласың?

Бу дөньяның әле азмы кере?
Җыйсаң, булыр иде сазлавык.

Саф гәрәбә кебек чишмәләре
ургып чыга тау-таш актарып.
Елга ага һаман сафланып.

Суга төшсәм, чылтырап аккан чишмә
сорый иде: “Сеңелем, ни йомыш?”
Шул чишмәнең саф тамчысы булып
агымына чыгыйм, әй, тормыш!

1963.

*Еллар аркылы**

Еллар уза. Менә тагын бер ел
саубуллашып узды үткәнгә.
Ямансудыр карап калу,
еллар
гомер йомгагыңны сүткәндә.
Ерагая бара йомгак очы,
кечерәя бара йомгагың...
Һаман киләчәккә омтылганга,
гомер җебен үлчәп тормадым.
Юк, ел түгел,
без үзебез үттек
җырлар җырлап еллар аркылы.
Чор — оркестр гүя,
кеше гомере —
әйтерсең лә шуның бер кылы.
Кыл тартылган саен көй югары,
алдан тия жиле, яңгыры.
Кыл өзелсә, еллар чыңлап кала,
кайтавазлар булып яңгырый.
Җыр көчәя һаман, күтәрелә,
алдан тия уты, ялкыны.
Юк, ел түгел,
без үзебез үттек
юллар ярып еллар аркылы.

1965.

*Р.Бикбулатов музыкасы



Ач, шигърият, серләреңне

Үз энҗемне эзлим һаман,
көн туса, йөрим йөдәп...
Ач, шигърият, серләреңне,
тылсымлы сүзләр өйрәт.

Гөл серләрен тыңлар идем,
чәчәк атса бер гөлем.
Танда торып, сандугачтан
өйрәнимме җыр телен?

Боз пәрдәсен умырзая
ничек ача? — күрсәйдең.
Энҗе гөлдән мәңге шиңмәс
такыялар үрсәйдең.

Тау чишмәсе таш эретә,
әллә суы кайнармы, —
шуның серен сорыйм әле
сездән, Урал таулары.

Кем уйламый бер очарга,
йолдызларга юл төбәп.

Уйларымны жырга салам —
яшендәй сүзләр кирәк.

Ташка тисә, таш эресен,
Һич сүрелмәсен йөрәк!
Ач, шигърият, серләреңне.
тылсымлы сүзләр өйрәт.

1960.



Кыр казлары

— Кыйгак-кыйгак, — казлар оча
ерак-ерак илләр аша,
канатларын кагып-кагып,
болытларда юллар ярып.

Кыр казлары, кыр казлары,
матур туган ил язлары!
Күктә уйнап, җырлар җырлап
кайтасыз сез:
— Кыйгак-кыйгак!

Очуыгыз бигрәк күркәм,
авыл өсте чынлап тора.
Җырыгызны яше-карты
юлга чыгып тыңлап тора.
Илләр гизеп, мин дә шулай
исәр идем язгы моңдай —
бик йомшак шул канат кынам,
оча алмыйм, тик талпынам.

Уйларымны белгән сыман,
каңгылдашып баш очымнан

казлар очты:
— Кыйгак-кыйгак!

Идел өсте калды чыңлап:
— Зәңгәр күктә тумадык без,
бәбкә чакта жирдә тордык.
Бик яшь иде канатыбыз,
оча-оча чыныктырдык.
Кичтек без киң диңгезләрне,
күрер өчен бу язларны!
Мине уйга салып китте
кыр казлары, кыр казлары...

1960.



Хатлар язам

Хатлар язам сиңа:
“Сөям, сагынам!”
Мондый сүзләр ләкин хатта юк.
Салкынайта мәллә хат битләрен
көзге жилләр саксыз актарып?..

Кайнар сүзләр юкка үпкәләмә,
укы, иркәм, шуны искәреп:
Сүзләрдән мин бары юллар тездем,
юл арасы тулы хисләрем.

1960.



Умырзая шау чәчәктә

Үзәннәрдә ак кар ята,
яфрак та юк муелда.
Умырзая шау чәчәктә
салкын чишмә буенда.

Чылтыр-чылтыр сулар ага
чәчәкләр уртасыннан.
Ә муел умырзаядан
өлгеләр ота сыман.

Умырзая — язлар гөле —
кар сулары сугарган.
“Гомерең уза заяга”, — дип,
кемнәр юк сүз чыгарган?

Умырзая шау чәчәктә,
ә муеллар бөредә.
Умырзаялары белән
кала язлар күңелдә.

1958.



***

Марс Шабаевка

Без мәжүси түгел,
ни гадәттер
дөрләп янган утка табыну.
Җанга очкын сала
көтмәгәндә
боз өстендә учак кабыну.

Агып бара учак боз салларда,
хәрәкәттә,
юлда,
иректә...
Янып бетә дошманы өстендә,
сүнә,
әмма бозны эретә.

1976.

Дөньяга килде бер кеше

Дөньяга килде бер кеше.
Артты бер гомер.
Зур тормыш аңа үзеннән
бер урын бирер.

Дөньяга туды яшь бала
мең газап аша.
Газаплар бетсен,
син, бала,
кайгысыз яшә.

Салкында сине төрергә
юрган сырганнар.
Тәпи баскач та йөрергә
юллар сузганнар.

Бәхетең артырмы, күренсә
юлның азагы?
Газаплар булсын —
яңаны
эзләү
газабы.

1957.



***

Колачлап инләдем*
Агыйдел суларын.
Әллә син килмәдең,
әллә мин соңладым...

Дулкыннар кагалар
бер ярдан бер ярга.
Безнең дә аралар
охшаган шуларга.

Юлларда җилләрдән
җырларың ишеттем.
Әллә мин ашыктым,
әллә син кичектең?

1959.

*Ф.Галәмиев музыкасы.



Су буенда шәфәкъ алы

Ике авыл уртасында
елга ага талгынга.
Ярдан ярга басма салдың
килер өчен яныма.

Су буенда шәфәкъ алы
ялганды таң алына.
Безне күрде алсу таң да
ярда бөдрә тал гына.

Җәйләр үтте, көзләр җитте —
Басмабыз агып китте.
Басмалардан чыккач, юлың
кайларга алып китте?

Мин дә үттем күперләрнең
чуенын, тимерләрен;
нигәдер, инеш басмасын
юксынды күңелләрем.

1959.

Чишмә

Илһам Шакировка

Үтелмәгән нинди юллары бар,—
ургый-ургый чишмә ага...
Сагынып, сусап көткән ал иреннәр
ерактарда, ерак ярда.

Ачылмаган нинди серләре бар, —
чылтыр-чылтыр чишмә ага...
Тау астыннан асылташлар җыйган, —
һәр ташыннан көмеш тама.

Җырланмаган нинди җырлары бар, —
уелып-уелып чишмә ага...
Бөгелеп кенә, сыгылып таллар тала,
су бир,
сулыгып йөрәк яна!

Ургый да гына ургый,
җырлый-җырлый
чишмә ага.

1960.



Эзләреңне саклый һәр буразна

Әткәй истәлегенә

Урман буе яшел аланлыкта
гөлләр үскән инде кай ара.
Күптәнме соң, кулларымнан тотып
өйрәтүең печән чабарга.

«Өздереп чап, чалгың уйнап торсын,
такыр калсын покос арасы.» —
Алдан киттең чыклы болын буйлап,
яшел сукмак салып барасың.

Очкынлатып чалгы янаганда
хәтерләдең яшьлек елларын.
Кылыч белән ерып үткәнсез сез
покосларга кайту юлларын.

Сүз озайтмый идең үз хакында,
әллә вакытың бик аз булдымы;
кара рамда рәсмең төшкән хәбәр
сөйләп бирде тормыш юлыңны.

Яшен кебек сукты һәрбер сүзе,
хәтеремдә мәңге калсын дип —
элек батрак булган,
аннан эшче.
Егермебишменче.
Большевик.

Сәнәкчеләр сине кыйнаганнар...
— Үләр диеп дошман көтмәсен! —
Канлы күлмәгеңне байрак итеп
колхоз кырларына киткәнсең.

Ак каеннар, әнә, хәйран калып,
шуны сөйли булыр җилләргә.
Эзләреңне саклый һәр буразна,
кырны инләп бодай тирбәлә...

1960.



Үкенмимен

Тау артында зәңгәр болыт
бер килеп явар төсле.
Тауга менсәм, бу күңелем
юаныч табар төсле.

Тау башлары ай-һай биек,
тау буе карамалык.
Нигә, дустым, үзең менгәч,
әйләнеп карамадың?

Тау башында түгәрәк күл,
йөрмәдек түгәрәкләп...
Үкенмимен, сиңа карап
тау кичтем, шуңа рәхмәт.

1961.



***

Караңгылар алай кара түгел,—
айлар батса, чулпан калкасы.
Күк йөзендә бер мәл пәйда була
Сызылып кына төшкән Ай кашы.

Йөзкәенә зәңгәр пәрдә япкан.
Ачылмаган әле керфекләр.
Ай кашына шунда гашыйк булды,
таңга калып янды офыклар.

Офыклардан әллә көнләшепме,
уятырга килде Кояшы.
Күк йөзеннән нурлар булып тамды
сызылып кына төшкән Ай кашы.

1967.



Кечкенә йорт бар тайгада

Бер йорт бар ерак Себердә, —
бүрәнәсе ак нараттан.
Башын бераз аска иеп,
гүя тирән уйга баткан.

Туктала да карый шуңа
юлы төшеп узган-барган.
Иске үзе, ә шулай да
горур мәрмәр сарайлардан.

Нәфрәт атып таш тәхеткә,
декабристлар салган аны:
«Тимер богау зыңлавына
бер уяныр сөрген ягы...»

Лачын туа очар өчен,
богаулатмас канатларын.
Баш игәннәр батырларга
кыргый себер наратлары.

1962.

Бүген монда сәер бер тынлык

Чапкан печән инде җыелган,
кызлар киткән урман буеннан.
Бар да тынган. Шаян җилләр дә
кибәннәргә килеп сыенган.

Бүген монда сәер бер тынлык —
кичен черки куган төтен юк.
Ике таган калган тырпаеп,
учак тирәсендә беркем юк.

Ә кибәннәр, гүя, үрелеп
колак сала ерак гармунга.
— Тальян гармун, китмә, кал монда,
иртә-кичләр моңга бай монда.
Күләгә бар кибән төбендә,
суынмаган учак көле дә.

Тып-тын калып тынлый болыннар: —
ерагайган гармун көендә
сызылып китә чалгы чынлавы,
сузып кына кызлар җырлавы,
чагыла ярсып учак дөрләве,
Туган якның айлы төннәре...

1962.

***

Бер исә җил, бер тына,
күк йөзе болыт кына.
Болытлар кичәр идем
искән җил булып кына.

Җил исә дә гел исә,
агыла болытлары,
тагыла болытлары...
Үтәргә иде ары.

Болытлар алып килсәм
Күгеңә синең, иркәм,
япма тәрәзәң иртән,
Болытлар белән килсәм.

Яшенле яңгыр кирәк, —
таралсын кара болыт.
Кавышсын ике йөрәк,
яшенле чаткы булып.

Карасаң тәрәз ачып
җил-яшен тынгач кына, —
табарсың яшен ташын
суынгач, сулгач кына.

1962.



Ай юлы

Диңгезгә төшкән ай нуры...
Жырлаган күпләр мактап.
Диңгезгә төшкән ай юлы, —
китәсе килә атлап.

Йөзәләр икәү шул юлдан,
йөзәләр кыз да егет.
Ай төшеп диңгез читенә,
үзенә алыр кебек.

Тирбәлә диңгез, тирбәлә,
айкала да чайкала.
Йөзәсе иде, һай, ерак, —
Үз ярларым жәл кала.

1962.



Диңгез ярында

Таң нурлары төшә,
вак дулкыннар
җемелдәшә...
Диңгез, синсез
ничек яшәгәнмен
бүгенгәчә.
Рәхәт
дулкыннарда чалкан ятып
күк гизүе.
Йөрәкнең дә була
ялга талган
бер мизгеле.
Нинди матур дөнья,
нинди тыныч
җир-күгендә!
Кояш бата.
Ай нурлары
кызлар керфегендә...
Күкне җирдән аерып,
кинәт кара болыт ятты.

Дулкын ярдан купты,
болытларга
ташлар атты.
Төне буе
диңгез шавы изде
төш аралаш.
Мин уяндым,
тәрәз атлап
тәүге нур карагач,
Юеш комнан
авыр атлап
ике солдат
бара
Арган дулкын
солдат итегенә
башын сала.

1962.

Поезд бара

Поезд бара,
поезд бара.
Кара диңгез
кала,кала...

Омтылгандай
хушлашырга,
дулкыннары
ярга кага.

Поезд бара,
таулар яра.
Кыя ташлар
кыелып кала.

Алда дала,
янда дала.
Көнбагышлар
көнгә бага.

Күмер таулар
кинәт калка.
Тау-тау байлык
илдә арта.
Поезд илтә
кемне кая —
кемдер бара,
кемдер кайта.

Көн дә, төн дә
тормыш бара,
әй, юлаучы,
йоклап калма!

Юллар чаба,
сулар ага,
якыная
ерак ара.

Ике якта
миләш, балан.
Хушыгыз, хуш,
пальма, банан!
Башка диңгез
дулкынлана —
бодайлар
баш иеп кала.

Манаралар
ераклардан
үрелеп карап
каршы ала.
Тәгәрмәчләр
жырлап бара —
бәхетне кем
кайдан таба.

1962.



Сынау

Сынау бара кичке техникумда.
Ямьле җәйнең эссе бер көне.
Фикерләрдән әллә бүлмә кысан,
әллә һава шулай бөркүме?
Башын тотып егет уйга чумган —
тарих куйган җитди сораулар.
Берәүләргә шактый җиңел сыман
тәүлек буе җирне бораулау.
Кемнәр борау, кемнәр сорау белән
эзли, таба,
тагын эзләнә.
Сынау бара.
Кеше үз гомерен
салып үлчи тарих-бизмәнгә.
Җавап бирә Гайсин.
Йөзе йончу.
Йокламаган төнге йокысын.
Кем юраган аңа, чәч агарткач,
сабый кебек сабак укыйсын!
Идел буендагы канлы сугыш...
Белми икән моны кем генә.
«Фактларга тарих шундый бай ул,

сөйләр өчен булсын тел генә», —
дия иде безнең бер студент.
Тел тегермән түгел Гайсинда.
Йөрәгеннән гүя суырып ала
сүзләренең бүген барсын да.
Идел буендагы канлы сугыш...
Тезми Гайсин дата, саннарны.
Бармаклары курок тоткан килеш,
ә уң күзе
дошманына төбәлеп калганын
бүген күрдем.
Ә мин сынау алам.
Тормыш,
хаклык монда бармы соң —
егерме ел элек егет үткән
бу сынауның утлы, канлысын.
Вуз ишеген миңа ачып биргән,
Берлиннарның ватып капкасын.
Кайгысыннан кара янып-көеп,
жире көткән.
Белгән кайтасын.
Көтеп алган ятим, ишле гаилә,
ачык яраларын ямарга.
Вакыт яңа тигән
өзелеп калган
фән жепләрен жыеп ялгарга.
Кылган эше аны алып чыгар
сынау түгел, сират күпердән!
Сөйли Гайсин.

Үткән-күргәннәрне
тарих битләренә күчергән.
Кылыч чыңы сугыш уены сыман
ишетелә безнең елларда.
Ә бит туры килде
бензин салган
шешә тотып яуга чыгарга.
Дошман утларыннан шешә шартлый,
ялкын ала солдат гәүдәсен...
Чыра кебек чыртлап
янып бетсәң,
шундамыни яшәү мәгънәсе?
Ярсып-ярсып солдат алга ыргый,
ядрә эри шушы ялкыннан!
Идел кайнап тора.
Җирдә корым кала
Улап сүнгән дошман танкыннан.

Бәхетне шул тәлинкәгә салып
китермиләр бәйрәм киченде.
Утлы сынау булды
иле белән
бер үк утта янган кешегә.
Ә мин сынау алам.
Гаеп итмә,
окопларда бергә янмадым.
«Без җиңәрбез!» —
Моның ни хакына
үтәлгәнен соңрак аңладым.

Күпшы сүзләр...
Күптән күңелем кайтты.
Укытучы өчен эш — яну.
Бәхәсләргә, көрәшләргә атты
бөек эшкә чиксез ышану.
Тик янмаска коры чыра булып,
эремәскә матур вәгазьдә.
Гади солдат!
Синең вөждан аша
чыныгу алам кызган бәхәстә.
Сынау бара.
Төрле караш белән
безгә бага бүген бар дөнья.
Синең вөждан,
минем вөждан эше
сынау үтә кешелек алдында.

1962.



***

Галәмдә иң көчле — кеше хисе! —
хыял йолдызын тотып карар өчен
акылны җигеп, жиңдек Җирнең
түбәнгә тарту көчен.

1968.



*Без йөргән юлларда**

(Нефтьче җыры)

Иртәнге ай йөзә,
Аксыл юллар алда.
Басу-кырлар ялда.

Кушымта: Иртәнге җилләрдә
Мин чыгам кырларга
Җирнең сулышын тыңларга.

Тирәннән яктыга
Кара елга ага.
Без менгән үрләрдә
Кайнар эзләр кала.

Кушымта: Иртәнге җилләрдә
Мин чыгам кырларга
Нурлар өстәргә юлларга.

Без йөргән юлларда
Алтын фонтан ата.

Без булган җирләрдә
Матур җырлар арта.

Кушымта: Иртәнге җилләрдә
Мин чыгам кырларга
Дуслар шатлыгын җырларга.

*Р.Яхин музыкасы.



*Бәйрәм вальсы**

Туй күлмәге кигән авыл-шәһәрләр.
Алсу-зәңгәр дөнья, сихри аһәңнәр.
Ымсындыра серле көйләр тылсымы,
Буйсындыра биюченең буй-сыны.

Җилдән җиңел оча күңел, җилкенә.
Тирбәләбез назлы җилләр иркендә.
Тирәбездә ай-йолдызлар әйләнә.
Ай юлында эзләр эзгә бәйләнә.

Урау-урау гашыйклар урамы.
Бөтерелә хәйран моңнар бураны.
Бөтерелә, дәрт-ямь өсти бәйрәмгә,
Безнең белән җир шары да әйләнә.

*Р.Яхин музыкасы.

II бүлек

Ни белән үлгәнә үткән гомер





Җирдәшләр

Кешеләрне дус һәм туган иткән
олы бер хис — күңел көзгесе.
Авылдашың әйбәт кеше булса,
мактанасың:
— Минем дус кеше.

Газет-журналларны актарганда,
эшләреңнән бераз арынгач,
тукталасың таныш бер рәсемгә:
— Герой, герой!
Минем райондаш!
Турнир барса бөтен ил буенча,
шунда гына була бар хәстәр:
— Нәҗметдинов тагын «мат» чәпәде!
Сынатмыйлар безнең кардәшләр!

Космонавтлар күктә.
Тетрәп китә
читтә яшәп чәче бәсәргән.
Сулган сыны турайгандай итә:
— Минем ватандашым!
Рәсәйдән!

Дус-туганлык хисе кешеләрнең
күзен ачкан гомер-гомергә.
Авыллар күп,
        илләр, калалар күп,
Ә җир шары бары бер генә.
Шул мөкатдәс җирнең бер баласы,
сабыйларның
бер анасы булып
        мин дәшәм:
— Йолып калыйк Җирне утмәхшәрдән,
әй кешеләр,
        без бит — җирдәшләр!

1966.



***

Актарылып, айкалыплар,
нигә соң күңел тулмый,
хәсрәтемнең бар ачысын
яшь итеп җылап булмый,

таш булып төшкән, утырган
кемнәндер каргышымы?
Әллә соң дуслар, туганнар,
якыннар кайгысымы?

Барысын җыеп бәгырьгә,
их, мин эретә алсам!
Илдә калдырмый шуларны,
алыплар китә алсам...

1979.



Юлларга чыксаң

Мамык кар төшеп тора,
йомшак җил исеп тора.
Ак шәлең болгап, каен,
ак юллар миңа юра.

Көн иткән йортым-курам...
Озата чыга урам.
Сез ачык капка белән
көтәрсез мине, беләм.

Чыгам мин атлап кына,
кышкы юл ап-ак кына.
Колачын җәйгән дала,
җилләре каршы ала.

Җилләре ачы, кырыс.
Күңелем, булма тыныч,
нинди тын иде урам...
Юлларга чыксаң — буран.

1963.



Машинада атлар

Кара тасма юл сузылган,
ике якта ак кар.
Машиналар узышалар,
машинада атлар...

Җирән кашка моңсу гына
карап бара юлга.
Дан казанган мәйданнарын
кайда, кара юрга?

Көмеш дага ялтыратып
юртыр гына чаклар...
Җилдәй очкан машинага
төялгәннәр атлар.

Дилбегәдән рульгә күчте
егетләрнең кулы.
Мәйдан түгел,
галәм гизеп
үтә батыр юлы.

Юл ташларын ат ташыды,
таныш һәрбер чаты —
кара көздә тездән батып,
чыгалмыйча ятты.

Пар кыңгырау чылтыратып
юртыр гына чаклар...
Машиналар чаба юлдан,
машинада — атлар.

1963.



Иртәнге җилләрдә

Иртәнге ай йөзә,
аксыл юллар алда.
Ак юрган астында
басу-кырлар ялда.

Атлыйсың сак кына —
йокламый Җир-ана.
Тирәннән яктыга
кара елга ага.

Иртәнге җилләрдә
мин чыгам кырларга,
җирнең сулышын, йөрәк
тибешен тыңларга.

Без йөргән юлларда
алтын фонтан ата.
Без булган җирләрдә
якты нурлар арта.

Кыш уза, яз житә,
уҗымнар уяна.

Урманга җыр кайта,
тургайлар куана.

Чык төшә юлларга,
мин чыгам кырларга,
җирнең сулышын, йөрәк
тибешен тыңларга.

Иртәнге җилләрдә
бодай дулкынлана.
Үзенә чакыра,
төнге утлар яна.

Без йөргән җирләрдә
кайнар эзләр кала.
Кул тисә җиремә —
кулдан алтын тама.

Таң нуры юлларда,
мин чыгам кырларга
Җирнең сулышын, йөрәк
тибешен тыңларга.

1963.



Кыш үтмәгән әле

Кыш үтмәгән әле,
йомшак җилләр
яз хисләрен инде уята.
Алтын көзге белән ирештерә,
кояш көлеп карап куя да.

Тау түбәсе ап-ак тунын салган,
бер елмаеп кояш назлауга.
Кырлар исә
яшел ужымнарын
ябып саклый —
әле яз алда.

1963.

*Күзләрендә**

Син әйтмәдең, ә мин сизми йөрдем,
яшертенме,
йә син түземме? —
Тутырып карау белән
күзләреңнең
иң түрендә күрдем... үземне.

Күзләрендә синең диңгез төсе,
диңгез холкы —
ярсый, карая.
Ә кайчакта ярларыннан ташып,
дулкын бәреп керә арага.

Башым куеп дулкын уңаена,
агыймммы соң, каршы йөзимме?
Ә каршыңа бассам,
күзләреңнең
иң түрендә күрәм үземне.

1963.

*Р.Бикбулатов музыкасы.

Киек казлар китә

Киек казлар китә, көзләр җитсә,
киек казлар китә каңгылдап.
Ерак юлда сезне саклар идем,
каплар идем җилдән, яңгырдан.

Сызылып кына зәңгәр юллар кала,
ил чикләре сезгә чик түгел.
Ят күзләрдән көнлим, киек казлар,
ник чит җирләр сезгә чит түгел?

Яулык болгап калам сез киткәндә,
киек казлар, тагын кайтыгыз.
Каршы алса дуслар ерак илдә,
канат кагып сәлам әйтегез.

Көн яктысы кунган ак канаткай
яктылары төшсен төннәргә.
Кагынганда агым суларымның
тамчылары төшсен чүлләргә.

Сәлам алып каурый очларында,
яз кайтырсыз, диңгез чик түгел.
Чиксез илләр, уртак телләр табу —
безгә дә бит, дуслар, чит түгел.

1963.



***

Нәнәй истәлегенә

Уйласаң уй,
жырласаң жыр,
тыңласаң гел моң гына.
Солы уралар соң гына, —
кырда ялгыз тол гына.

Балачактан,
алачыктан —
тавыш-тынсыз
тыныш йөз...

Энҗер төшә,
өйрә пешә.
Күрше-күләп, —
күреш, уз.

Кемнәр киткән,
кемнәр кайткан —
кала-капка,
ят койма.

Дүрт ягым кыйбла димәгез,
бер генә була кыйбла.

Түр тәрәзәдә ак сөлге,
чиккәне, каеганы.
Кызыл чукларда —
кояшның
чыкканы, баеганы.

Киткәнгәме —
көткәннәргә
кыенга килә дөнья.
Нигез ташыңны ташламау —
электән килгән йола.

— Утырышыгыз, оланнар...
Алга сөлге сузыла.
Уйласаң уй,
җырласаң җыр,
тыңласаң моң сызыла.

1970.

---

*Нәнәй - дәү әни, әби (диалект).



***

— Тиз кайт, әни,— диеп калса бала,
сабый белән булыр ана жаны.
Санап торыр күрешү араларын
сәгать саны түгел, минут саны.

— Хат яз, балам,— диеп калыр ана,
улы китәр ерак юллар белән.
Санар аннан күрешү араларын
айлар белән түгел, еллар белән.

1963.



***

Куанасың сабый бала төсле,
гел җырлыйсы килә, көләсе.
Моңаясың, әллә сагышың көчле,
уйларыңны килә беләсе.

Фикерләреңә, бәлки, төрле дәдер,
күңелендә бармы бер генә?
Беләмен дә төсле, күрәмен дә,—
бик үз дә син, артык серле дә.

Чәчләреңне жилләр тараганда,
күңелләреңә кая талпына?
Күзләремә туры караганда,
ерак та син, чиксез якын да.

1964.



*Җырчы дустыма**

Венера Шәриповага.

Ике күзең, ике күзең утлы күмер,
бер карасаң, ничә күзләр кабына.
Күз сирпесәң, ничә йөрәк, ничә күңел
өметләнәп, канатланып кагына.

Җыр башласаң, болыннарга, тугайларга,
сахраларга әйди көмеш кыңгырау.
Китәсе лә бергә, борылып карамый да!
Ә күңелдә, ә күңелдә бер сорау:
Җырга ияреп, дулкыннарга төшеп чумсам,
гел янармы, йә сүнәрме бу дөрләү?
Сүнмәгән дә, күмер булып көймәгән дә,
яннарында нигә соң юк тик берәү?

Ике күзең, ике күзең якты йолдыз,
сүндерәдер бик күпләрнең кайгысын.
Таң белән таң очрашалмый,
кавышалмый...
әллә шуңа узең һаман ялгыз син.

Китәсе лә иде бергә ерақларга,
ерақларга әйди көмеш кыңгырау...
Сагынырсың да, әйләнерсең дә карарсың —
өметләнеп калганнар күп,
син берәү.
Шуны сөйләп чыңлый көмеш кыңгырау.

1964.

*Р.Яхин музыкасы.



Хәерле сәфәрләр

Урманнар, болыннар,
мәһабәт чыршылар...
Юлларда онтыла
мәшәкать-борчулар.

Бу җитез каеннар
кая гел йөгерә?
Кич була, ай чыга,
вагонга төн керә.

Шуышып төн керә,
моңая җырчылар.
Мәхәббәт турында
көй яз да жыр чыгар.

Тылсымлы аһәңнәр
жилкетте гомергә.
Сагышлы көй белән
кермә син күңелгә.

Йөрәкнең иң нечкә
кылына кагылма.

Һәй, гореф-гадәтләр
бик кырыс авылда.

Сездәге жыр-уен,
чамасыз ярамый.
Бу төннәр алдаучан
томандай таралыр.

Жыр-уен — сезгә эш.
Эшнең бар төрлесе.
Ә мине көтәдер
жир эше, тир эше.

Жырлыйлар жырчылар:
"Жилләрдә гөл сынар..."
Кем сынар, кем чыдар —
туасы көн сынар.

Паровоз ыргыла
төтеннәр төтәтеп.
Ашыга вагоннар:
— Көтәдер, көтәдер...

И, туган якларның
ник якын жир-суы?!
Үрелгән пар толым —
шатлыгы, борчуы.

Иелә-бөгелә
каршылый арышлар.
Ә сез бит биредә
тик узып барышлый.

Хәерле сәфәрләр!
Бу минем тукталыш.
Ә йөрәк ник янмас: —
көтәдер уттай эш.

Мәхәббәт турында
жырлыйлар жырчылар.
Юлларда онтыла
мәшәкать-борчулар...

1964.



Янә килдем Минзәләгә

Минзәлә юллары такыр, диләр...
Такырлыгы чынмы, түгелме —
шул юллары менә ничә еллар
һаман тартып торды күңелне.

Минзәләдә ярлар матур, диләр...
Ялгыз кеше ансын карасын.
Койрык кагып чапкан грузовойда
Чаллы белән Минзәлә арасын
кайчандыр бер очып үткән идек,
түмгәкләре саен
бер-беребезгә ныграк сыенып,
юлда җыелып яткан кар суының
биткә чәчрәвенә сөенеп.

Бездән дә бай кеше булмагандыр —
икебезгә ике чемодан...
Агач өйдән нәни бүлмә алгач,
шатлык ашкан иде чамадан.
Ашау өстәле дә шул чемодан.
язу өстәле дә чемодан.
Гел шатлыгы истә.

Борчулары
сүзсез генә әллә йотылган.
Сыңар чиләк тотып, иртә таңнан
суга чират тору онтылган.
Гел шатлыгы калган. Язлар саен
мәктәп кичәләре хәтердә.
Ун ел элек унны бетергәннәр
унҗидедә кебек хәзер дә.

Минзәләдә юллар такыр, диләр...
Бәхетләләр өчен такыр ул.
Минзәләдә ярлар матур, диләр...
Сөя белгән өчен матур ул.

Сикәлтәле сиртмә юлларыннан
оча-оча килдем мин янә!
Бәхет кошым әллә бер каурыен
синдә калдырганмы, Минзәлә?

1964.



Безнең яшьлек җырлары

Без яшь идек, баш имәдек,
җыласак та җырладык.
Окопларда һәм утларда
туды яшьлек җырлары.

Без яшь идек, яшермәдек
илдән күңел серләрен, —
үзәкләрне өзелдереп
туды яшьлек җырлары.

Без яшь идек, аш димәдек,
эш дип яндык, юл ярдык.
Калалар салды, дан алды
безнең яшьлек җырлары.

Без яшәдек һәм яшәрбез
яңгыратып елларны.
Яңа яшьләрдә яшәрә
безнең яшьлек җырлары.

1976.

Саубуллашу вальсы[*]

Ак алъяпкычларда ак канат,
күңел оча, гүя акчарлак.
Ак канат иңнәрдә,
жилферди жилләрдә,
күңел оча ерак жирләргә.

Аерылыр чак житә, дусларым,
сизелмәде ун ел узганы.
Хуш, мәктәп, үз күрдең,
яшәргә көч бирдең,
канат куеп безне үстердең.

Алда юллар, кайсын сайларга,
юллар чакыра әллә кайларга:
океаннар айкарга,
очарга айларга,
тормыш дәрьясында кайнарга...

Алъяпкычың, дустым, ак икән,
ак булса да, салыр чак житкән.
Хыяллар ак жилкән,
кузгалырбыз иртән,
ерак юлга чыгар чак житкән.

1964.

[*] М.Имашев музыкасы



***

Болыннарда сихри бер ямь.
Такыялар үреп киям.
Чәчкә кадыйм чәчләремә —
бөтен дөнья чәчкә генә.

Йомшак кына җилләр исә.
Яфрагына җилләр тисә,
ак энҗеләр сибә шомырт.
Бу табигать нинди юмарт!

И былбылым, сандугачым,
бармы сайрап туяр чагың?
Гүзәллектән эри җаным,
бармы, башым, уяу сагың?

Ак күбәләк тибрәп оча,
чык суларын гөлдән эчә.
Дөнья аңа гөлгенәдәй,
гомере ләкин бер генә җәй.

Гөлләр сыйпап узыйм дисәм,

4. Я-547

кулларымны чәнчә билчән.
Былбыл таушын тыңлап йөрсәм,
бәбкәләрне аулый тилгән.

Сөендерә язгы тамчы,
сискәндерә яшен-камчы.
Ә син сайра, сандугачым,
күңел — былбыл,
йөрәк — лачын.

1964.

***

Ак конвертта адрес —
Казан.
Күк конвертта адрес —
Казан.
Казан, Казан,
сиңа язам.
Язам, бозам,
сызам-язам.
Язам —
килсә бәла-каза,
сиңа язам —
шатлык артса.
Эндәшмичә калсаң,
Казан,
шуннан авыр булмас
җәзаң.
Жырлар язам сиңа, Казан, —
түгел синдә жырлар аздан.
Казанында кайнат, Казан,
Иделеңдә айкат яздан.
Жырлап акса,
дөрләп янса,
димәк, яшим,
нурлы Казан!

1964.



***

Кичке шәфәкъ.
Яна офык.
Күктә төрле төсләр.
Бик ямьле дә
һәм моңлы да
шушы җәйге кичләр.
Үрмә гөлкәй үрли, әнә,
ал нурларга сузыла.
Көн ачылды,
Якты көнкәй,
узма әле, узма.
Үткәрмәдем көн кайнарын
изрәп, үрмә гөлдәй.
Саклап йөрдем таң нурларын
күңел түрләремдә.
Офыкларда шәфәкъ нуры,
балкый барча төсләр!
Нигә моңсу була икән
шушы җәйге кичләр...

1964.



***

Көн эссе.
Су өсте нәкъ көзге.
Күктән нур коела.
Таң белән уянган күп төсләр
жуела, жуела.
Бик иртә чык кипкән.
Күзләрем
камаша яктыга.
Баш иеп миләүшә берәүне
озаткан вахтага.
Ай күргән эзләрне, и кояш,
чык белән алдыңмы?
Таң белән уянган төсләрне
оталмый калдыммы?

1964.

***

Чәчәкләр аланда,
чәчәкләр болында,
ак канат ромашка
гашыйклар кулында.

— Ярата, яратмый,
яратмый, ярата...
Өметле карашлар
иң соңгы канатта.

Сөяме, сөймиме,
сөяме, сөймиме...
Сөйгәне әйтмәгән
сүзне гөл сөйлиме?

— Ярата, яратмый,
ярата, яратмый...
Никадәр чәчәкләр
өзелгән канатлы.

Чәчәкләр кырларда,
чәчәкләр юлларда.
Табышкан, кавышкан
күп икән дөньяда.

1964.



Җырланмаган җырлар

(цикл)

Саргаеп көйгәнне,
сөюдән үлгәнне
сөйлиләр борынгы бәетләр.
Янсаң да, көймә син,
саргаеп сөймә син,
замана гаепләр.

Үткәнгә иярмә.
Заманны иярлә,—
чабышта чыныксын йөрәгең.
Юлчылар юл алыр,
моңлыга җыр калыр,—
кирәкле һөнәрен.

Ә җыр бит күтәрә.
Авыр юл үткәндә
дәртле җыр һәрвакыт иң алда.
Ул ялгыз калдырмас,
арытмас, талдырмас, —
сагышлы җырларга инанма.

Тик менә һаман да
Бу яңа заманда
кешедә сагыш бар, кайгы бар.
Күңелләр көр була,
максатлар бер була,
ә юллар нигәдер аерыла.

Йолалар искерә,
тик менә хис кенә
һаман шул — буйсынмый, тузына.
Диңгезләр кушыла,
айга юл сузыла.
Ә күңел дигәнең өзелә, сызыла.

Күкләрне күкрәтә,
тауларны тетрәтә
очканда очрашкан жисемнәр.
Нидә соң кодрәте?—
Күпләрне тетрәтә
янәшә жырланган исемнәр.

Мин дә жыр тыңладым.
Йокысыз төннәрем
таң белән тоташты, сизмәдем,
Ишеткәч түзмәдем,
иясен эзләдем
күңелне кузгаткан сүзләрнең.

Эзләгән тиз табар,
күңел бит — эзтабар,
бушлыкка чыдамый бик озак.
Бер тынса, бер тула,
жыр булып ургыла,
ә жырга юк йозак.

Бәлки ул яңгырамас,—
кайда көз, кайда яз.
Эресен күңелләр юшкыны.
Яңарыр, онытылмас,
йөрәккә һәрчак хас
омтылу, ашкыну.

...

Тәңкә карлар,
алка карлар,
ап-ак карлар ява.
Җәйләр,
көзләр,
йөргән эзләр
кар астында кала.
Кара күзе,
сабыр йөзе,
әллә үзе якын.
Карлар ява,
карлар ява,
ә йөрәктә ялкын.
Йолдыз карлар һавалардан
ңигә төшә җиргә?
...Күрми торсам,
онытыр идем,—
төшләремә керә.
Күктән йолдыз яудыралган
сөю бар, ди,
чындыр.
Салкын кышта
яндыралгач,
гыйшык уты шулдыр.

...

Яр тулып бозлар акканда
нигәдер күңел тула.
Елыйсы килгән чакларда
җырласаң җиңел була.

Тамчылар тама, таш яра,
Ирешә теләгенә.
Күз яше эзләр уялмас
берәүнең йөрәгенә.

Ә күктә кояш елмая,
урамнар дәрья төсле.
Яз быел матур килә бит, —
кешеләр көләч йөзле.

"Чык-чык" дип килә чыпчыклар
Тәрәзәм турысына.
Каршылыйм таңны сөялеп
тәрәзә борысына.

Сыерчык килгәнен көтәм,
күңелемне аңлар иде.
Барыр да аның каршына,
талпынып сайрар иде.

Сыерчык теленә салып
җибәрсәм сагышымны,
ул да бер моңланыр иде,
ишетеп тавышымны.

Сәламен, бәлки, җибәрер
жырчы кош канатында...
Сыерчык килгәнен көтәм,
күңелемне аңлатырга.

...

Күзләреңнән нурлар агылганда,
керфекләрең ничек талмый соң?
Син карыйсың миңа, гел карыйсың,
әйтер сүзең әллә бармы соң?
Син карыйсын үзең,
керфекләрең
серләреңне жыя, яшерә.
Син яшермә инде,
әйт, яшермә,
сүз табалмыйм башлап дәшәргә.
Көн дә йөргән юлларына чыгам,
дәва эзлим йөрәк сызлауга.
Син кызганма инде,
һич кызганма,
күз нурыңны сирпе узганда.
Күзләрендә, ахры, тылсым бардыр,—
сине күрми бер көн түзалмыйм.
Мин эзләмим сине,
юк, эзләмим,
эзләреңнән генә күз алмыйм.

...

Иртәрәк килмәдең,
и ләйсән яңгыры.
Бөредә йомылган
яфраклар арыды.
Саргаеп көттеләр
үләннәр, уҗымнар.
Сарылган тузанны
тамчылар юсыннар.

И яңгыр, ю әле
берәүнең тәрәзен.
Күтәреп карасын
күңеле пәрдәсен.

Тамчылар, тамчылар,
белегез бер серне:
Мин бердәнбереме,
күпләрнең берсеме?

Нигә соң тәрәзә
томанлы, тузанлы...
И ләйсән яңгыры,
юдырып уз әле.

...

Кайдан синдә бу кадәр
сөенеч, шатлык?
Шатлыгың мина күчә,
үзеңнән артып.

Очраштык. Әйтергә сүз юк.
Үтәргә юл юк.
Сина ни сөйли икән
тынычсыз тынлык?

Кара коңгырт күзләрнең
төрлесен беләм.
Яз сыман яктыларын
беренче күрәм.

Үзем нигә елмаям,
сәбәпсез көләм?
Нигә сөенүеңнең
сәбәбен беләм...

...

Күзләр белән күзләр очрашканда
калам төсле упкын читендә.
Сагына да төсле, чакыра да...
Соңгы адымны ясау читен дә.

Тиңсез сагыш
кара тирәнлектән
якты өмет булып бөркелә.
Әллә көтә,
әллә икеләнә,
кулын сузмый, куя иркемә.
Ә мин һаман, сихерләнгән сыман,
басып торам упкын читендә.
Күзне йомсам, бәлки, атлар идем,
күрәләтә керү читен лә...

...

Яңгыр ява,
яңгыр ява,
гөрләп сулар ага.
Җыелмаган бөртекләрем
кала инде,
яна.
Урылганы,
егылганы,
сугылганы бергә...
Нигә килү кирәк инде
чакырылмаган җиргә.
Җыяр идем,
куяр идем
келәтләрне бикkә.
Йозак-келә табалмадым
йөрәккә
һәм
күккә.
Яшьнәп, күкрәп калыйм диме
җәйнең соңгы ае?
Күктәгеләр күкрәр инде,
җирдәгегә авыр.
Яңгыр ява,
яңгыр ява...

Гөрләп сулар ага.
Галәм суы сүндералмый,
Яна йөрәк,
яна.

...

Табышмакның җаваплары кызык, —
йә бик ерак, йә бик якыннар.
Син эзлисең мичтән пәрәмәчләр,
алар йолдыз булып балкыйлар.

Йөрәгенә ут салучы бала
Кайда йөри?
Табу, һай, авыр.
Ә ул синең каршында ук икән —
кайнап торган сары самавыр.

Ак самавыр жырлый, гөрли генә,
Дус-ишләрне жыя табынга.
Тик йөрәге
кеше кулы белән
утлы күмер салып кабына.

Янар йолдыз
төннәр карасына
үз яктысын биреп яктыра.
...Синең күзләр йолдызларга тиңме, —
хыял илләренә чакыра.

Эзләгәнне бик якыннан тапсаң,
табу сөенече ник сүрән?
Ерактагы учак якты сыман,
якын килсәң, инде ул сүнгән.

Табышмаклар дөньясына кереп,
әллә инде үзем югалам.
Минем өчен әле табылмаган
табышмак син.

Эзлим, уйланам.

...

Яланаяк юлга чыгам,
әле янам, әле туңам,
һаман барам бер ялсыз.
Әллә җәй бу, әллә кыш.

Берәү аңлый, берәү каргый,
аяк тала, йөрәк армый,
һәр борылыш — сөенеч,
әллә бәйрәм, әллә эш.

Бер югала, бер табыла,
бер ераkта, бер янымда, —
кояш кына бата кич.
...Әллә өн бу, әллә төш.

...

Буранлы кышларым,
яшенле җәйләрем,
Йокысыз таңнарым,
кичләрем...
Кайларда кышлады,
кайларда җәйләде
хыялда сакланган төсләрең?
Ә хыял канатлы,
ябуны яратмый.
Кошларга кинлек бир,
югалмый.
Кундың да, очтың да,
тотарга кыялмыйм,
бәхетме,
әллә син хыялмы?
Ә бәхет түгәрәк,
килә, ди, тәгәрәп,
туп итеп уйнарга, чөяргә...
очасың,
төшәсең,
туктама,
тәгәрә.
Кояшы артыннан
жир калмый,
иярә.

Кайсыннан алыйм да,
бирим соң кайсына, —
берәүнең бәхете —
берәүнең кайгысы.
Кайгыны бүлешәм,
шатлыкны өләшәм.
Ә бәхет бүленми,
ник аның ярты сы?
Торналар очалар,
торырга кушалар.

Жыр белсәң, кошка бир,
таратыр.
Кешедән качырган,
эченә яшергән
сукыр ут саргайтыр.
Чаткылар уйнасын,
йоклаган уянсын, —
мин күккә йолдызлар чөям.
Сүнсә дә нур калсын.
Көл түгел, жыр калсын, —
янам мин,
сөям!

...

Болытларны ярып нидер үтте,
әллә яшен, әллә ажаган.
Табылмаган,
танылмаган уктай
йөрәгемә нидер кадалган.

Кузгата да, сызлата да сыман,
җәрәхәт тә кебек, түгел дә.
Көе табылмаган,
язылмаган,
җырланмаган жырдай күңелдә.
Сызлаган да булды,
эзләгән дә.
Ул чакларны инде оныттым.
Эзләгәндә түгел, сизмәгәндә
юлларыма нигә юлыктың?

Сизелмәгән,
әле бизелмәгән,
өзелмәгән гөлләр кирәкме?
Күз күрмәгән гөлнең энәседәй
нидер чәнчеп тора йөрәкне.

Бозлы диңгез ятса арабызда,
эретер иде кайнар хисләрем.
Карлы таулар булса,
мәхәббәтнең

канатлары белән кичәрмен.
Юллар, еллар безне аерсалар,
йөрәкләргә алар киртәме?
...Бер сукмактан йөреп,
очрашканда,
туктап кул да бирми китәмен.
Күзләреңнең сихри нуры сүнәр,
караларын түгеп карама.
Очып,
йөзеп,
атлап чыгалмаслык
кеше язмышы бар
арада.

...

Синең куллар белән минем куллар,
синең юллар белән минем юллар
очрашса да бергә үрелмәс,
“Саумы” диеп кемнәр кул бирмәс.

Ә мин кулым бирәм син сузганда.
Ә мин өнсез булам син узганда,
Йөрешләрең әллә тылсымлы.
Очрашулар безнең бик соңмы?

Үзем кулым алам кулларыңнан,
үзем күзем алмыйм юлларыңнан,
булыр төсле берәр могҗиза.
Көн артыннан шулай көн уза.

Ә мин сыныйм акыл белән хисне.
Баскан җирдә карлар эрер төсле...
Йөрәк каты тибә, тиз эремәс.
Күзләреңә туры карасам да,
эчләремдә утлар кайнаса да,
кулым салкын булыр,
сиздермәс.

...

Чәчләреңне тарар идем,
күзләреңә карап.
Алар көзге көндәй соры,
болыт сыман кара.

Беләм бит мин ул күзләрнең
иң бәхетле чагын.
Тибрәндереп, сискәндереп
карарлармы тагын?

Кояш кебек кирәк миңа
яздай якты йөзең.

...

...Атналары бик тиз уза,
бәйрәмнәре озын.
Отыламы, онытыламы
язылмаган җырлар.
...Иңнәремә салынмаган,
кагылмаган куллар,

Серләреңне белер идем,
күзләрендә томан.
Алар бүген ерактагы
кара урман сыман.

...

Ымсындыңмы, күңел?
Актыккысы.
Ахыргысы булсын. Соңгысы.
Очып барган идең каршысына,
сынып килде Амур сөнгесе.

Сөюемне яклап яуга чыксам —
каршы сөңгеләр юк,
буш кыны.
Йөрәгендә калкан —
янган, сарган
сүнгән мәхәббәтләр юшкыны...

...

Кашларың кыйгач дигәннәр
чәченне үрмәсеннәр.
Башларың ялгыз дигәннәр
яшеңне күрмәсеннәр.

Гөлләргә тиңләсеннәр,
алларга тиңләсеннәр.
Арага кергәннәре дә
яраңны күрмәсеннәр.

Сагышлар йөздә чагылса,
әйдә,бер сөйләсеннәр!
Сагына дисә дисеннәр,
ялына димәсеннәр.

1964.



***

Хисләр болыты
кыя күкрәгенә тап булды,
ватылды
челпәрәмә.
Өзелде,
сибелде җиргә
чын гәрәбә.
Әйләнеп кайтып эзләдең,
бөртекләп жыйдың тезләнеп,
ә жепкә тезмәдең.
Салкыннар алар, дымлылар,
чыкмы бу, бәсме...
Учыңда йөртәсең курынып*,
кабат чәчелмәсме?

1964.

---

* Курыну - югалтудан курку, кызгану.



***

Чәчкә хисләреңне букет итеп,
сөйгәнеңнең аяк астына
салма, салма, дускай,
аларга бит
ялгыш булса да бер басыла.

1964.



***

Ah, ник түгел җилдәй җиңел чагым?
Пар канатлар — кашың, керфеген.
Шул канатка кунып очар идем,
изге хыял итеп җир-күгем.

Бик карамыйм әле күзләренә,
юк, бирелмим әле хисемә —
иңнәремә авырлыгын салган
дөньям тарта мине үзенә.

Вәгъдәләрем анда, өметләрем...
Син дә җирсез, илсез ир түгел.
Юк, карамыйм әле күзләренә,
җирдә үзем салган эзләрем бар.
Кош канаты — кашың-керфеген.

1965.



*Йөрәк җыры**

Тиңләр өчен серле күзләреңә
күк йөзеннән йолдыз эзләдем.
Гөлләр сибеп йөрдем эзләреңә,
ятка калганыңны сизмәдем.

Ян сиң, йөрәк, ян син, ян көчлерәк,
ялкыннарың бер чак сүрелер.
Янган мәхәббәтем очкыннары
йолдыз булып күккә сибелер.

Караңгыда юллар эзләрсең дә
йолдызларга карап табарсың.
Сызылып кына йолдыз атылганда,
өзелеп сөюемне аңларсың.

1965.

*М.Имашев музыкасы.



Яңгыр килә

Яңгыр килә, яңгыр килә
кара урман буеннан.
Явар түгел, кояр яңгыр —
күк болытлар куерган.

Яңгыр килә, яңгыр килә,
юл өстендә ком-тузан.
Әйдә, бер яу, жәйге яңгыр,
ком-тузаннан тын кысан.

Яңгыр килә, яңгыр килә
күк күкрәтеп, яшенләп,
узма, яңгыр, жил уйнатып,
явар булсаң, яу чынлап.

1965.



*Агым сулар**

Агым сулар ярсып ага,
әллә яры тар микән?
Сулар ага, йөрәк яна,
сүреләсе бар микән?

Агым суда, агым суда
агып китте балдагым.
Агым сулар ташлап китә
үз дип көткән ярларын.

Агым суга сал төшердем,
тал бөгелә, кисмәдем.
Хисләреңне җилкән итеп,
бармы дәрья кичкәнең?

Аккан сулар кире кайтмас,
инләп-буйлап йөзәрмен.
Син онытсаң, мин, бәс булып,
керфегеңә төшәрмен.

1965.

---

*Ф.Галәмиев музыкасы.



Чуерташ

Җилләр исеп, болыт куергач та
роза тажы сыман коелмас, —
Кырым кырларыннан истәлеккә
алып кайтам сиңа чуерташ.

Алырсың да ташны, йә көләрсең,
Йә салырсың берәр тартмага.
Ә мин күрдем аның болытларга
атылганын үткән атнада.

Ул үзе дә гади бер таш түгел, —
күптән сүнгән йолдыз затыннан.
Жирне караңгылык каплаганда
якты бер нур булып атылган.

Йолдыз сүнгән. Ташкыннарга төшеп,
чуерташка инде әверелгән.
Гомер узган саен, таш тәнендә
сурәтләнә барган дәверләр.

Карлы таулар — ташның аркасында,
тау башында — болан мөгезе.

Кара болыт әнә якынлаша,
яулар баса Кара диңгезне.

Упкын аша очып, чаптар атлар
таудан төшә быргы тавышына.
Һәр авазы илнең, һәр ярасы
Ярылып калган җирнең ташында.

Су буенда, диңгез ярларында
чуерташлар ята янәшә.
Төннәр буе алар, күккә карап,
йолдызлары белән серләшә.

Ә йолдызлар җирдән күренмәсә,
күк йөзендә болыт куергач,
давыл куба, диңгез ярдан чыга,
һаваларга атыла чуерташ.

Күп дәверләр ташка язылып барган
ят авазлар кабат яңара...
Ташны ташка бәрсәң, очкын чыга,
ташлар алар эчтән яналар.

1965.



Каен себерке

Ап-ак зифа буй-сынын
хәтерләми дә иде,
язга яшел шәл-яулык
әзерләми дә иде.

Кемдер җиргә кадаган
каен себерке сабын...
Кайткан мәллә, ак каен,
алкалар таккан чагың?

Муртайган чыбыкларны
кем күтәргән өскә? —
төшермә, төшермә,
төшермәгез искә...

1964.



Кунакчыл

Тәмле сыеннан өстәл сыгыла,
баллы теленнән хәмер түгелә,
керфек очыннан саркыла мәкер,
и фәкыйрь, фәкыйрь...

1964.



***

Су буйларын буйлыйм.
Ярга басып,
рәсемнәр дә, җыр да язганнар.
Гел яшәреп торган бизәкләрне
табалмаган әле рәссамнар.

Нинди серле минем зәңгәр күгем!
Күк гөмбәзе, беләм, ачылган.
Ләкин хыял очкан биеклеккә
менәлмәгән әле лачыннар.

Үлчәп төштек девон тирәнлеген,
океан-диңгезләргә тиң генә.
Кеше күңеле тиңсез тирән дәрья —
беркем җитәлмәгән төбенә.

1966.

*Урсал тауда**

Ярларына кайты елга,
яшелләнде киң ялан.
Урсал тауда күксел томан,
әллә шуңа моңланам?

Яшьнәп, яшеннәр көйдерсә,
яңгырда калып чылан.
Урсал тауда кара урман,
керсәм, чыгалмам сыман.

Көзләр килде,
төсләр төрле —
алтын бизәк ай гынам!
Урсал тауны сары сарган,
әллә шуңа кайгырам?

Үтә айлар, көтә Зәйләр,
суларында йөзәлмим...
Урсал тауга карлар яуган,
барам инде, түзәлмим...

1966.

---

*Рәис Нәгыймов музыкасы.



***

Кар суы шаулап-гөрләп акты,
кошларны уятты.
Минем кайгы-хәсрәтем кайтты,
җылатты, юатты.

Гөл керфекләрен түбән иде,
Бар дөнья тын калды...
Минем бәхетем-шатлыгым китте,
ай күрде, көн алды.

Бәхеткә шулай килеп-китеп
йөрергә калдымы?
Узгынчы узар. Кайсы туктар —
шатлыкмы? Кайгымы?

1966.



Ерак икәнен дә беләм

("Гүзәлия җыры")

Таң атканда уйланам,
су акканда моңланам.
Таң нурында син йөзәсең,
утларында мин янам.

Биек тауга менимме,
агым суга керимме?
Дусларыма сөйлим микән,
үзем генә белимме?

Таулар текә, су тирән,
тирән булса да керәм.
Ерак икәненне беләм,
нигәдер якын күрәм.

1966.

---

*М.Имашев музыкасы.

*Нефтьчеләр маршы**

Җырлап чыгабыз иртән кырларга,
кырлар, урманнар уяна.
Көч бар беләктә,
кодрәт йөрәктә,
кеше бәхеткә юл яра, —
суда йөзәргә,
күктә очарга,
галәм серләрен ачарга.

Корыч манара аумас жилләрдә,
күңел омтыла тирәнгә.
Таулар селкенә,
йөрәк жилкенә,
максат бер генә: жиңәргә! —
Суда йөзәргә,
күктә очарга,
галәм серләрен ачарга.

Җырлап чыгабыз иртән юлларга,
кырлар, урманнар уяна.
Утлар кабына,
нурлар агыла,
жыр кала туар елларга, —
суда йөзәргә,
күктә очарга,
галәм серләрен ачарга.

*М.Имашев музыкасы.



Дан турында баллада

Сафлар килә урам буйлап,
атлый хезмәт данын зурлап.
Адым төгәл,
кулда җегәр —
кем килә?
Яшь нефтьчеләр.

Бу инде безнең гадәттә:
җыела ел да Әлмәттә
башкорт,
казакъ,
азербайҗан —
сәлам, Татарстан!

Быел слет йолдызлары —
Нурисламов* һәм дуслары.
Слет байрагын элә Дамир,
эштә — яныр,
сүздә — сабыр.

---

* Дамир Нурисламов - Көнчыгыш нефть районнары буенча рекорд куйган бораулау остасы.

Җәйрәп күккә менә байрак.
— Кыюрак, егет, кыюрак!-
Иптәшләре хуплап тора:
— Дамир, ура!
Дан.
Бөек тә һәм гади дә.
Кем белгән кичә фамилияң?
Бүген исемең белән дәшә
карты-яше:
— Дамир, яшә!

...

Бу жирләрдә булган әсир
җиде буын, җитмеш нәсел.
Кара тирән, кайгы-зарын —
җир сендереп торган барын.

Җир күкрәге — канлы яра,
йөрәгенә ялкын каба.
Кемнәр ачар, кемнәр табар,
ялкынга иш җаннар кая?

Күп гасырлар җир астында
гүләп торган утлы елга.
Ата-баба васыятен
сөйләп торган елдан елга.

Яшәү уты тирән, ерак —
кыюрак, батыр, кыюрак!
Күккә ургый алтын фонтан!
Ни телисең:
ут, кан?
Нур, таң!

Салкын кышны ут жылыта,
жансыз кошны кан терелтә.
Айга оча ракеталар,
балкый ерак планеталар.

...

Уйламадык дан хакында,
эзләмәдек ансатын да.
Тамызмасаң тамчы тирең,
кабул итмәс изге җирең.

Туфрак кара көйгән җирдә
алтын фонтан!
Кем җан өрде?
Егетләрең, Татарстан,
бүген тирә-юньгә өлге.

Якын итеп килгән Төмән,
төркмән, үзбәк,
коми, пермяк.
Нефть серен өйрәнүдә
Әлмәт үрнәк!

Космонавтлар, күккә менә
биеккәрәк, гел үргәрәк.
Нефтьчеләр тау-таш кисә,
түбән төшә, тирәнгәрәк.

Галәм айкый корыч кораб
һәм ирешер морадына,
тирән булса тамырлары
туып-үскән туфрагында.

...

Үзәк мәйдан шыгрым тулы,
фотокоры, репортеры.
Иң үзәктә данлы халык.
Ә без, энем, читтән карыйк.

Иң биеккә без очмаган,
рекорд куеп җир тишмәгән.
Күңелләрне тетрәтердәй
шагыйрь булып җитешмәгән.

Дан бөек ул. Данны куса,
авып төшә космик кораб.
Данны зурлап яшим дисәң,
гадәтенә булмас ярап.

Данга төбәп чыккан юлда
азмы батыр кабер тапты.
Үз-үзенә һәйкәл куйса,
тарих аны бәреп ватты.

Халык өчен яуда янса,
шагыйрь кайта җырларында.
Тамырың булсын, тирән булсын
туган-үскән җирләрендә —

җырлар яңгырар,
Байрак җәйрәр!

Тантаналы үзәк мәйдан.
Адым төгәл,
кулда җегәр —
кем килә?
Яшь нефтьчеләр.

Аклый халкым өметләрен,
данлыйм шундый егетләрне.
Ә кем соң дан өмет иткән?
Иле кушкан,
улы киткән.

Дамирмы бу, Николаймы —
үтәр изге әманәтне.
Шундый уллар биргән илнең
жирдә калмас яман аты.

Дуслар килгән.
Һәркемнең бар
Җәлилләре, Дамирлары.
Бик тирәндә, бик ераста
безнең дуслык тамырлары.

Кушылды да бер йөрәккә
әтиләрнең түккән каны,
күтәрелде байрак булып
Хезмәт даны.

1963.



Юллар, уйлар

(цикл)

Тал-тирәкләр тагын яфрак ярды,
бөреләрен ачты юкәләр.
Таң алдыннан Бигәш егетләре
тальян гармун уйнап үтәләр.

Көйләргә дә ачык, җилләргә дә,-
шәһәр чите койма-киртәсез.
Уйлар, юллар китә еракларга,
чакыра җәйнең чыклы иртәсе.

Сабый чакның сукмаклары сыман
тальян моңы
әрәмәгә кереп югала.
Уйларымның очы
авылымның
талларына кайтып урала.

...

Язгы таңда ярсып калган күңел,
Җәйләр житсә, чыга җәйләүгә.
Мотор гүләвеннән башың арса,
кырлар иркен, төш тә җәяүлә.

Саумы, авыл!
Исәнмесез, кырлар.
Урак урып йөргән җирләрем!
Ераклардан сагынып кайтыр өчен
ташлап китәбезме илләрне?

Сабый чакнын яшел сукмаклары,
үсеп житкәч, ахры, тарая.
Уйлар, юллар ерак алып китә,
далаларга, шаулы калага.

Дала жилләреннән кырысланып,
кала шавы белән басылып,
бер күрим дип, йә бер күреним дип
кайтсаң, яшьләр карый ятсынып.

Су буенда, кичке уеннарда,
бию залларында башкалар...
Өлкәнрәкләр танып-төсмерләпме,
олы күреп сина баш кага.

Җил капкалы иде киткән чакта —
өр-яңа йорт энем җиткергән.
Минем өчен һаман шул җил капка...
Әңкәй чыга җилдә җилфердәп.

...

Шатлык кояш кебек балкып чыга,
кайгы иңгә төндәй сарыла.
Кайгылардан күңел кырыслана,
сөенечтән канат кагына.

Яздай якты, алтын көздәй сабыр
әнкәй басып тора каршыда.
Йөрәгеннән үткән шатлык-хәсрәт
керфегеннән тамган тамчыда.

* * *

Алмашына тора көннәр, төннәр.
Төннәрнең дә була айлысы.
Иң караңгы төннән кара, диләр,
Ачы, диләр, бала кайгысы.

Син дә, әнкәй, кыю ул үстерден,
Таянычым, диеп, ир бала.
Аянычың синең, ачы яшең
Кара керфегендә тирбәлә.

Сөенечне томалаган яшьләр —
Минем дә бит вөждан газабы.
Күрмәсен дип, селтәп ташлыйсың да:
— Нихәл, кызым, исән-тазамы?
Күзләр яшел бәбкәләргә күчә:
— Күп буласы быел казларым...
Эчкә йоткан ачы яшең, әнкәй,
Безнең дә бит вөждан газабы.

Сулар ага, аның юлы кала,
Язлар җиткәч, кайта ярларга.
Ерак юллар бары якынлыкны
Сынар өчен ята арага.

Күлләр кибә, җирдә яра кала.
Каплый аны яшел үләннәр.

Ана жанын ярып алып китсә,
Ил теленә кайта үлгәннәр.

Була ачы яшьле яшерен яра,
Кара төндә керфек кактырмый.
Әрнү салып, үзе рәнҗү алып,
Хәтәр юлга киткән кайтырмы?

Язлар кайткан саен ярлар тула,
Кар суы да таба үз юлын.
Шатлык ташып өйдән кырга чыга,
Ана көтә тагын бер улын.

...

Туган илме, торган җирме яхшы?
Берсен алып, берсен ташлама.
Олы юлга чыгар сукмакларың
авыл кырларыннан башлана.

Туфрагында тәүге эзең калган.
Кырлар сырлар салган табанга.
Кемдер сине монда өзелеп сөйгән,
бәлки онытмыйдыр һаман да?

Сөйгән ярлар күптән онытса да,
бер хис сүнми, һаман яңара.
Елның аен айга ялгый-сүтә
сине көн дә көткән ана бар.

Туган якның якты язларына
очып кайта киткән кошлар да.
Әнкәй, синең күңелең яз шикелле, —
кайткан кошлар белән хушлана.

Туган җирме, торган җирме якын?
Юк, берсен дә сызып ташлама.
Без торган жир — кара алтын иле,
олы эшләр шуннан башлана.

...

Тал-тирәкләр тагын яфрак ярды,
бөреләрен ачты юкәләр.
Таң алдыннан Бигәш егетләре
тальян гармун уйнап үтәләр.

Җырларга да ачык, юлларга да —
шәһәребез койма-капкасыз.
Юллар!
Нурлар төяп китәсез дә
яңа моңнар алып кайтасыз.

1966.

Каз канаты

Каз канаты —
кыз канаты.
Киек казлар оча, кызлар!
Сырлы оя, җылы абзар
теләмиләр киек казлар.

Ишек алды — каз базары,
каңгылдаша йорт казлары, —
очты, очты киек казлар.
Шагыйрь сагынып җырлар язар.

Җимнәр сибәм казларыма,
үзләренә тиздән өмә.

Каз канаты каурый-каурый,
мич агарта, коймак майлый.
Ак болыттай мамык — йомшак,
яшь кияүгә мамык түшәк.

Каз канаты кат-кат була.
Канат кагар бер чак була.
Очты, очты киек казлар.
Каз өмәсе җитә, кызлар!
Каз канаты —
кыз канаты.

1967.

Серләремне сиңа сөйлим

Серләремне сиңа сөйлим,
Агыйделкәй, акмый тор.
Айкама да, чайкама да,
төпләрендә саклый күр!

Агыйделкәй, һай агым су,
тарая да киңәя.
Серләремне тыңлады да
салып куйды тирәнгә.

...Төнбоеклар көнгә чыккан
Агыйделнең төбеннән.
Төнбоеклар ник боек дип,
таллар суга иелгән.

Талларга сандугач кунып
сайраган таң атканда...
Эч серләремне кошлардан
ишеттем үз бакчамда.

Агыйделкәй, серләремне
сиңа гына сөйләдем.
Саесканнар авызыннан
ишетмәсен сөйгәнем.

1967.



***

Җыр ишетеп чыктым басуларга.
Җырлы башак, чыклы ужымнар
камылларга калып саргайганчы
һаваларда яңгырый бу җырлар.

Кыңгыраулар тагып туйлар килә,
өзеп көзге эшләр зынҗырын.
Берсе җырлап бирсә, бер җавапсыз
калдырмыйлар бездә ул җырны.

Җыр ишетеп килдем бу дөньяга.
Соңгы юлга җыенып, көлтәләр
сабыр гына ни көтәләр дисәм,
миннән җавап җыры көтәләр.

1968.



***

Офык диңгезендә ал җилкәндәй
таң беленә,
гөлләр сизгәнме? —
мәк чәчәге таңны көтә иде.
Нуры төшкәч, кинәт сискәнде.

Тибрәнде дә ачты канатларын:
әйтелмәгән серләр калмасын.
Сак кына ис, җилкәй, чак кына ис,
коелмасын,
йомылмасын.

1967.



***

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Йөргән юллар белән,
Уй чаткысы булып йөзгә төшкән
юл-юл сырлар белән.

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Менгән үрләр белән,
үзән-үрләрендә йөргәнеңдә
белгән серләр белән.

Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Калган эзләр белән,
кеше күңеленә орлык итеп
салган сүзләр белән.

Һәм өметләр белән! —
Я табылган,
я тапталып калган...
Гомереңдә алда —
үлчәүләргә сыймас
хыялларың барда.

1968.



***

Тынгысыз башкайларымны
салыйм да күкрәгеңә,
онтылып очыйм әле бер
хыялым күкләренә.

Арала авыр уйлардан,
яман сүзләрдән якла.
Алып кит әле син мине
сызлып таң аткан якка.

Утлымы, канлымы сызык
төн һәм көн арасында? —
Офыкны түгел, йөрәкне
яралап яна сыман.

Без аны кичәрбез бергә,
ялгарбыз төнне көнгә...
Алып кит әле син мине
алсу таң аткан җиргә!

1967.



***

Сине сагынып, төн узганын көтәм,
нурлар бөркеп, назлап уятам.
Балкып каршы алам көн дә иртән,
мин — таң.

Кояш батса, төн үзенә ала,
төн куенында нинди кара көч?
Моңнар, серләр әсирендә калам,
мин — кич.

Кышлар уза.
Җәйнең урман-суы
кочагына сине алалмас.
Ташкыннарым белән үзем киләм,
мин — яз.

1967.



***

Буйга җитеп, балигъ булгач, бала
бирәчәген уйлап өтелә:
— Сәфәр чыгам, бәхилләшик, анам,
бармы бәя күкрәк сөтеңә?

— Йөрәк каным белән Ил бирдем дә,
Күкрәк сөтем белән Тел бирдем.
Саклый алсаң — мәңгелек фатихам.
Җуйсаң, сатсаң — күкрәк сөтем хәрам!..

1967.



Асмалы күперләре

(Җыр)

Урсал тауда тал үскән,
тармагы Зәйгә төшкән.
Кич җиттеме, су юлыннан
бер сылу кайта эштән.

Асмалы күперләре,
тирбәлеп үтүләре.
Тибрәнеп калды хисләрем,
әй, читен китүләре.

Тукталмый яннарыма.
Карый Зәй ярларына.
— Сөюләрең хак булса, — ди, —
ник кайттың ялга гына?

Билгесез фикерләре,
җәйнең тиз үтүләре...
Әйләндерде башларымны
асмалы күперләре.

Төнбоек ал кулымнан,
боек су салкыныннан.
Зәй буенда ут кабынды
мәхәббәт ялкыныннан.

Тирбәлә күперләре,
бергәләп үтүләре...
Утка-суга сала икән
мәхәббәт сихерләре...

1967.



***

Кипарислы Кырым. Кайнар ярлар.
Алтын нурлар, көмеш дулкыннар.
Кара диңгез,
зәңгәр кочагында
юллар,
үткән еллар онтылган.

Кырым.
Ханнар,
канлы яулар кыры.
Сөнге таулар, серле сарайлар.
Яр өстендә кызыл гөлләр үсә,
Һәр ташында, баксаң, яра бар.

Ничә гасыр шул ярларга яуган
ук, сөңгеләр,
туплар, бомбалар.
Шул елларга колак салган сыман,
күксел таулар моңлы,
шомлылар.

Яулар тынган.
Диңгез ярларына
юллар ачык барча яклардан.
Таулар сакта,
хәтта гөлләре дә
энәләрен кадый ятларга.

1967.



Севастополь

Күбәү өчен берәү гомерен бирә.
Берәү өчен үлә дистәләр.
Дәвам иткән тарих битләренә
данлы юллар тагын өстәлә.

Дан каласы,
синең итәгеңә
тарих үзе килеп туктаган.
Батырларның янган йөрәкләре
ялкынныннан юлга ут алган.

Гасыр үрләренә юнәлгәндә,
Җемелдәшә утлар, чакыра.
Җыерчыклы тарих битләрендә
Балкып кала яңа чаткылар.

1967.



Дулкыннар

Тирбәтәсез зәңгәр бәллүләрдә,
бик назлы да бит сез,
йомшак та.
Сихерләнгән сыман, һай, бик күпләр
ташланалар сезнең кочакка.

Иркәлисез,
аннан ярсынасыз,
ургыласыз кыя ташларга.
Ыргытасыз барсын яр читенә,
әллә хисләр тулып ташканга,
бушанырга?

1967.



Мәхәббәт фонтаны

Фонтан любви, фонтан живой,
Принес я в дар тебе две розы.
А. Пушкин.

Бакчасарай. Шигъри томан аша
барыр юллар таулы, бормалы.
Борылмалы тау сукмагы түгел,
алып килде шагыйрь юллары.

Фонтан. Күккә ургылмыйлар сулар,
көмеш тамчы саран тамчылый.
Яңа тапкан мәхәббәтен җуйган
ир йөрәге булып таш елый.

Хан йөрәген әсир иткән сылу
тоткынлыкта үлгән сагыштан...
Фонтан. Яшь эчендә ике роза, —
берсен-берсе каян табышкан?

Шагыйрь салган ал һәм кызыл роза —
мәхәббәткә һәйкәл, иреккә.

Тәнне алып була,
жанны — булмый,
хәтта хан йөрәген биреп тә.

Сабагыннан сынган гөлләр сыман,
жарияләр сулган сагыштан.
Яшь эчендә ике тере роза,
гүя ике йөрәк кавышкан.

1967.



***

Бу диңгезгә төшеп югалмыйсың,
суда көймәчеләр күзәтә.
Кызыл буйны узу тыелганын
яр буенда диктор кисәтә.

Буйлар, чикләр —
шикләнгәннәр өчен.
Зәңгәр дөнья ята арырак.
Кисәтүсез, күзәтүсез киңлек,
таулар гына үрелеп карыйлар.

Инсез, буйсыз,
тыелгысыз диңгез...
Куеныма дулкын сарыла.
Кеше, куркып чиксез иркенлектән,
кире кайта шаулы ярына.

1967.



***

Таулар кичтем, диңгезләргә төштем,
тынмасмы дип йөрәк яныу.
Диңгез суы парга әйләнде дә
ак болытлар булып агылды.

Сулышларым,
болытларны куып,
кайнар жилләр булып истеләр.
Кайтсам,
күктә йөзә шул болытлар,
явар өчен минем өстемә.

1967.



Гомер

Кыш килә,
көннәрне кыскарта,
күк йөзенә күк пәрдә тарта.
Ак юрганына төрен дә ят! —
Мәңге хуҗа булырга уйлап,
сызгырып, дулап,
кыш килә.
Яз килә
йөгерә-атлый,
тып-тып —
тамчылар тама,
кояш, чык-чык!
Шәрәгә калып, дөнья яшәрә,
киенә,
ярларны тарсынып ярсына,
узмас яшьлек сыман
яз килә.
Җәй килә
җәяүләп, җайлап.
Тетрәтеп уза яшен-җайдак
сабан туйларына, бәйгегә.

Күенын ачып кояшка, җилгә,
җәйләүгә чыга дөнья,
җәй килә.

Көз килә.
Каеннар күзе күлдә — көзгедә,
юлларда тау-тау олаулар,
җырларда көлү дә елаулар...
Бизәнеп, баеп көз китә.
Ата йортыннан гүя кыз китә.

1970.

***

Җилме соң бу?
Тирәкләрнең шавы
тәрәзәмә ялгыш кагылды.
Ерак юллар үткән Идел дымы
иңнәремә килеп сарылды.

Җирсүме бу? —
Су буена чыктым,
күл күзенә батты карашым.
Күл төбенә багып, якынайттым
җир-су белән күкләр арасын.

Яз инде бу —
ташкын көткән ярлар,
орлык көткән үзле ызаннар!
Яз килә дип казлар канатында,
йөгереп йөргән чаклар узганнар.

Син инде бу —
сагыну, җирсүләрем.
Суга сусап, таулар тезләнгән.
Яз килә, дип, казлар канатында,
йөгереп китәрмендер, түзалмам.

1973.



***

Күпләр, беләм, гомерен корбан итеп,
шашкын хискә ияреп атылган.
Мин башбаштак хисләремне чалам
гомер иминлеге хакына.

1973.

III бүлек

Тормыш булмый кою-сөенүсез



Ак калалар

Траншеялар,
ташлар өеме,
узганмыни яулар!
Таш калалар сала кыюлар,
актарыла таулар.

Ак калалар сала кешеләр,
ай катында утлар.
Акчарлаклар оча диярсең —
ак чардаклы йортлар.

Кәрван шәһәр
Кама ярында,
колачлары зурдан.
Яшь калага яулык болгыйлар
ак кораблар судан.

Ак калалар сала кыюлар,
як-яклары — урман.
Таш каланы бизи кешеләр,
урам — каен бульвар.

Ага Кама,
атлый төзелеш,
адымнары күркәм.
Ак каеннар әнә тезелеп
суга бара иртән.

1967.



Иртән

Сандугачлы бакча хәзергә юк,
әтәчләрдән башка таң ата.
Кунак өе тәрәзәсен кагып,
экскаватор тавышы уята.

Таң белену белән килеп житкән,
йоклап калмасын, дип, кунаклар.
Аз-маз таныш кеше чәйгә ала,
бик кунакчыл икән бу яклар.

Урам аша берәү фатир алган,
җырлыйсы бар әле, биисе!
Яңа туган сабый тавышы белән,
хыял белән тулган өй эче.

Шушы өйдә чәйдән авыз иткәч,
әйтәм лә шук яшьлек өстәлде, —
яшен суккан ярык нарат икән
газет җәеп куйган өстәле.

Яңа урам, исеме «Тын аллея»,
ишек алларында гөлчәчәк.

Кайнашалар күзлек кигән кызлар —
тимер кисә алар, ут чәчә.

Бар да яшьнәп тора яңа җирдә,
утлар сүнеп житми, таң ата.
Сузган куллар булып юллар көтә,
кешеләрне шулар уята.

1967.



Кич

Искелекләр монда юктыр сыман,
“Кристалл” ресторaны өр-яңа.
Кайсы эштән кайткан, кайсы ялда,
кайсы кәефләнеп болгана.

Сөлек кебек егет безнең янда
бер кабынып алды, бер сүнеп.
Үз хатыны аны ташлап киткән.
Тыңладык без авыр көрсенеп.

Ни әйтик соң? Бер дә рәнҗетмәгән.
Эчкәләгән бераз. Тартмаган:
Ә хатыны, яшь баласын алып,
хушлашмый да киткән. Кайтмаган.

Буйдак кичләр хәзер ресторанда...
Бер уйласаң исең китәрлек:
нинди хатын сөлек кебек ирне
ташлап китә, бала күтәреп?

Ни житмәгән: йорты, машинасы —
күп төшергән егет айлыкны...

Акча белән тутырып була микән
җанны суырып алган сазлыкны?

Табигате белән бик сабыр да,
бик батыр да безнең хатыннар.
Авырлыкны бергә күтәрешә,
утка керә ире артыннан.

Утка керә, ире ялкын булса,
сазлыкка да шулай керсенме?
Сөлектәй ир җеби ресторанда.
Ни әйтик соң — авыр көрсендек.

1967.



Яшьлеккә хас

Чыршылардан узып күккә ашкан
корыч колонналар кырыслар.
Урманнарны ярып гудок яңгырый,
арыш басуында — рельслар.

Якынайта өлгер тимер юллар
шәһәр белән авыл арасын.
Шәһәр туган җирдә магнит бардыр,
шунда тарта авыл баласын.

Бизүдән дә түгел үз өеннән,
киләчәккә яшылек ашыга.
Энҗе-җәүһәр табып җир ташыннан,
бизәк сала җирнең кашына.

Ят диңгезләр, ак калалар калка,
таң атуга яңа төс арта.
Үзгәртәбез шулай җирнең йөзен.
Ә ул безнең йөзне үзгәртә.

1967.



Кама буенда

«Суда балык йөзәдер,
су салкынын сизәдер...»
Су буенда балыкчылар,
белмим, ничек түзәдер.

Кама ага, Кама ага,
дулкын кага ярларга.
Саллар ага, ярлар кала,
гармун уйный салларда.

Агым суга таянырга
өйрәнәләр балалар.
Талгын дулкын бишегендә
тирбәләләр калалар.

Ярдан ярга колач салып,
яшүсмерләр узыша.
Су буйлатып, җил уйнатып,
моторкада кыз оча.

Пароходлар, пароходлар
алып китә уйларны!

Җилләнеп тә, моңланып та
кала Кама буйлары.

Энҗер ята. Теге ярда
дөрләп яна бер учак.
Салкының да, ялкының да
бергә инде, туган як.

Ишкәкчеләр ярышмый да,
бер-береннән калышмый.
Әкрен генә җыр сузалар,
су өстендә таныш моң:

«...Авылыбызда бер матур бар,
үзәгемне өзәдер...»
Су буенда балыкчылар,
белмим, ничек түзәдер.

1967.



Син әле тәмле йокыда

Көн әле яктырмаган да,
урамнар тулы халык, —
атлыйлар җилне җәһәтләп,
бүрекне кыңгыр салып.

Сөтле шешә муенын сузган
кайсының сумкасыннан.
Кар гына шыгырдап кала,
бүленеп йокысыннан.

Буровой юлы суынмый,
кышын да гөрли кырлар.
Син әле тәмле йокыда,
кешеләр җирдән ут ала
өеңне жылытырга.

1969.



Тәнкыйтьче дуска

Без мәйданга чыктык,
һәр көрәштә
бар бер гадәт-йола:
баш ярырга мөмкин җиргә орып,
аяк чалу тыела.

Юк, бу көрәш түгел,
бокс, ахры,
син йодрыклы, тукма.
Башка тондыр, йөзгә,
ияккә бәр!
Минем йөрәк,
йөрәк капланмаган —
тик йөрәккә сукма.

1967.



***

Тешлеләре усал тешләделәр,
тешсезләре ямьсез көлделәр,
күңелемдә шыткан янар гөлне
җиргә таптап, җилгә элделәр.

Гөлкәемне көл-күмердә күреп,
утсыз яндым. Һушсыз уяндым —
ачу йоткан усал бүреме мин,
коты качкан куркак куянмы?

Йөгерек зиһен кирәк ак куянга,
үткен тешләр кирәк бүрегә!
Җәядәге уктай үткенләнәм,
гайбәтчеләр, сезне күрүгә.

1967.



***

Мәхәббәт ышаныч түгел,
Мәхәббәт уттай каба.
Ышаныч яулап алына,
Мәхәббәт үзе таба.

Ышаныч мәхәббәт кебек,
югалса, эзләмә дә.
Эзләсә, табардай булып
йөрәгем өзгәләнә.

1967.



Тамчы гөл

Тама инде, тама тамчылары,
сулар сибәм, һаман көлмиләр...
Сабый чакта тәрәз төптә елап
утыра идек тамчы гөл белән.

Язлар, җәйләр җитә.
Тамчы гөлкәй,
нигә һаман яшең коясың?
Еллар үткәч, ераклarга килеп,
күрдем менә көньяк кояшын.

Кырым кырларында тамчы гөлләр,
алкалары көн дә ачыла.
Тамар өчен ташлы тавы кирәк
тәрәз төбендәге тамчыга.

1967.

*Масандра**

Мәгънәсен исемеңнең
белмәдем, Масандра.
Гел ачык ишеген,
кайтсам да, барсам да.

Ал, зәңгәр төсләрдән
чуп-чуар яр буе.
Гел монда төшәме
кояшның бар нуры?

Гарәптәй каралар,
бар безнең ише дә.
Кызганып карыйлар
ак тәнле кешегә.

Без Идел ярыннан,
син инде тарсынма.
Узарга сукмак бар,
сыярбыз, Масандра.

Ун кеше урнаша
биш бөртек ташыңа.
Танышлар ашыга
актерлар пляжына.

Билеты булмаса —
я трагик, я комик.

Сәләтле төркемнән
ә без соң ник калыйк?

Смоктуновский белән
бер ташка бассаң да
бер роман, —
китәбез,
бигайбә, Масандра.

Бер дулкын кагыла,
уртак тел табыла
исемсез актерга,
билгесез шагыйрьгә...

Диңгезгә куелган
чикләрне дә уздык.
Су белән жир чиген
узмады бу дуслык.

Йозаксыз, капкасыз,
кайтсаң да, барсаң да
каршылый, озата,
юата Масандра.

Йа, жәннәт шул икән,
туйдыра жәннәтең.
Яшәүгә яхшырак
үземнең Әлмәтем.

1967.

*Масандра - Ялтадагы пляж исеме.

7. Я-547



***

Идел өсте салкын көзге сыман.
Ник ямансу икән бу көзләр?
Тәрәзәне салкын яңгыр кага,
әллә кая китә поездлар.

Тәрәзәне салкын яңгыр чиертә...
Бер сизгере килеп кагуын
юкка көтәм.
Шул поездлар кебек
минем дә бит узып баруым.

Юл кешесе юлда булса яхшы;
калганнарның күңеле калада.
Ярны ярга кушкан саллар булып,
Шпаллар, шпаллар ята арага! —
бер килерсең әле...

1967.



***

Синең янда әле берсе атлый,
әле икенчесе бәхетле.
Берәү генә күңелен биләми дип
шатланырга миңа вакытмы?
Бит мин генә сиңа кирәк идем...
Ни булса да инде узган эш.
Тик бер генә кичлек бәхет белән
Бәхилләнгән кызлар кызганыч.

1967.



***

Сөйләп сүзләр бетмәс сыман иде,
башын иеп калды бер сорау:
Нигә? Нигә җанда чаң кагалар?
Нигә бөтен дөнья сагырау?

Чыбыкларда, телефонда чыңлый
сиреналар — хәвеф матәме...
Сөенечләр төяп килгән идем,
сөендереп бер сүз әйтмәдем.

Сөендереп бер сүз әйтмәдем бит,
нигә шикләр? Ямьсез юраулар?
Китәм. Кайтса, каршысына барып,
баш исеннәр өнсез сораулар.

1974.



Укытучы яшьлеге

Яшь-җилбәзәк чаклар узды, дидем,
журнал тотып кергәч класска.
Ничә язмыш хәзер синең кулда! —
Сыйдыр, күңел, барысын колачака.

Тәрәзәләр чиертеп, яшь егетләр,
чакырмагыз кичке уенга, —
ак кәгазьдә тәүге хаталарны
төзәтмичә калу тыела.

Хәрефләре, кыр кәҗәсе кебек,
сикереп чыга дәфтәр юлыннан...
Җаен табып, юлга кертәсе бар
Һәр баланы, тотып кулыннан.

Йә җыр булам, көйгә кертер өчен
очар коштай нәни күңелне...
Сизелми дә шулай узды яшьлек,
мәктәп шау-шуына күмелеп.

Чынлап баксаң, яшь-җилбәзәк чаклар
бераз соңрак узган икән лә, —

күкрәп торган чәчкә яшьлегеңне
үзең бүләк иткәч бүтәнгә.

Инде кем дә сина тәрәз чиертми,
дәшүче юк кичке уенга.
Аерылгысыз икәү. Башкаларга
урын да юк инде уеңда.

Яшь дусларның күзенә тәүге тапкыр
никтер карый алмыйм тутырып, —
әйтерсең лә изге бу дуслыкка
бер хыянәт эшләп тотылдым.

Җыелышлар, бәйрәм кичәләре
нигытгылар тагын дуслыкны.
Иртә-кичләр бергә. Хәләлемә —
вакытымның калдык-постыгы.

Ә яшь чаклар барыбер соңрак узган:
Синең кулда нәни, нарасый.
Ана түгелә йөзкәеңнең нуры,
ике күзкәеңнең карасы.
Кеше үсә! Күңелең энжеләре
аның күңеленә коела.
Кеше үстергәндә яшьлегеңнән
аерылмыйсың гомер буена.

Мәктәбеңә бер көн бармый торсаң,
үзе йөгереп килә каршына.

Үз баландай газиз болары да —
жаннан аерып булмый кайсын да.

Күп сынаулар бергә кичәсе бар,
канатланып кошлар очканчы.
Тормыш юлындагы хаталарны
сызып кына төзәтеп булсачы!

Алар инде очар кинлек сайлый
син башлаткан дәфтәр юлыннан.
...Яшьлегемне гармунына салып,
әнә, улым
чыгып китте кичке уенга.

Әле бүген генә!
Үзе яңа,
үзе таныш көйләр ишетәм.
Узмаган ул яшьлек. Эше күпкә
сиздерергә генә кичеккән.

Шул яшьлекнең кочагына атылып,
көн дә керәм шаулы класска.
Ялгышлары, шатлыклары белән
сыйдыр, күңел, барысын колачка.

1967.



***

Горур жырлар читлекләрне вата,
очып уза утлы чикләрне.
Сайрар коштай Туган илгә кайта, —
үз илендә жырга чик бармы?!

Байрак булып кулдан кулга күчә,
сыймый җырлар сыйлы табынга, —
сафка баса,
чөнки ул жырларга
күпме ялкын һәм дәрт салынган!
Мылтык көпшәсенә чәчкә кадап,
яңа сафлар жырлап узалар.
Байракларга йөрәк каны тамган,
онытмагыз!
Онытырга кушмый Муслар!

1967.



Туган җирем, эчкән суым!

Әнкәй миңа тәмле-татлы сүзләр
өйрәтмәгән сабый чагымнан,
яратуы күкрәк сөте белән
Һәр балага тигез салынган.

Олы хисләр күңел түрләрендә,
тел очында йөрсә, җил алыр.
Яратуың артык тирән булса,
«яратам» дип әйтү бик авыр.

Авылымны өзелеп сөям, диеп
сөйләп йөрми авыл кешесе.
Чәчә, ура, илне туендыра, —
яратуның шунда көчлесе.

Болыннарым сагына, печән җитсә,
кырлар чакыра урак өстендә.
Печән исе, кара икмәк тәме
канга сеңгән ана сөтеннән.

Басуларның булды көйгән чагы, —
кем кайгыдан качып котылган?

Кырны баскан әрем әчесе дә
күз яшьләре белән йотылган.

Туып үскән җирем, эчкән суым,
сулар һавам — туган як кынам!
Күпме балаң яуда башын салды
шушы жирдә яшәү хакына.

Үлгәннәрнең калган гомерләре
ал таңнарга кушылып кабына.
Туган жир ул кеше күңеленә
ана сөте белән салына.

Тәпи баскан жирем, эчкән суым
кара, акмы,
ачы, татлымы —
бөтен гомерем белән түли алмам
шушы жирдә яшәү хакымны.

1967.



***

Ел әйләнә.
Кыш-җәйләрдә
яшәлгән байтак гомер.
Яшеннән утлар кабынган,
утлардан калган күмер.

Йомшак кар яуган кышларның
ачы җил-бураны бар.
Ут кына күңелемнең дә
бозланып туңганы бар.

Юлмыни йөрмәгәнем лә,
шулмыни күрмәгәнем!
Кай ара ялкын телләре
йөрәккә үрмәләде?

Нигә соң эчәм җилләрне
көйгәнче иреннәрем?
Ник керәм утлар эченә
күргәнче күмерләрен?

Күпмени иккәннәрем лә,
азмыни түккәннәрем!
Ник тагын кышның салкынын
үзәккә үткәрәмен?..

Яшәгән чакта илләрдә,
күтәргән чакта иңнәр, —
и дөнья, шатлык-кайгыңны
чамалап ала белмәм.

1968.



***

Балкыды да сүнде,
яшенме бу?
Күкрәүләре һаман яңгырый.
Күкрәгемә тамды,
яшемме бу?
Әллә инде ләйсән яңгыры?..

Су ерып яз килә яланаяк,
җил-җил итә яшел күлмәге.
Тамчы-алка — минем сөйгәнемнең
яз-сылуга яшерен бүләге.

1967.



***

Бик бәхетле елмаюларынны
әллә кояш үзе урлаган:
Аның йөзен болыт каплап тора
син узганда безнең урамнан.

1967.



***

Тиз узар бу мизгел,
һай, кыска юл.
Бик нечкә бу кыл,
өзелер.
Өзелмә, үс, гөлем,
көз гөле,
түз, гөлем,
суз, гөлем, бу гүзәл мизгелне.

Тылсымлыдыр юл,
һай, моңлы бу кыл.
Яшәп туярга
җитмәс йөз гомер.

1968.

***

Кермим кеше биләмәләренә,
бәлки, анда мәңге җәйдер дә...
Ил күргә чыксаң, азмыни ул
күзне камаштырган әйберләр.

Кермим кеше биләмәләренә,
дөрес, таулар анда мәһабәт!
Күңел омтылышы гел биеккә, —
каян килгән аңа бу гадәт?

Кермим кеше биләмәләренә,
чикләр аша яулык болгама.
Ике ярдан икәү карап йөрик
ташып-шашып аккан елгага.

Бер йөзәсе иде колач салып!
Кулларымны бәйлим ни белән?
Ниятләрем яулап алу булса,
төзәми дә туры тидерәм.

Кермим кеше биләмәләренә,
үз җиремдә ташка таш өям,
мәһабәт тау түбәсенә басып,
мәхәббәткә шуннан баш иям.

1968.



***

Юлларыма якты төшсен дипме,
ут күрсәтеп калдың артымнан.
Синең ният изгеләрдән изге —
ялгыз кеше бизми яктыдан.

Караңгы төн парлыларга тансык...
күңелең болай сизгер булса да,
"Әнә юлың", — диде, мине озатып,
сина аркылы төшкән бусагаң.



***

Тормыш булмый көю-сөенүсез,
яшәү авыр сөелү-сөюсез.
Караңгыда якты караш кирәк,
өшегәндә кирәк жылы сүз.

Төссезләнә кеше, көчсезләнә,
күздән күзгә нурлар таммаса.
Ямьсезләнә кеше, әрсезләнә,
сузган кулын кемдер алмаса.

Таянырга иңнәр табылмаса,
жан яраткан жанга табынмаса —
салкын була жиле, һавасы...
Сөю-сөелү — кара көнчелекнең,
вакчыллыкның иң шәп дәвасы.

1968.



Авыл урамы

Бу урамның һәр түмгәге таныш.
Тәгәрмәчләр эзе көзгедәй.
Көз буена икәү йөргән идек
Ат юлының ике эзеннән.

Нинди уйлар уйлап йөрелгән дә
ничә язлар алда күрелгән?
Без атлыйбыз. Тәгәрмәчләр эзе
тояк эзе белән бүленгән.

Куллар гына кайчак очрашалар,
сикереп чыксаң яңгыр күзеннән.
Сүзләр тынып кала, курыккандай
әллә синнән, әллә үземнән.

Ә бер кичне никтер син килмәдең,
юк-бар сүзләр шунда ишетеп,
озаттырдым күрше егетеннән
әллә нишләп. Сиңа үч итеп!

Капка төбендә дә торган булдык,
мин гел юлга карап уфтандым.

Кинәт атың, йөгең белән үзең
безнең турыга килеп тукталдың.

Ул чакларда атлар арык иде.
Көзге юлда син дә жәл идең.
Әллә нәрсә булды телгә генә —
сорашмадым хәтта хәленне.

Ә син киреләнгән ат тирәли
бер әйләндең, ике әйләнденең.
Безнең янда гына кырт өзелгән
камыт бавын ялгап бәйләдең.

Тешең кысып, ахры, бәйләгәнсең,
сыкрап калды койма-капкалар...
Шуннан китте атың, китте, китте
без хыялда күргән якларга.

Сөрлеккән дә юлда, өрекмәгән...
Холкыгызны мин бит беләмен.
Безнең турыга житкәч, атың һаман
туктый, диләр.
Кысылып куя менә йөрәгем.

Атыңны син һаман куасындыр,
югалыйм дип тизрәк күзеннән...
Көзге юлда тәгәрмәчләр эзе
Калмый бара тояк эзеннән.

1968.

***

Ялгышым дип уйласам да,
язмышым булды бугай...
Ничаклы сөенеч алып,
һавадан төште тургай.

Кайларга җитә бер очы
салават күперенең?
Шул аллы-гөлле юлларда
җитәкләп йөртер иден.

Мин китәм әле.
Күперем —
очланмый калган җырдай.
Җирдән бер сөенче алып
менәр бит әле тургай.

Күкләргә өмет баглаучы
болай да күптер инде, —
төшерим җиргә бер очын
салават күперенең.

Күпернең ике очында,
җирдә, күктә — без икәү!
Ялгышым дип уйлап йөрдем,
язмышым булган икән.

1968.



Уфа - минем яшьлегем

Әллә күрәчәгем монда,
әллә киләчәгемме?
Уйларым артыннан мин дә
Агыйдел кичәм инде.

Йолдызлы күктәй яр өсте,
килсәң дә кайсы яктан.
Аста кар ята, ә өстә
чияләр чәчәк аткан.

Ярлары текә, яралы
убылган упкыннары.
Ургылган дулкыннарыдай
чыңнары, һай, моңнары.

Яшерми кеше күзеннән
яшен дә, яшенен дә...
И Уфа, минем яшьлегем
бит синдә яшеренгән.

Бакчадан килеп чыгар күк,
кош булып кунар сыман.

Мин аны саклармын әле
хәерсез сунарчыдан.

Урамда утлар җемелди,
әле таң атмаган да.
Кемнедер көтеп, әллә соң
бөтенләй ятмаганнар?

Тәрәзә гөлен, җил генәм,
шулчаклы бөгелдермә.
Берәүнең мине өзелеп
көтүе түгелдер лә?

Җил искән саен гөл үскән
бу кемнең юлларына?
Агыйдел дулкыннарыдай
җырлары, моңнарына.

Сибелсен җиргә, кадыймчы
мин дә бер чәчәгемне,
и Уфа, үткән яшьлегем,
яктырт киләчәгемне.

1968.

Йөгереп каршы чыксам

Ярата дип уйлый күрмә тагын,
юк, син түгел миңа кадерле, —
сине күргән саен, бар дөньяга
гашыйк чакларымны хәтерлим.
Ярсуларны эчтән тыеп кына
карап тордык елга ташуын.
Бергә күрдек япь-яшь бөреләрнең
кыяр-кыймас керфек ачуын.
Һай, күкләрнең язгы күкрәүләре!
Бу дөньяның зәңгәр сафлыгы!
Шәфәкъларның кайнар кочагына
керелмәгән шунда атлыгып...
Син яратып инде аргансыңдыр,
калганнарга сагыш таратып.
Ялганнардан качып, бер кайтып кил,
яшьлегеңнең җигеп пар атын.
Йөгереп каршы чыксам, уйлый күрмә,
гашыйк икән, диеп, һаман да;
юк, мин түгел —
таңнар шулай алсу,
шулай якты зәңгәр һавалар.

1968.

***

Тагын узды кыңгыраулы язлар,
чылдырдатып чәчкә чукларын.
Беләсеңме, кәккүк, бу юлларның
кайда җитеп, кайчан туктарын?

Юк, әйтми тор әле, чү, әйтми тор,
гомер елын бик аз санама.
Сабый чактан көткән ал җилкәндәй
җәйге таңнар һаман аллана.

Килә дә ул, китә. Ә мин һаман
зәңгәр ярга барып җитмәгән.
Күңелемдә йөрткән сүзләремне
кулъяулыкка әле чикмәгән.

Тагын узды кыңгыраулы язлар,
чылдырдатып чәчкә чукларын...
Ә мин төне буе яулык чигеп,
каршыларга таңны чыкмадым.

Каедым да сүттем.
Сана, кәккүк,
ничә жебем актан, карадан.
Диңгезләргә киткән жилкән кебек,
кайтмасмыни таң да яңадан?

1968.



***

Мәхәббәтне тирән яшерәләр,
сиздермәслек итеп беркемгә.
Тирәнәйгән саен, аның нуры
керфек очларыннан сирпелә.

Нәфрәтне дә кайчак качыралар, —
кирәк чакта үзе бер һөнәр.
Ә керфекләр —
күзләр коесында
елкылдашып торган сөңгеләр.

1968.



***

Ачкыч табып,
күңеленне
үзем ачам, дисеңме?
Ачтырмасаң, бикле килеш
алып качам, дисеңме?

Мөлдерәмә күңелемне
түкми күтәрерсеңме?
Таштан каты,
кылдан нечкә —
ватмый эретәлерсеңме,
өзми үтәлерсеңме?

1968.



***

Үзем сөяр идем,
берәү сине
өзелеп яратканын белмәсәм.
Тагын берәү сине шулай сөйсә,
бәхетең артык булыр,
көнләшәм.

Ут йотсам да,
салкын су эчәрмен,
сиңа кабынмасын ялкыным.
ярсуларым тулып ургылсын да
җырга күчсен!
Көтмим артыгын.

1968.



Каен

Бүлешик әле кайгыны,
ак каен, сары толым.
Саргая торган аең бу,
сагына торган елым.

Кем өчен сүтеп тарадың,
ак каен, алтын чәчең?
Иренемә төшеп эреде
гәрәбә кебек яшең.

Җилләр дә сиңа елыша,
һай зифа, сылу каен.
Башыңны идерсәләр дә,
сынма син, сылукаем.

Сөйләшик әле серләрне,
ак каен, сары сагыш.
Сагынуны басар җырларны
син табыш әле, табыш.

1968.



Марина Цветаевага

Кометалар юлы - шагыйрь юлы...
М.Ц.

Ачтан интеккәннең арыклыгы,
симезлеге артык тукларның —
синең дошман.
Шул дошманга атты
революциянең туплары.

Син канатлы —
күз-колагың каплап,
чит бер җисем булып олактың.
Эзли идемени синең йөрәк
яшерен яшел почмак —
ерак, тын?..

Ерактагы ватан — җан ярасы...
Тук тынлыкны ярган, кыйраткан
революциянең утлы шары
кояш булып чыкты ерактан.

Ә кояшта таплар
чит күзләрнең
күзлегеннән кара күренә...
Юлдаш булсаң, йолдыз булыр идең
туган-үскән илнең күгендә.

Горур киңлек,
хозур биеклектә
шагыйрь итеп Рәсәй үстергән.
Шагыйрь күңеле,
кометалар кебек,
парашютсыз очты йөзтүбән!

Туган туфрак,
кара икмәгеңнән
киселгәнме сыныкмы —
киселгән!
Орбитадан чыкса,
үзен тарткан
җиргә бәрелеп яна җисемнәр...

1968.



***

Әй солдатлар,
тигез, кыю басып,
үтмәгезче безнең урамнан.
Кирза итек, иңбашларда мылтык, —
артыгыздан калмый оланнар.
Яңартмагыз утлы еллар җырын, —
улым үсеп килә, улым...

Әй солдатлар, сез атлаган чакта
тынып торсын шаулы урамнар.
Адым тигез, балкый кызыл йолдыз, —
сезгә тигезләнә оланнар.
Һай, күп әле җирдә җәбер-золым...
Улым үсеп җитте, улым.

1968.



Мәкер

Күз алдыма кара елан булып
килә иде мәкер элгәре.
Моңа чаклы ничек белмәгәнмен
аның битлек киеп йөргәнен.

Битлекнең дә кияр гел яңасын,
чакырганны көтмәс, килгәләр.
Авыр чакта, йомшак куллар булып,
чәчләреңнән сөеп иркәләр.

Көчле булсаң, ярлы ялгыз хатын
иңнәреңә кайгы бушатыр.
Кырыс булсаң, моңлы җырлар булып,
күңеленне тәмам йомшартыр.

Йә килер ул сылу яшь кыз булып,
күз яшьләре мөлдерәп тамарлар, —
Йөрәгеңне эретеп үткәч кенә
кара елан булып чагарга.

Ничә тапкыр күңел тәрәзәсен
танымыйча ачтым мәкергә.

— Ышанмагыз моңлы-зарлыга, — дип,
телем бармый ләкин әйтергә.

Гөнаһсыз җан, бәлки, чын булыр да,
кабатланмас моңлы җыр булыр?
Инде чагылып беткән йөрәгемнең
югалтуы тагы да зур булыр.

1968.



***

Матурлар — батырлар, —
алынмас кыя юк,
Алган — шатлык,
калган — артык,
бәхет бар, хыял юк.

Матурлар — ут-ялкын,
яратсаң — янарсың.
Килгән — янган,
киткән — ялган.
Ялгызлык, ямансу...

1968.



***

Сузган юллар, аккан сулар белән
уза тора еллар, гомерләр.
Юл тузаны каба сулышына,
су юшкыны куна күңелгә.

Тузан кагып кайчак көнең үтә,
вакыт уза юшкын актарып.
Сагынасызмы сез дә
өметләрнең
бары да алда, бары да әле жанда —
кер куналмас якты чакларын?

1969.



***

Әйләнәм дә киләм яр буена,
салкын бәрә Идел суыннан.
Кар суында эзләр җуелганда,
күңелләрең әллә суынган?

Кош юлыннан очып килдем дә бит,
кышын йөргән юллар өзелгән.
Язлар алып киткән эзләреңне
эзләп йөрим хәзер Иделдән.

1968.



***

Бөтерелә, бөтерелә карлар,
кышлар уза, кичләр буранлый...
Эх, ышаныйм әле Уралыма,
бураннарга кереп уралыйм.

Киләчәгем миңа килми калмас,
үткәннәрне уйлап үкенмим.
Бар дөньяның бер аклыгы белән
ераклыгы калыр бу көннең.

Бер ышаныйм әле бураннарга,
үз-үземнән китеп югалыйм!..
Ерагая барган якыным син,
ялкыннарга салган ерагым.

1970.

Этюд

Буш урамда
ак буранда
җитәкләшеп икәү бара.
Тәрәзәләр нурлы икән,
баганалар чыңлый икән,
таш урамнар җырлы икән,
чынмы икән?

Җитәкләшеп икәү бара,
эзләренә ак кар ява, —
эзләренә кер кунмасын,
җил тимәсен,
суынмасын.

Шул эзләргә кире кайтып,
берсе, бәлки, яшен түгәр.
Ак эзләрне,
пакъ эзләрне
икенчесе килеп үбәр, —
кер кунмасын,
җир туңмасын.

Буш урамда
ак буранда
җитәкләшеп икәү бара.
Эзләренә ак кар ява.

1970.



***

Кем әйтә сөю ләззәт дип?
Дөресе, сөю — газап.
Йөгәнен өзгән йөрәгең
әллә кол, әллә азат.

Ут белән су арасында
тукталыр нокта эзләп,
үрсәләнә, өзелә үзәк.
Дөресе, сөю — бизгәк.

Үз-үзеңне югалтуың —
мәхәббәтне табуың.
Йомарлап йөрәккә салган
ожмахың бу, тәмугын.

1970.

IV бүлек

Имсынган да, очынган да чаклар...





***

Имеш, йомшакмын да мин, бик юашмын...
Аһ, балкып чыкты минем дә кояшым!
Алдан мин күрдем — уяндым иртәрәк!
Кызганмыйм сездән — кояш бит түгәрәк.
Сөенегез, сыенығыз — кем ялгыз?
«Үземә генә», — дип, чур! Кул сузмагыз! —
Сүнәрмен! Аның белән бергә генә!
Нурланып янган кояш — йөрәгемдә.

1969.



***

Үз йолдызым
бәхетемә
соңлаган, диләр. Ялган! —
Ул минем өчен кабынган,
гел минем өчен янган.

Һәркем эзли үз йолдызын,
мин дә таптым, ахрысы.
Ах, җиргә шул
озак килә
йолдызларның яктысы!

1969.

Син якты булсаң, киләчәк

Сөрә беләм, ура беләм,
үрә беләм, чигә беләм —
кулымда уйный эшем!

Әкиятне чын итә алам,
тормышны жыр итә алам,
киләчәк, тагын нишлим?

Кыйгач кашым күз өстендә,
ай булыймсы күк йөзендә
туар гашыйклар өчен?

Киләчәктән хәбәр килде:
«Балкырга теләүчеләр күп,
барысын да кабул итмәс күк —
син туфрак бул, и жисем,
жир шуннан алган исем».

Син якты булсаң, киләчәк,
өстемдә үсәр күк чәчәк...
Чәчәккә башын иячәк
тормышка гашыйк кешең!

1969.



***

Килешле кара күлмәгең,
и кара күзле кыз бала.
Бар икәненне белә идем,
ә күргәч, күңел сызлана.

Яулыгың кызыл керешле,
Әнкәннән тигән өлешме?
Каралы күлмәк килешле,
Караңгы чырай килешми.

Аклыдан минем күлмәгем...
Карлыгач икән яр-кошың.
Сезне пар кош дип белмәдем,
төшмәсен миңа «каргышың».

Аклыдан минем күлмәгем...
Күк томан минем күзләрем.

1969.



Бер генә гомер аз икән

Әйтә килде күрше-күләп:
— Соңга калып суга төшмә.
Киңәш бирде белгән-күргән:
Сусап, салкын сулар эчмә.

Чишмә ага чылтыр-чылтыр.
Күрәчәгем шулдыр, шулдыр.

Чылтыр-чылтыр көтеп алды,
кулым тиде — өтеп алды.
Су чәчрәде, сөртәлмәдем,
яулыгымны бөркәнмәдем.

Чишмә ага чылтыр-чылтыр.
Халык сүзе чындыр, чындыр.

Суын эчми түзәлмимен.
Колач салып йөзәлмимен.
Җитәлмимен очларына.
Җәйләрен дә, кышларын да,

Чишмә ага чылтыр-чылтыр,
төпсездер ул, чиксездер ул.

Ник элегрәк эзләмәдем, —
тау-ташларны кисмәгәнмен.
Бер генә гомер аз икән,
уза икән, сизмәгәнмен!

Чишмә ага чылтыр-чылтыр,
җырлый-җырлый: чындыр, чындыр...
Чындыр.

1968.



Безнең якта

Безнең якта таулар күккә якын.
Җыр җырласаң, күпләр ишетә.
Таудан тауга,
ярдан ярга яңгырап,
кайтавазлар аны ишәйтә.

Үзән якын җирнең үзәгенә.
Бер җырласаң, кырлар тын кала.
Колак салсаң,
җиде катлам җирнең
кан тибешен була тынларга.

Үзәннәрне айга якынайтты
тизлек каны — девон төбеннән.
Илем! Әле күпме җан байлыгы
тыйнак тынлыгыңа төренгән!

1969.



***

Бергә чакта каен утын яктык.
Син китәсең —
калдым усакка.
Эх, бер балкып калсын әле яктым! —
Балта сабын салдым учакка.

1969.



Улыма

Минем кулдан синең кулга
күчте туплар, шарлар, —
күк шикелле зәңгәрләр дә,
таңнар сыман аллар.

Олылары, кечеләре, —
тәгәрәт тә очырт!
Туплар тәгәрәшеп китте,
шарлар бетте очып.

Таңнар һәрчак алсу булыр
күкләр зәңгәр чакта.
Җир шарын бирәм кулыңа,
ычкындырма, сакла!

1969.



***

Ераста чакта — йөрәктә,
янымда чакта — жанда.
Йолдызым — көзге кичләрдә,
кояшым — язгы танда.

Күк зәңгәрләре серлеме,
таң алсулары чынмы?
Йөрәктә сакланасыңмы,
янымда каласыңмы?

1969.

***

Киттең.
Юлларда бозлавык,
Бозлавык, тайгалаклар ла, —
туңган туфракның сызлавы
сыкрап менә аякларга.

Көттем,
туң тәрәзләрне
сулышым белән эретеп.
Йоттым күз яшьләремне мин,
сагынуларымны сер итеп.

Иртә-кичләрне бер итеп,
туңалармы, яналармы, —
тынмыйлар,
зынлый, чыңлыйлар
телеграмм баганалары!

Кайттың...
Кар төшә, кар ява! —
Җиркәем, төрен юрганга.
Эссе дә, салкын да буран,
шушы кичтә югары очта —
Авылда син булганга!..

1969.



Кичүләр юк икән язларда

Кар сулары ярсып, ярлар тула,
кошлар кайта урман буена.
Ярлар тулган саен, күңелкәем
тулып түгелер сыман тоела.

Кар суында аккан ак яулыгым
тап булганмы киек казларга?
Мәхәббәтең язгы ташкыннардай!
Кичүләр юк икән язларда.

1969.



Төш

Чәчләреңнән үбим, керфегеңнән.
Маңгаеңнан үбим, чәченнән.
Бар сәгатьләр җирдә туктаганнар,
бар вакытлар шунда өзелгән.

Уйларымны салыйм күкрәгенә,
үрелсеннәр шатлык-кайгылар...
Бөдрәләрен җилгә сибелдергән
ак муенлы сулы каеннар

баш чайкыйлар... Аздыр бу мизгелләр,
санаулылар, азлар бәхетле.
Өзеләсеңме, төшем, сузыласыңмы,
бар вакытлар җирдә — вакытлы.

1969.



Илһам

Тын елгалар тынгыларын
мәңгегә югалттылар.
Дулкыннар ярларны кагып,
тауларны уяттылар.

Бер генә тамсаң таңнарның
юлларына нур булып,
бер яңгырап алсаң, заманның
күкрәгендә җыр булып,

ни кирәк шагыйрь кешегә —
әманәтләр үтәлгән.
Юллар бара, җырлар яңа.
Еллар кала бүтәнгә.

1969.



***

Артта — җиңүле юл,
алда — зур эшләр.
Йөктә уңышлар мул,
көтә бурычлар...

Җиңү — җайдаклы ат,
эштә — җигүле,
уңышларны тарта,
белми чигенүне.

Җилләр — кылычлар да,
еллар кырыслар.
Җирне гөл итәсе
олы бурыч бар.

1969.



Киләчәгең килә үткәннәрдән

Киләчәге белән тормыш якты,
үткәннәре белән кадерле.
Үткәннәргә берсе таш ыргытса,
җәберләнер әткәм кабере.

Чабаталы надан мужик, димсең,
изүен дә каплый алмаган?..
Шул мужиклар, күкрәк какмый гына,
без яшисе җирне яулаган.

Маңгаенда янган кызыл йолдыз
кара авыллarны уяткан.
Ул елларда таң да шытып чыккан
кан аралаш кара туфрактан.
Туар таңнарына тап тидерер
үткәннәргә саксыз таш аткан.

...

Яшьтәшләрне хурлап сүз әйтсәләр,
шәүлә төшә минем битемә.
Кызыл сүзләр, имеш, бик мул сипкән,
туймаса да кара ипигә...

Үлгәндә дә «ура» белән үлгән —
син бәллүдә әле ятканда.
Чордашларым,
янган утка кереп,
бәллүеңне уттан каплаган.

«Кызыл» диеп утлы чор сүзләрен
хурламагыз, килер буыннар!
Алар
көлгә калган калаларны
тергезгәндә очкын булдылар.

...

Хәнҗәр булып керә йөрәгемә
өметсез сүз яшьләр хакында:
алар күкрәгендә минем каным!
Без хак булсак, алар хак юлда.

Дары исен иснәмәгән, имеш...
Сугышмы соң ин шәп чыныгу!
Хыялында янган ай-йолдыздан
яңа кояш ясар оныгың.
Син башлаган юлда күпме рәхмәт,
юкмы нәләт — яшьләр хәтерле.
Яман атың белән абынырлар.
Яхшы атың үтәр әмерне.
Үткәннәре белән тормыш якты,
киләчәге белән кадерле.

1969.



***

Кага да кага бу йөрәк,
чик-чамасыз көче бармы?
Суга күкрәк читлегенә, —
читлекләрдә үче бармы?

Йә көтәме аргамагым
алда чабыш мәйданнарын?
Чикләрне ват инде, беләк, —
кага да кага бит йөрәк.

1969.

Яз килә

Кышлый ул нәни бөреләрдә,
яшь көе яши күңелләрдә, —
яз иңә җирнең сулышына,
яз куна кояш чыгышына.

Адымы —
йөрәк тибүендә.
Ягымлы —
кызлар көлүендә.
Яз килә!
Хәбәрдар һәр аваз!
Яз көләч,
тәрәзәң киңрәк ач!

Яз килә кошлар канатында,
яз көләч дуслар карашында.
Ярсуы агым суларга хас.
Җилкенеп искән җилләрдә
наз...
Алтын нурлар уйный —
алтын таж.
Җирдә патша бүген
якты яз!
Бозларны кузгатып,
төннәрне кыскартып,
яз килә,
яз!

1969.

Язгы күкнең йөзе кояшлы

Быелгы кыш артык кырыс килде,
язлар шуңа бигрәк сагынылган.
Песнәкләр, әй, сөенеп, тирәкләргә
сары алма кебек сарылган.

Кояш, саумы!
Кояш һәрчак көләч.
Кырлар менә ничек кышлаган?
Яшел ужымнарга ак юрганын
ябып җиткермәгән кыш бабаң.

Ахры, артык комарланып киткән,
«Күрегез, — дип, — минем холкымны!..»
Агрономның йөзе болытлы.

Яшәртер лә иде ужымнарын,
күзләренең түгеп карасын!..
Елмаясың, кояш.
Игенчегә
кабат буразналар ярасы.

Табигатьнең салкын карашыннан
бөгелеп төшәмени ир башы?!
Барыннан да көчле
яшәү көче!
Көчләрнең юлы кояшлы.

1969.



И кызлар, и хатыннар...

Сагышым үксез —
далада аунап елардай булам.
Кычкырып, үксеп еласам,
акылдан язган диярләр.

Шатлыгым чиксез —
дөньяны кочып
жырлардай булам.

Ярларны ярып жырласам,
бу тәмам азган диярләр.
Без шатлансак,
керфекләрдән нур тама,
нур сирпелә,
кем очраса, шул күрә.
Кайгыбызны кем белә?
Керфекләр жиргә иелә,
күз яше жилгә сибелә.

1969.



***

Нәкый Исәнбәткә

Даулы еллар күкрәп, шаулап узды,
чәчләреңдә челдәй чал гына.
Әйтче, нигә шулай егет-кызлар
гөл сибәләр синең алдыңа?

Әллә ат уйнатып, су буйлатып,
ерак сәфәрләрдән кайттыңмы?
Илдән-илгә, телдән-телгә күчкән
энже-җәүһәрләрне таптыңмы?

Кем исеменә җырлар жырласаң да,
һәр күңелгә алар замандаш.
Ай-урагын кулбашына салган
уракчы кыз әле һаман яшь.

Гомереңдә буе җыйган җәүһәрләрне
кызлар чулпы итеп чыңлатыр.
Юлларыңа шуңа гөл сибәләр:
исеме жырга кергән — чын батыр.

1969.



Учак

Төн эчендә дөрләп учак яна.
Төрле серләр сөйләп, озак яна.
Юлчы, утка салып ярсу жанын,
көтә микән жәйнең алсу таңын?

Сызылып таң беленер, бу төн узар,
иңрәп калыр көлдә утлы кузлар.
Юлчы китәр. Ә син сүнмә, учак,
якты йөзең белән юлга озат.

Көл-күмергә калып янар эчең...
Учак — уйлар, ә таң — юллар өчен.
Юллар үтә, максатына житә,
уйларына кайта, кайта кеше.

1969.



Җир әйләнә

Тынычлык юк бу күңелгә,
тынычлык юк.
Анда тетри, монда күкри
жир дә күк.
Йолдыз атылганда кеше
теләк тели.
Ниятләр күп. Уртак теләк —
иминлек.
Жир кабуллый файдага да,
зыянга да
кеше акылының
яңа ачышын.
Тынычлык юк бу дөньяга,
тынычлык юк.
Дөреслекнең кайсы шикле,
кайсы чын —
күрә-сыный кояш йөри,
шушы жирдә
гөрләсен дип тормыш,
күпме көч сарыф!
Кем нур сипсә, кем тир түксә, —
шуның кулы

әйләндерә җир шарының
күчәрен!
Урак-чүкеч тоткан куллар
алып бара
киләчәккә кешелекнең язмышын.
Тынычлык юк бу кулларга.
Дөреслек — бер! —
Үтерешеп түгел,
яшәп ярышыйк!
Төзеп, бизәп,
очып, узып!
Бәндәләрне
кеше иткән хезмәт белән
киң хәят.
Дауда, яуда вөҗданнарын
канга буяп,
кешеләрне ерткыч итү — җинаять!
Тынычлык юк бу дөньяда,
тынычлык юк.
Анда тетри, монда күкри
җир дә күк.
Җир әйләнә. Күрә-сыный
кояш йөри:
җир күчәрен кулыбыздан җибәрмик!

1969.



Чәчләреңне җилләр тарый

(Җыр)

Чәчләреңне җилләр тарый,
көнләшәмен җилләргә.
Ә мин һаман сүзләр сайлыйм
хисләремне сөйләргә.

Уйларыма ураласың
үрмәле гөлләр сыман.
Ураласың, югаласың
җырланган җырлар сыман.

Сине сагынып, ераклардан
кайттым туган илләргә.
Чәчләреңне җилләр тарый,
көнләшәмен җилләргә.

1969.



Чаңгыда

Көн кояшлы. Кар өстенә
йолдыз коелганмыни!
Чыршы-каен ак киемнән
туйга җыенганмыни!

Әкияттәге тылсымчыдай,
син шулар арасында.
Тау жилләре сызгыралар,
чаңгылар-канат синдә.

Чәчләреңә бәсләр кунган,
Карбизәкләр җилбәзәк.
Елмаеп әйткән сүзләрең
әллә чын, әллә мәзәк.

— Ак бәхетләр өләшәләр
Актүбә каласында.
Ризамы, шунда очабыз
мәхәббәт канатында?

Кашларында карбизәкләр,
тирбәндереп жил исә.

Кыш кабынган ут-ялкынны
жил сүндермәс югыйсә.

Иңнәренә кул салалмыйм,
кар сибеп кагыйм әле.
Сөйләсә, кеше сөйләсен,
яр сөеп карыйм әле.

1964.

***

Яшьлек, гомерең кыска синең...
Һ.Такташ

Яшьлек, гомерең кыска —
ашык!
Кояш уянмастан юлга чык.
Тамчы чык та калмас синнән качып,
бер гашыйк та йөрмәс адашып.

Табигатьнең гел шәүләсез чагы,
бер хәйләсез ачык кочагы.
Жил алмаган әле чәчәк исен,
чирәмнәрнең ачык яшел төсен
капламаган әле юл чаңы.

Төш авышкач, төшә якты күлгә
ак каеннан кара күләгә.
Кызыл чәчкә алса күз явыңны —
табигатьнең авы-алдавы бу, —
күз тимәсен зәңгәр гүзәлгә.

Чын төсләрне таныйм дисәң —
ашык!
Кояш уянмастай юлга чык.
Гөлләр сина бер хәйләсез ачык.
Гел шәүләсез гөлгә син гашыйк.

1970.



***

Чикләүләр, читләтүләре! —
Бер кыюга мең тыю...
Ах, әллә сиңа рәхәтме
кеше жаннарын кыю?

Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә,
урталыгың — үртәвең.
Ах алла, мин үталмыймммы
болгап күлмәк итәген.

Яратуың чыннанмы дип,
әлләме соң сынавың?
Ах алла, мин көталмыймммы
сабырлыгың сынганын?

Каф тавыдай таш кыя мин!
Күзләреңдә, ah, давыл...
Ах, әллә миңа рәхәтме
эчтә дулкын саклавы?!.

1970.



***

Китәрмен дә, үтәр, бетәр, димсең?
Оныталмассың әле ялгыш та!
Ак каенлы айлы кичләреңне
көз урармын сары сагышка.

Күз алларың һаман томалармын
иртән томан булып, кичен — кар.
Чын дусларны оныта йөргәннәргә
һич онытылмый торган үчем бар.

1970.



***

Киткәннәрнең юллары озын,
көткәннәрнең көннәре озын.
Йөргәннәргә ачыш-табышлар,
көткәннәргә — сагыну, сагышлар.

Сагыш коесыннан су эчим,
сөйгәнемнең юлларын үлчим.
Янадыр ул. Бәлки тунадыр,
эчеп бетералмыйм шунадыр.

1970.

Хәсән Туфанга

Кайсыгызнын кулы жылы?
Бәйлисе бар йөрәкне...
Х.Т

Чал башыңны кайгы-хәсрәтләрдән
аралыймчы, остаз, аралыйм.
Йөрәк җәрәхәтен бәйләр өчен
жылы куллар бездә бар әле.
Бәйлим әле, бәйлим, оныттырыйм
вокзалларда туңып йөргәнең...
Чү! Чүкечләр чыңы - кан тибешең,
әй, бәйләрне өзә йөрәгең!
Яшьлегенә әйди Урал тавы —
ике материкның капкасы.
«Үткәннәрне бирмә ятларга!» — дип,
киләчәктән дәшә Такташың.
Кызыл ялкын — Урал домналары
жырларына кайтып яналар.
Утлар белән бергә йөрәгең яна,
янгыннары жирнең яңалар.
Ут эчендә Алиш, Җәлилләрнең
гомерен өзгән балта елкылдый.
Жир яралы, ил хафалы чакта

әрнүләрдән ничек аралыйм?
Җылы куллар гына җитми, дуслар,
бәйләр өчен җитмеш яраны.
Ир кайгысын баса ил шатлыгы,
Биләүләргә бирмә йөрәген!
Изүеңне егетләрчә ачып,
дөньябызны ваклыклардан арчып,
арабызда, Туфан, йөр әле.

1970.

***

Ренат Харисовка

Түбәннәнме, өстәнме бу аваз?
Яшенли дисәң, көн аяз.
О, Харисов, мәргәннәр варисы!
Аттың, шартлаттың акылың дарысын.
Берәүләр ишен тапты,
берәүләр — мишень.
Берәүләр тишек эченнән эзли
дарының төшен.
Ә мин телим:
мәргән
егет булса, атка атлансын,
чапсын, чапсын да,
җир ярасына сөрлегеп, каплансын.
Күзеннән сыек тоз түгел,
ачы яшь аксын.
Җир исен танып, җәяү атласын.
Турылыкны, ныклыкны сөя бу ат.
Кылычсыз кыны өчен аттан оят.
Ул бит гади ат түгел, әдәби ат.
Танысын ат мәргәнне,
чын хуҗасы итеп танысын иде!
Китүендә, ахры, кайтуын сагынам —
Ah, ул хәзер үк миңа тансык инде.

1970.

Янган-тау

И, Янган-тау, Янган-тау,
утлар, бозлар яуган тау.
Кыя ташта карт имән
аягүрә янган тау.

И, Әман тау, имән-тау,
яманнарны жиңгән тау.
Сихәт эзләп жанына,
мосафирлар килгән тау.

И, биек тау, киек тау,
ярдан ташлар орган тау.
Кояш нурын үргән тау,
алтын чатыр корган тау.

И, Янган-тау, янгының
йөрәкләргә күчкән тау.
Изге сулар эчкән тау,
Йөрүзәндә йөзгән тау.

Тик... Янган да янган тау,
сүнмәгән тау, кайнар тау!..
Ни кичереп, тетрәнгән,
ялкыннарга тарган тау?
И, Янган-тау, Янган-тау...

1970.

Бәби туенда

(шаяру)

Сездә көзме? Бездә көз.
Бездә малай, сездә кыз.
Уйлашырбыз, сөйләшербез,
Туйлашырбыз сез дә без.

И, нинди үкенеч —
бездә ике, сездә өч.
Безнең егетләр җитмәсә,
илдә егетләр күп ич.

Тусын, тусын, кыз тусын,
дөньялар имин торсын.
Улларым исән булсалар,
үземә алам берсен.

Шатлыгы казна булсын,
кайгысы азга булсын.
Сездән кыз, бездән ул,
бездән аяк, сездән кул.

Сездән үрдәк, бездән каз,
сездән муен, бездән баш.
Бездән теләк, сездән бүләк.
Сездән иләк,
сездән чиләк,
сездән җиләк,
бездән терәк.

1970.



***

Күңел серен аңа күпләр ачты,
«Сөям, көям, үләм...» — диделәр.
Әмма «Сине сөям» — димәделәр,
бүтәннәргә гашыйк иделәр.

Түкми-чәчми тау-тау серләр саклый
дус гашыйклар китереп өйгәнне.
Тау астыннан бәреп чыгар кебек
арадан бер аңа дигәне.

1970.



***

Телим сиңа яшел җәйләр,
ап-ак карлы кышлар.
Кышларында, җәйләрендә
кызу, кайнар эшләр.

Шаулы көннәр телим сиңа,
айлы төннәр телим.
Тагын ниләр телим сиңа,
күпне күргән Җирем?

Телисеңме тыныч йокы
һәм хәерле иртә?
Бу теләкне һәр баланың
чын теләве җитә.

1971.



Салават һәйкәле

Туктаган тик бер минутка.
Ярда ярсу чаптар ат.
Җәядәй тартылган нукта.
Салават батыр — уктай.

Очарга әзер томрылып,
керергә әзер утка!
Минутны өзмә, сыбайлы,
бер минут, узма, тукта...

Батырлык — утка керүме? —
Ялмарга әзер ялкын!..
Күрергә шушы мизгелне
җыелган яше-карты.

Тынлыкны өзеп, ак ярдан
сикерәмсең, Салават?..
Зәңгәр күк — төпсез упкындыр,
син күрәмсең, Салават?

Тартылды нукта. Яр тынды.
Өркеп очты ярканат, —

Салаватның камчысыдай
кан йөгерде аркама! —

Каранса алды-артына,
шул да буламы акын?
Суларда батмый яктылык,
утларда янмый ялкын.

Тукталган тик бер минутка, —
күк күкри, чыңлый һава!..
Салават күпере төшә
ул баскан кыя тауга.

1971.



Шигърият язы белән

Без китәбез, сез каласыз дип җырлармын,
Җәсадемне туфрак белән күмгәндә дә.
Г. Тукай

Күпме килде, күпме китте
шагыйрьләр дә җырлары.
Тукай аһәңнәрен отып
калды Кырлай кырлары.

И мөкатдәс моңлы сазы
һәркемнең күнелендә.
И туган тел, и матур тел —
халкымның гомерендә.

Җыр булса да, сын булса да —
һәрвакыт шагыйрь тере.
Тукай күзләре —
халыкның
ташка уйган хәтере.

Бу заманда шатлыклар да,
кайгылар да кискенрәк.

Көч күбрәкме, хис кимрәкме,
санмы, җанмы өстенрәк —

хәстәрли, сыный күк шагыйрь
кичен дә, иртәсен дә.
Дөньяның кайгы-шатлыгы
калганнар җилкәсендә.

Шул йөкне күтәрешә ул
шигърият язы белән.
И туган теле белән дә,
и моңлы сазы белән.

1971.



Җырчыларның зәңгәр күгенә

Сибгат Хәкимгә

Май күгенең зәңгәр гөмбәзендә
ай дугасы — алтын беләзек.
Сандугачкай сайрый үзәк өзеп,
кунган тал чыбыгы, ай, нәзек.
Жилләр исте, сандугачкай очты.
Ай-беләзек таңда югалды...
Былбыл жырын салдың йөрәгенә,
иннәреңә — утлы Дуганы.
Була микән жырсыз заманалар?
Һәр хәрәкәт жирдә аһәңле.
Жәһәннәмгә барган чагында да
жыр озатып бара адәмне.
Дугаларда кыңгыраулар доңы,
дагаларда корыч очкыннар!
Жәйге күкнең зәңгәр гөмбәзеннән
бар йолдызлар гүя ычкынган, —
кем каберенә, кемнең күкрәгенә —
һаваларда йолдыз ничәдер...

Шагыйрьләрнең зәнгәр күгенә дә
утлар кичеп кенә күчәдер.
Син атлыйсың ташлы юллар буйлап.
Һәр хәрәкәт җирдә аһәнле.
Җирдә утлар сүнми,
күктә — йолдыз.
Тормыш бирә җырга бәһане.
Күзең йомсаң,
төнлә
түшәгенә
куе томан булып уй ята.
Май аеның җырчы сандугачы
төшләрендә сайрап уята.

1971.



***

Тагын язлар килде,
ярсу язлар!
Актарылды бозлар елгада.
Жир яшәрде,
язгы бу яшеллек
яшьлек булып инде дөньяга.
Тагын казлар кайтты,
киек казлар —
кыйгак-кыйгак — кыеп ак юллар.
Умырзая шаһит —
бар мон-зарлар
кар сулары белән актылар.
Алсуланды йөзләр!
Сиздегезме —
кызлар көлүендә — яз чыны.
Күк күкрәве шаһит —
гашыйкларга
күк капусы бүген ачылды.

1971.



***

Ымсынган да, очынган да чаклар...
Ташламагыз әле, дусларым!
Сез булсагыз гына бәхет тулы,
тулы килеш күрсен дошманым.

Арылган да, кагылган да чаклар...
Борчымагыз мине, дусларым, —
сезнең алда никтер күңел тула,
яшь күрмәсен күздә дошманым.

1971.

Бәйрәм кичендә

Урамда, бәйрәм кичендә
байраклар җилфердәве!
Ишетелә кызыл комачта
йөрәкләр лепердәве.

Хыялы, ихтыяры бар
комачта утлы чорның, —
күңелне шулар билиләр,
йөрәкне шулар чорный.

Һәй, кузгал, уян,
сафка бас? —
Байраклар ярсып дәшә.
Бомбалар ерак төшмиләр —
йөрәк белән янәшә.

Янәшә
иллəр көрәшә,
янәшә гөлләр яна!
Бер һава сулап яшибез,
саф түгел җирдә һава.

Урамда, бәйрәм кичендә
байраклар баскан сафка.
Әйтерсең, шәһәр йоклагач,
йөрәкләр тора сакта.

1971.

Ирек

Г. Флерага

Дәфтәр-дәфтәр шигырь алып килде
Бал әбинең үги килене.
Киңәшүләр, сөйләшүләр кирәк, —
жиде сыйныф — барлык белеме.

Кичергәне — дингез кичерерлек.
Күргән кайгы — салып сыгарлык.
Урман кисте, забойларга төште,
атка төяп күмер чыгарды.

Хәзер инде менә тегү тегә,
хатыннарга халат — сатиннан.
Кыз-киленчәк килеп ашыктыра
калышмаска мода артыннан.

Майга, туйга, ялга...
Келтер-келтер —
төн тетелә, язгы таң сызыла.
Жиң утырткан чакта, әллә нишләп,
күз алдыннан узды кулсызлар.

Үсмер чактан, сугыш елларыннан
шахтер атлар ярсып кешнәде!..
Өстәленнән сыпырып ташлады да
кулын бәйләп торган эшләрен,

тәвәккәлләп дәфтәр-каләм алды,
тыялмыйча уйлар дулавын...
Ак кәгазьдә —
өркетелгән тайлар
чабышыдай шигырь юллары.

Йөгәнлисе иде, йөк саласы...
Үтелмәгән яшьтән күп фәннәр.
Азатлык һәм турылык турында
ни әйткәннәр Тукай, Туфаннар?

Актарыла китап шүрлекләре,
хис ташыса, дөнья тар икән.
Руста тагын колак ишетмәгән
Блок дигән шагыйрь бар икән.

Шагыйрьләргә ирек таләп иткән,
конституцияләрне азсынып.
Китап сүзе күп тә —
йөрәгеңә
майдай ягылганы — азчылык.

Бер ычкынып илләр гизсәң иде,
күпне күргән күңел — күрәзә.
Ишек-түрле йөрсән, алга баса
тузан кунган олы тәрәзә.

Мунчалаңны кат-кат чайкыйсың да,
яктыртасың: өең, үз кайгың...

Тәүләп дөнья тану — тәрәзәдән.
Мунчаласыз булмый, дускаем.

Дөнья куар өчен чалбар кирәк,
кер уарга — халат... сатиннан.
Өс-баш бөтен,
энә күзе аша
үткәргәнгә аны хатыннар.

Уяу узган төннәр исәбенә —
сабыйларның нурлы иртәсе.
Була микән тормыш бер киртәсез? —
Ирек — фидаилар фиркасе.

Ил язмышы белән ул камаулы.
Кайда кояш, кайда күләгә.
Кайсын шагыйрь акта чагылдыра —
монда инде күңел күрәзә.

Кырга чыксаң, шахталарга төшсәң,
ни сөйләмәс иде кешеләре! —
Үсмер чакның забоенда калган
атлары да сагынып кешнәде.

Дөньяларны бөтен итәр өчен
азмы йөкләр бергә тартылган...
Язмышларны күңел күзе аша
үткәрергә —
шигъриятkә килә хатыннар.

1972.

V бүлек

Үз йолдызым





Җисми дөнья

Исбатланган иске хакыйкатьне
үзе ачты күңелем, шаккатты:
җисми икән дөнья,

шуңа икән
иртәм таңлы,
кичләр шәфәкъле.

Кояш тирәсендә Җир әйләнә.
Төн артыннан якты көн туа.
Яңа язда җирне яңартырга
кыз туа да илгә, ул туа.

Җисми икән дөнья.
Искән җилләр
сәлам түгел сөйгән ярлардан.
Сандугач та җәйнең уртасында
туктый, диләр, өзелеп сайраудан.

Хыялыйның каурый канатында
оя кора чуар мәшәкать...

Ләкин —
кемнәр өчен йолдыз атыла,
кемне сагынып сызыла бу шәфәкъ?!

Исеме табылмаган нинди көчләр,
туфрак-җирдән йолкып кешене,
алып менә хыял үрләренә? —
Төреп бирә идеал серләренә
яшәешнең гади җисемен.

Юк, ышанмыйм! —
Әгәр җисми җирсү
өстен булса изге хисләрдән —
нигә
һаман елый Ярославна,
дастан туа Таһир-Зөһрәдән?!

Берәү өчен берәү канын бирә.
Җаны фида —
сатмый иманын.
Илаһилык жинә —
үтә алса
жир-суларның жисми сынавын.

1972.



Себердән

Күңеле илереп тә,
сөрелеп тә —
кыю ирләр сәфәр кылган ил.
Кырлары — күз, урманнары аваз, —
юлын-телен белсәң —
Туган ил.

Ишетелә, очрый таныш сүзләр,
даулы еллар исем биргәннәр:
«Үткәрмә» дә «Урай», «Яулы-тора»,
елга-урман корган кирмәннәр.

Себер көен җырдан алып атсаң,
тулы булмас илнең аһәне.
Аттан төшкәч, атны онытуны,
юк, мактамый халык мәкале.

Ничә буын монда, күпме милләт
үз җылысын салган, гомерен —
җылытырга җирне, яшәртергә,
яктыртырга сөрген Себерен.

Көнбатышка инде нур сузарга
«кара алтын» таба якташлар.
Таныш йөзләр —
жир сандыгын ачкан,
Татарстан данын яклашкан.

«Дуслык юлы» булып кайта бүген
кайнар елга
салкын Себердән.
Күзгә — дала,
жырга — кара урман
юл ачышкан гомер-гомердән.

1972.



Тиз генә онытмале

Түбәдә яңгыр шыбырдый,
куана җиңүенә —
капладым күген Себернең,
китмәле җиңел генә.

Урамда зонтлар-чатырлар, —
күчкәндәй Күчем явы...
Әйтерсең, төнге серләрнең
ишетелә пышылдавы.

Чатырлар чолганышына
чыгамын яланбашым.
Тамчылар аяк очымда
бииләр тупылдашып.

Алдылар мине әсиргә
аһ, Себер болытлары!
Күп серләр сеңгән бу җирдә —
истәсе, онытканы...

Агыла, йөзә болытлар,
ачыла соры пәрдә.

Һәм нәни кара чатырлар
юк була шушы мәлдә.

Карашлар хәвеф-хәтәрсез,
күк төсе — зәңгәр күзләр.
Төн сере — кыйгач күзләрдә.
Яңгырлар юган эзләр...

Гасырлар юган барын да —
кем каны кем канында.
Яралган жаннар —
яралы
бер тарих карынында.

Дау белән давыл куптарып,
ач жилләр күчләп искән.
Яу килгән — башлар киселгән,
яу тынган — урман үскән.

Каннарны кушып,
кайнатып,
шул Себер киңлекләре
үстерде зирәк зиһенле
пәһлеван егетләрне, —

ялкынга салып сынап та,
салкында чыныктырып...
Богаулар кысса ирекне —
кем әүвәл алды йолып?!

Зынжырлар зыңын эреткән
дәрьялар сискәндерер.
Ят күрү, дусны бәһаләү —
табигатендә, Себер.

Үткәннең чоңгылларыннан
калкынып, болытлары
чолгады мине: китмәле,
тиз генә онытмале!..

1972, Төмән

Кызыл каурыйлар

Я из той орлиной стаи...
В. Кюхельбекер

Безнең кулда язар каурыйлар бар.
Хөр иминлек — язмыш сагында.
Җыр залында түгел —
тын калдылар
житмеш шагыйрь
кабер янында.
Богау, зиндан,
затсыз дар агачы —
чүктермәгән, күккә менгергән, —
Кюхельбекер — бөркет төркеменнән,
якты очкын — эңгер-меңгердән.

Гамьсез генә бәндә яшим дисә,
бар иде бит —
ирек, байлык, дан...
Иркен суламагач газиз ватан,
иркенлекне ничек тойсын жан?
Жан —
кешедә бәһаләнмәс байлык.
Мал —
азмыдыр анда кан да кайгы...
Дан —
янәшә күпме ялагайлык —
барысын кире какты горур вөждан.

Һәм бөркетләр очты төнне ярып!..
Безнең күзне назлый ал таңнар.
Тан йокысын бүлер сәбәп тә юк,
ирек, шөһрәт, муллык —
бар да бар, —
күндәмлеккә күнгән олы агайлар,
дан янында әрсез ялагайлар,
хужа булган жирдә алабайлар —
дөнья булган жирдә бар да бар.

Бар да бар шул әле.
Бил буарга
мәйдан тар дип, ник без, шагыйрьләр,
аһ орабыз әле, күз буабыз,
бар бит жирдә изге каберләр, —
тетрәнергә,
яңартырга антны,
чистартырга жанны, вөжданны!
Азмы тәннәр — вак корт умартасы,

азмы жаннар — иман зинданы.

Ә бөркеткә һәрчак ук төбәлә.
Очып төшә кызыл каурыйлар...
Күк барында —
жирдә уклар да бар, —
тыныч яшимени шагыйрьләр!

1972, Тобол



Йортыңа иминлек, кардәш

Язулар монда искечә,
кашага каюыдай.
Кибетен ачып жибәргән,
теләге баю бугай, —

товарын мактый кычкырып,
багышлый безгәдер дә, —
сибелгән сүз тәңкәләре
кагылмый безгә бер дә.

Кая керсәң телдән төшмәс
бер изге сүз бар ләкин,
бар ишекләрне ача ул:
— Әс-сәлам-мәга-ләйкүм! —

Мосафир телендә ул сүз
юл саба илләр гизеп.
Онытылган дустын күргәндәй
яктыра гарәп йөзе:

— Вә-галәйкүм-әс-сәлами! —
Теләге баюдыр да...
Туганнар каны саркыла
кояшның баюында.

Сугышлар тансык якларда
теләкләр үзгәрмәде, —
безнең якта андыйлардан
тапмассың йөзгә берне.

Минем илдә синең илгә
изгелек тели һәркем.
— Йортыңа иминлек, кардәш,
әс-сәлам-мәга-ләйкүм!

1972.



Чүлдә

Җир дә, күк тә монда бер үк төстә,
күз ачкысыз кояш тирә-юнь.
Чүл кояшы әллә кайнар ташка
әйләндергән Мәжнүн йөрәген? —
Җете кызыл, утлы сары тутлар,
таң нурлары шулай саргандыр.
Абынсагыз аңа, кагылсагыз —
сары ялкын ялмап саргайтыр.
Сахраларда җилләр җиләс түгел,
кояш усал, кояш аяусыз!
Кара чадра каплый кызлар йөзен,
мәхәббәтләр яна чарасыз.
Уклы нурлар юлны яктыртмыйлар,
күз ачкысыз эссе тирә-юнь...
Кайтып житсәм, бер туйганчы елыйм,
сиңа ятып, яшел чирәмем!

1972.



*Егетләр китә солдатка**

Киң урамнар ник тарайган?
Моңлы көй сибелә як-якка.
Гармуннарын сузып уйнап,
егетләр китә солдатка.

— Апакайлар, әбекәйләр,
булгандыр усал чаклар да...
Усаллык егеткә кирәк, —
китәләр илне сакларга.

Зурлар сыман салмак атлап,
озата бара энекәшләре.
Иртәгәдән бу урамнар
сезнеке, авыл яшьләре.

Айлы кичләр, тәүге хисләр...
Күз салмагыз, кызлар, ятка!
Сыналырга,
сынатмаска —
егетләр китә солдатка.

Туган авыл, үскән нигез,
яшел болын кочагында
тәрәзә ачып, тыныч йокла;
улларың сакта чагында.

Күңел тынычлыгын алып,
дәртле җыр сибелә як-якка.
Ярсуларын җырга салып,
егетләр китә солдатка.

1972.

---

*М.Фәйзрахманов музыкасы.



Озатканда

Наздан кача торган кырыс малай
киткән чакта үзен сөйдерде.
Кире кайтмас балачагы белән
хушлашуы, ахры, шул иде.

Юл капчыгы белән иңнәренә
салды, гүя, дөнья хәсрәтен.
Озак кунак булган солдат сыман,
куа китте үзенең гаскәрен.

Шулай чыгып китте сабыйлыктан...
Иркәлекне сөйми, ир бала
өйдән китә.
Кырыс шинель киеп,
ир-егетләр кайта илләргә.

1972.



***

Җәйдән бүләк алып, көз бизәнде,
көязләнде. Никтер сыктады.
...Ак чыбылдык эчен үз иттеме, —
ялангач көз кире чыкмады.

1972.



***

Энгер төшеп килгән кышкы көннең
аклыгына күзләр чагыла, —
сырлап-бизәп язган эзләр укып,
Зәй өстеннән киләм чаңгыда.

Елга аша поши-болан үткән.
Кош-корт аулап, төлке шуышкан.
Мавыктыргыч әкият батырлары —
куян белән бүре куышкан.

Куркаклык та, хәйлә, явызлык та —
әкият түгел, чыннар, дөресләр.
Яфраклы җәй, яңгырлы көз булса,
ачык ятмас иде бу эзләр.

Яңа гына җиргә яуганнар да,
көн пакълеге булып, ак карлар
таң калганнар яхшы-яманына:
— Күрегезче, илдә ниләр бар!

Куян алай житез чапмас иде,
үкчәсенә бүре басмаса.

Кош канатсыз, кыш таләпсез булса,
төлке яшәр иде башкача.

Ярый әле күз кабаксыз түгел,
күрмәсен дә кайсын, сизмәсен, —
су буйлатып кына ике болан
йөри бирсен эзгә-эз басып.

Зәй буйларын урап кайтып киләм.
Нур-бизәкләр,
эзләр — ак карда.
Бу дөньяда кара таплар күренә,
ак өстендә ярылып ятканга.

1973.



***

Сыкылы-бәсле кыш иде.
Чатнама салкын кич иде.
Ак бәллүр тәрәзә — ак рәшә.
Бик якын ят аһаң янәшә.

Өстәлдә шәрапле тустаган,
күчтәнәч якыннар-дуслардан,
йолдызлы ак кар — бар жир,
ә бездә кояш, «Алжир».

И кызды дуслыкка имтихан —
шигырьдә кем хаким, кем туфан...
Бәхәстән иреннәр чатнады.
Бу кичтә күп нәрсә хакланды:

Хак сүзнең саксызы, саклысы,
хаклыкның һәркайда пакъ йөзе,
Тарихта кем халык, кем тиран...
Алтынга сатылмый ихтирам...

Чын бәллүр чынбарлык һәр яһәт.
Янәшә бик тә үз бер аһаң, —

бөдрәләр зәңгәр — төтеннән.
Әллә мин гашыйк бу төндә?

Сүзләрдә чакматаш очкыны.
Кулымда иркә-наз уч тулы...
Мин аны чәчмәдем, түкмәдем,
күкрәккә кысып йокладым...

Чатнады җандагы бозлавык,
уятып, сызлатып, кузгалды...
Сыкылы тынлык,
хуш инде!
Чатнама суык кыш иде...

1973.



***

Син әле яшь тал сыман зифа, сылу.
Белмисең, ни әле ул сыну, сулу.
Яшьлегең — сызылып киткән язгы яшен.
Күңелең җәйге урман — шаулы яшел.

Чәчләреңә кара төтен кебек бөдрә,
Һәр бөдрә балдагында — тыелган дәрт,
кагылырга кем кулы итәр жөрьәт? —
Сикереп төшәргә тора көнче кодрәт.

Син әле яшь тай сыман гамьсез чибәр,
ә тормыш шундый чуар, шундый чуар...
Дөньяга өстәлмәсең бер җилкуар, —
гөлләрдән дә жан-күбәләк бер туяр.

Күзләреңә асыл ташлы чишмәдәй саф.
Юлаучы су алдисә, түләр ясак.
Күбәер ясакчылар, кибәр ярың, —
мин сакчы булып күңеләндә калыйм.

1972.



Бүтән мәхәббәт

Яратмасалар да, ялынмыйбыз!
Бар бит әле бүтән мәхәббәт, —
чукыса да аны мең карчыга,
чаба алмас тамырын мең җәллад.

Очрашулар көтеп йөргән чакта
очар коштай йөрәк талпына.
Алда гомер азрак калган саен
күңел ныграк аңа тартыла.

Төшләреңә кереп уята ул,
уйларыңны кинәт чуалта.
Халык тулы урам уртасында
юлларыңны бүлеп оялта.

Бер карасаң, ул сихерче, иблис,
Йә канатлы ап-ак фәрештә, —
бөтереп алып сине, давыллатып,
әйләндерә җырлы вальста.

Була көннәр — без шаһ-шаһинәләр
җиде катлы илһам күгендә.

Була төннәр — үксез көчек сыман
шыңшып калам капка төбендә.

Таң атуга, бар дөньямны ташлап,
эзләп китәм эзен тапканчы.
Кочагында жан бирергә риза —
чит күрмәсен,
читкә какмасын.
Хәләл-хәрамдырмы
якыннардан
аерып алган сәер хөррият —
әсир итте сихри ул хөррият —
исеме аның —
Ижат, Шигърият.

1973.



***

Сулар ага, күлләр күккә бага,
кояш карый дөнья күгеннән.
Яз килсә дә җиргә, боз яуса да —
күкрәп уза кеше күңеленнән.

Карурманнар ава, юллар чаба,
шәһәр калка таулар ташыннан.
Таш ярса да заман, төш ярса да,
ярчыклары — адәм башында.

Йөрәгендә кайнап, ал таң ата,
кояш бата шул ук төбәктә, —
бәндә ничек гел фәрештә булсын,
ожмах, тәмуг — бер үк йөрәктә.

1973.



Ир-егеткә

Шундый булсаң гына
кирәк син миңа.
Эд. Межелайтис

Җир кызларын фәрештәдәй күргән,
садәлекне сөйгән ир-атлар,
кер кундырмый аны саклар өчен
сездә көч бар, сүнмәс гайрәт бар.
Гүзәллекне сез бик яратканга
дәвам итә безнең яшәү дә, —
яңа кеше белән өмет туа
киләчәкне күреп яшәргә.
Вакланмаучы, акланмаучы җаннар,
саклау, кадерләүгә сез лаек.
Никадәрле сездә ирлек булса,
шулкадәрле башсыз малайлык.
Абайламый агу биргән дә сез,
саранланмый ширбәт эчергән.
Шуңа да бит без, хатыннар, сезне
мең кат каргап, мең кат кичергән.
Сез ул — якты көндә ут уйнатып,
башын ташлап биючеләр дә,

афәт купса илдә, янгын чыкса,
башлап утка керүчеләр дә.
Үлемнәрдән өстен ир-егетләр,
сезнең белән көчле Ватаным.
Үзеннән дә алда киләчәккә
яхшы аты бара атаның.
Яшәп туймас гомер дәвамчысы,
һәрчак беренчеләр сафында,
кылычтан да үткен чор чатында
син торасың тормыш сагында.

1973.



Таякка мәдхия

Җырда хыял — канат.
Үр менгәндә
йөрәк кага,
тала аяклар.
Канатларның бик тә хажәт чагы —
таяндыра гади таякка.

Тук-тук —
ныграк, ныграк тотын җиргә,
бар-бар, арма, атла арырак.
Йолдызларга карап, билең турайт,
уйлар күктә кунак,
жир — торак.

Юл читендә ята каен таяк,
тузы тузган, очы юнылган.
Таянычы булган кемнәрнеңдер
өмет баглап чыккан юлында.

Каен таяк тагын кулда,
юлда —
алгысынма, йөрәк, чү, берүк! —

Үтеләсе юлның карышын да
үтеп булмый очып, сикереп.

Сизү кирәк жирнең күзәнәген,
уйсу үзәннәрен, үрләрен.
Таш астында чишмә сулкылдавын,
жир куенында ялкын дөрләвен.

Жирне тоеп, капшап барсаң гына
һәр атлаган адым ырамлы.
Жанга сихәт бирә чишмә дымы,
кодрәт бирә ялкын ырымы.

Нык-нык басып, таяк алдан китә,
юлчы хәлдән тайдым дигәндә.
Каен таяк гүя тамырын эзли,
тамырлары жирдә, тирәндә.

Бөдрә каен булып, юк, тирбәлмәс...
Нәүмизләнмә, күңел, чү, сабыр!..
Атлый таяк —
арган юлчыларның
тозын жыйган дәрвиш, мосафир.

1973.



Печән өсте

Кичәгенең дымсу яфраклары,
ап-ак чәчәкләре кичерсең, —
исерерсең, иснәп туялмассың
чапкан печәннәрнең хуш исен.

Гөлләренең татлы яшен сибеп,
үткәрә ул соңгы бәйрәмен.
Алып китәр аннан кырпак кышка
яшел ямен җылы җәйләрнең.

Сабан туйда ярышчылар сыман
уйнап тора көмеш чалгылар!
Җиләкләрнең өзелеп пешкән чагы...
Аланнарда печән чабалар.

1973.



***

И акыл өйрәтәләр,
тәмәке көйрәтәләр.
Белексезләр йөрәгенә,
имеш, ут үрләтәләр.

Дәшмим, күп сүздән гарык,
Туктарлар әле арып.
Күмелеп калган сүзләрем
бер чыгар ташны ярып.

1973.

***

Башмакларга гына кагылдың син, —
алып бирдең сөю тутырып.
Аяк очымдагы мәхәббәткә
Идел карап торды йотылып.

Су читендә үскән тал-тирәкләр
баш иделәр!
Баскан эзләрнең
эсселеген сизеп, атлап киттем,
жетеләрен сөзеп төсләрнең.

Житезлеген күргәч адымнарның,
текәлделәр күпләр аркама...
Киде-салды, узды, китте диеп,
сабыр күнелеңне каргама.

Су сибегез, янам, көям, дидем,
серем ачтым Идел-дәрьяга.
Нинди сулар, кемнәр коймас иде,
насыйп булса бергә янарга!

Тәүгесе дә түгел, соңгысы да —
юлларында синең бер генә, —
сөю тулы жинел башмак киеп,
жирдә йөрим бары мин генә.

1973.



Март

Зур ачылган күз карасы сыман
күксел урман серле, сихерле...
Кырт сындырып февраль салкыннарын,
сөңге-сөңге нурлар сирпелде.

Март!
Ак карлар кырыс, горур иде, —
карашыннан эри каршында.
Тыштан салкын карлар эчтән сыза
язгы ташкын булып ярсырга.

Каршылауны көтми, дымсу жилләр
тәрәзәне килеп чиртәләр.
Тәрәзәләр дәррәү ачылмыйлар, —
салкын — кичләр,
бозлы — иртәләр.

1977.



***

Беркем гөлләр өмет итми иде,
ниләр уйлап, кемнәр чәчкәннәр, —
хатыннарның язгы бәйрәменә
яшерен үскән тансык чәчкәләр, —

вәгъдә түгел әле —
ымсындыру:
табигать бай, гүзәл, фидакарь!
Салкын кыштан чык та,
карлар ерып,

Җирне сөреп, яшел җәйгә бар.
Карлы кыштан алтын көзгә вәгъдә —
уҗым кыягында ак сырга.
Сыргаларны сыйпап Март узганда,
сөтле парлар җирдән саркыла.

Бик сак әле урман, тын, пакъ әле...
Март сулышы саксыз бөркелде,
тирәкләрнең бөдрәләрен үпте:
сал шәленне, ташла бүркенне!

Каеннарның ак сыннары сылу, —
«наз» бит инде язның мөһере...
Зур ачылган күз карасы сыман
карурманның күксел сихере.

Сискәндерде, сынды сөңге-нурлар,
яшел калган яшерен юл табып...
Бар табигать уяу, китәмсең, Март? —
кыр юлында Апрель толпары.

1973.



***

Бергә булган көннәрен сөйлиләр
һәм төннәрен уйлап сагыналар.
Әллә кайчан инде изге түгел
мин табынган иске кәгъбәләр.

Ачылмаган кара чәчәкләрем —
и төннәрем минем, төннәрем!
Сагынып искә алыр кемнәрегез,
хуш исе юк йомык гөлләрнең.

Мин үзем дә әле төсмерләмим,
кемгә ачылыр, кемне сихерләр...
Төннәремнең биген ачып чыга
таң нурыннан тамган шигырьләр.

1970.



*Йөрәгемә язлар ярсу салды**

Кайсы язның ярсу елгалары
Ярсыттылар минем йөрәкне?
Кайсы таңның сайрар сандугачы
Сагыну җырын миңа өйрәтте?

Җәйләр җитсә, күңел кышны сагына,
Кышлар җитсә, күңел яз көтә.
Яз айларын көткән кошлар сыман
Талпынадыр күңлем кич-иртә.

Кайсы якка искән җилләр белән
Җибәрим соң сиңа бер хәбәр?
Йөрәгемә язлар ярсу салды,
Җилкетәләр җәйге иртәләр.

1968

*М. Имашев музыкасы.

***

И туган авылым яңгыры,
коендыр әле, чылат!
Таралсын алтын толымнар
чык тамган таңнар сымак.

Юдыр бер
лаклы башмакның
тәкәббер елкылдавын.
Болыным, сулар чәчрәтеп,
каз көтеп йөргән чагым, —

син һаман җилбер чәчле кыз,
кояшлы, чыклы, садә...
Аһ орып көтмәсәң дә соң,
таш орып китмәсәнә.

Яшь чаклар,
кемнәр ни эзләп,
як-якка сибелмиләр?!.
Кайтабыз,
яңгыр белән без —
апалы-сеңеллеләр.

1973.



***

Ардык, димсең,
ял юк, димсең,
гомер кичкән яллык та? —
юк инде, язмыш, башымны
йә суга сал,
йә утка.

Йә бәхетле,
йә бәхетсез.
Бер дулкынга, —
бер упкын.
Упкын ул
дулкын ялына
ябырылыр алдыннан тын.
Мин әле дулкын кылында.
Кем упкында —
жен, пәри? —
Чыксыннар көнгә,
бу жирдә
бер чәчәккә, —
бер әрем.

Яратсам-яратмасам да
ярлыкыйм —
яшәсеннәр.
Бәхетне кемнәрдән яклыйм,
булмаса әшәкеләр?
Мин торам дулкын кылында,
кагылма, үткен чагым.
Йоталмас упкын —
җанымда
ут һәм су — ике сагым.

1973.



***

Йокы качты. Куышалар
машиналар, гудоклар...
Гөрселдәшеп, сүз берләшеп,
өзлексез уза йөкләр.

Үткен уклар - төнге утлар
тишеп керә пәрдәне.
Йокы качты, йокы качты! —
Чынлый хәтер әргәне.

Бәргәләнә, чәбәләнә,
чәрдәкләнә уй-фикер.
Йокы качты. Үксез башым,
бар, эзли чык, тап, китер!

Кая китте күңелемнең
иминлеге, тынлыгы?!.
Ул әле миңа тугрымы,
әллә карак-угрымы?

Юкка чыкты ефәк төннең
тылсымланган биләве...

Йокы качты. Әйләнәмдә —
Җир шарының гүләве.

Үткәннең, киләчәкләрнең
вәгъдәсе, дәгъвалары...
Аеклык белән исертеп,
йокы, ни дәгъвалавың?

Төн кичеп, жан өзеп,
кочып
утырган өстәлемне
калдырып,
озын олауга
йөк булып өстәлимме?

Бирмәсме эзләгәнемне
олаулар бәллүкие.
Бармасмы, җырлап, җанымда
Тукайның «Әллүки»е?

Теркелдәшә, сер серләшә,
тукталмый юллар йөге.
Бүтәннәрне уятырдай
сүз әйтсәм — килер йокы.

Үбәр дә керфекләремне,
урар төн ефәгенә...
Ә ул сүз бара, мөгаен,
олаулар күчәрендә.

1973.



Кайный, шаулый Казан урамнары

Кайный, шаулый Казан урамнары,
карлар оча, жилләр тилемсә.
Матурлыгын кичнең казанлылар
күрми дәме әллә югыйсә? —

Кабалана алар, ашыгалар, —
троллейбуска чират, кинога.
Өйсез жилләр белән житәкләшеп,
буран диңгезендә мин агам...

Яр өстендә, тауда ак манара.
Кремль сәгатендә ун тула.
Богауларын өзгән Муса, гүя,
болай гына ярда утыра.

Баһадирлар бераз ят һәм ерак...
Язга чыккан өлгер малайдай,
киемен салып, кул очына тоткан —
һәр студентта яши Володя.

Халыкларның күңелен яулап алган,
үзенекен биреп алмашка.
Бөекләрнең даны ташка күчә,
җаны иңә җиргә, тормышка.

Каплар өчен җирне ач бураннан,
кыя-Муса кинәт калкына.
Кайный Казан,
ялкыннары ялмый, —
ташларыннан ялкын саркыла.

1973.



Әлмәт[*]

Хыялларны кушып ут тергездек.
Учаклардан шәһәр башланды.
Ак теләкләр белән нигез салдык,
таудан алдык ап-ак ташларны.

Шуңадыр ла урамнары якты,
тауга кардәш биек йортлары.
Тәрәзәләрендә балкый сыман
без кабызган учак утлары.

Зәңгәр кичтә җем-җем тәрәзәләр
ай-йолдызлар белән серләшә.
Безнең яшьлек хыяллары булыр,
зәңгәр ялкын сүнми дөрләсә,

манаралар йөрсә кырлар буйлап,
ургып торса кайнар фонтаннар —
безнең яшьлек бүләгебез булыр
әкиятне чын иткән Ватанга.

Әлмәт, Әлмәт,
синдә кемнәр тумас!

Без тудырдык сине үзебез.
Нигезеңә яткан һәр ташыңа
уелып калган яшьлек эзебез.

Шуңадыр ла урамнарың якты,
җем-җем итә төнлә йортларың.
Ә күңелдә һаман балкый әле
Зәй буеның учак утлары.

1973.

*Р.Вәлиуллин музыкасы.



***

Аланнарның иркенлеген тоеп,
жиләкләрен җыеп үскәнмен.
Таш астыннан чыккан чишмәләрнең
сиңнән элек суын эчкәнмен.

Ә шулай да артык үрсәләнмә,
барысын татып карыйм, дип, тизрәк.
Чорлар белән жырлар ярышында
син барыбер миннән җитезрәк.

Акыллырак булыйм дисәң инде,
шигырьгә бит күбрәк хис кирәк.
Ансына да тимим, синдә тибә
минекеннән көчлерәк йөрәк.

Ил алдында, борылмаларында
сынадылар аны яхшы ук.
Аңладылар микән? —
тыңладылар
күкрәгенә синең баш куеп.

Ә мин шуны белдем: ярышларда
бер батырны арттан иярtеп,
уздырырга да бит йөрәк кирәк,
йөрәк бит ул туктап куяр күк.

Сикереп чыгар төсле чик ноктада,
нәкъ очында мәрмәр кыяның
шул мизгелне күрдем, сихрилеген
чын дөньяның,
түгел хыялның.

Кыя очларында гел янәшә
тормас безнең гомер чикләре.
Кем китсә дә —
шул ноктадан узар
язмышларның киләчәкләре.

Бер биеклек ике теләк өчен —
менгән идек икәү: син дә мин.
Биегрәкне әле тапмасам да,
кире кайтыйк, диеп өндәмим.

Син уза тор.
Таш астыннан чыккан
чишмәләрем ята мөлдерәп.
Акыл белән хисләр ярышында
син барыбер миннән өлгеррәк.

1973.



Шагыйрә

Һәр авазы серле, шагыйрәнә.
Җир әйләнә, ә ул үзәктә,
өе тирәсендә дию туен
йөрәгенә басып күзәтә.

Шул йөрәктә тагын ничә үкчә!
Үксеп чыга аннан жыр, ютәл...
Йөрәгемнән сикереп, җиргә чумдым,
Ахматова түгел мин, бүтән.

1973.



Табылдык хат

Бик кирәге булса, синдә калсын
сынар канат һәм хат...
Калсыннар! —
Кемдер белән сиңа эссе чакта
жиләс һава жилпеп алсыннар.

Бернәрсә дә, беләм, кире кайтмый.
Хат укылган. Канат өтелгән.
Кешеләргә булган сөюемне,
ышанычымны бир,
үтенәм!..

1973.

***

Хисләреңне салып дулкыннарга,
колачыңа алып йөзәсең.
Беләсең бит инде, дулкыннарның
диңгез эзләп, илләр гизәсен.

Зәңгәр күккә аннан күтәрәсең,
үз-үзеңнән куркып, гайбәттән...
Күктә, фәрештәләр аклыгында
Сак-Сок булып оча җан һәм тән.

Көзләр узгач, язлар китерәсең,
ел агышын җырга кабызып.
Җан орырга, шашып сагынырга
кирәк бит ул сиңа ялгызлык.

Һәм мин яшим
синең хакны хаклап,
дулкыннарда,
язда,
күкләрдә...
Җыелмалы зонтигыңны күтәр —
баш өстеңә киләм күкрәргә.

1973.



***

Утлар йоттым,
янып-көеп беттем,
ымсынулар, икеләнүләр...
Хәзер уйлыйм:
ике дә уйламый
китәр идем ул көннәремнән.

Китәр идем, әгәр үз-үзеннән
китеп булса алга,
арткамы —
һәм тамаша итеп карап булса
янган йортта чапкан атларны.

Читтән ярдәм килсә, кабул итми,
ут эченә атлар сикерә...
Янып, көеп беттем,
бер син генә
сүндераласың,
тик сүндермә...

1973.



***

Бер юлынны илдә яңгыратырга
еллар буе йөрим тәкатьсез, —
шигърият, мин сиңа хыянәтсез,
ә кемгәдер шундый шәфкатьсез.

Бер сүзеңне таңда сайратырга,
төнге бикләремә ут төртеп,
мин иң изге гөнаһларымны да
кош җименә салам күпертеп.

Гөнаһлылар кере кунмый аңа,
таң аттыра былбыл тирәктә.
Ай былбылым-җаным, янып бетәм,
тирәгеңә көлем кирәксә.

1972.



***

(Бер гыйбрәт)

Өр-яңа тотка куйганнар
бер өйнең капкасына.
Әйткәннәр: тимер бу, тиң бу
замана тоткасына.
Яңа тотка искечәрәк
керешкән үз эшенә:
өлкәннәргә кул бирә дә
юл бирә бу кечегә.
Шулай да юхалар майлап,
усаллар шаулап уза.
Майланып, тотка шомара,
юкара, сизә: туза.
Эш йөртә хәзер башкача:
бил бөгә дә тез чүгә.
Көчлеләргә баш ора да,
таш, ора, ди, көчсезгә.
Кадагын суырып бирергә
әзер дә дусларына, —
үз кадагым, кадалмас, дип,
бирә, ди, дошманына.

Какшаган тотка, аксаган...
Белгәннәр тотынмастыр,
усалга койма өсте бар,
юхага — капка асты.
Шулай да, тутык тотканы
алып атканга тикле,
турылык сөючеләрдән
капкага төшә типке.

1973.



Ил чикләре

Чик буйлары тыныч түгел, ди ул,
кышны тагын анда каршылый.
Күз нурлары белән яктырадыр
ил чигенең һәрбер аршины.

Чик буйлары тыныч түгел, дисә,
тынгы белми йөрәк, сызлана...
Әллә инде Ватанымның чиген
минем йөрәк аша сызганнар?

Йөрәгемнән өзелеп төшкән улым
чик буенда, дөнья сагында.
Ил язмышы аның кулларында,
үзе һаман өйне сагына.

Сагынганга да бит сакчы сизгер:
төнме — кара, җилме — сызгыра...
Чиксез сөю тулы күңелләр бар,
шулар аша чикләр сызыла.

1973.

Җәлил

Иңбашына соры шинель салган,
кирза итек кигән чолгаулап...
Көн тудисә
Җәлил шәһәрендә
һәр вахтага чыга шул солдат.

Сәламлиләр: шагыйрь бит бу, диләр.
Кайберләре әйтә: сугышчы.
Данлы исеме белән
шагыйрьгәме,
солдаткамы Җәлил бурычлы?

Шагыйрьләр бит бармый үтерергә,
сугышчылар бара һөжүмгә.
Солдат ата яуда дошманына,
ә шагыйрьләр төзи үлемгә.

Үлемнәрдән өстен шагыйрьләрдә
иман шиксез,
йөрәк калкансыз —
кояшка һәм кылычларга ачык,
ояламый анда ялган сүз.

Үз чалымын, үз адымын танып,
эшче Җәлил — нефть төбәге —
һәр вахтада үз сафына ала
солдат жанын, шагыйрь йөрәген.

1974.

Соңгы патрон

Исән икән әле, тутыкмаган,
истәлекле, исем-тамгалы.
Салкын тимер...
Утлар-сулар кичкән
кайнар гомер —
әткәм наганы.

Хәтәр еллар!..
Шлемдагы йолдыз —
әткәемнең тапсыз вәжданы.
Соңгы чара — соңгы патрон калып,
тезләнгәнче соңгы дошманы,
ул сугышкан.
Кырга тургай кайткан.
Чәчәк аткан миләш-баланнар.
Басуларда агач сукаларны
алмаштырган корыч сабаннар.

Ничә тапкыр
дошман
коммунаның
соңгы сәгатьләрен санаган!
Гадел атлы әткәм күзләренә
хыянәтчел үлем караган,
ничә тапкыр...

Ятим итә алмас
бер дошман да миндәй баланы! —
Күңелемдә әткәй елмаюы,
мендәр астындагы наганы...

Патроннары баш калкытмый гына
сакта яткан —
жиңү сагында.
Ил чигенә кара шәүлә булып
янә яулар килгән чагында,
«Өйрән», — диде әткәй, наган бирде.
Карачкыга, әткәй кушканга,
алты патрон аттым.
— Соңгы патрон?
— Соңгы патрон — соңгы дошманга.

«Соңгы пуля үз-үземә», — дигән
жырны безнең әткәй белмәгән.
Дошманының үкчәсенә басып,
бәреп кергән чит-ят илләргә.

Жаны калган кайчак кыл өстендә,
мылтык көпшәсендә — гомере...
Соңгы сулышкача
фашистларның
соңгы ояларын жимерде!

Исән әле наган...
Салкын тимер
сискәндерде уяу хәтеремне.
Бик сак кына кулларыма алам,
сакланганмы соңгы патроны?

Дус-дошман бар.
Тыныч заманнарда
жырлар үлчи илнең кинлеген.
Чикләр аша уклар төбәлгәннәр
сынар өчен кемнең кемлеген.

Очар пуляларны туктатырдай
жырлар бармы?
Утлар комарлы.
Соңгы патрон әле атылмаган,
ул атылса, дөнья тынармы...

Соңгы патрон әле атылмаган,
онытылма, йөрәк, хушланма!
Гадел атлы әткәм әманәте —
соңгы патрон —
соңгы дошманга!

1974.



Эндәшү

Ялгыз-ятим каба-йоның көтә,
утыр әле, әнкәй, эрләргә.
Син йөрмәсәң, өйнең яме китә,
чирләмә син, әнкәй, чирләмә.
Йон-оекбаш, мамык бияләйләр —
бәйләгәнең дә бик житәрлек,
эрләмә син, болай гына утыр,
балаларның күңелен күтәреп.
Бәйләм оекбашның һәр күзендә
күз нурларың, әнкәй, саклана,
сизгер карашыңны сизеп калам
саксыз атлыймсыман чакларда.
Авыру дигән хәбәр алгач кына
кайтып күрәсез, дип әрләмә,
син чирләсәң, авылда ямь бетә,
чирләмә син, әнкәй, чирләмә.
Ударница чагың рәсемнәрен
эзлик әле сандык төбеннән.
Эзләмик тә, зифа буй-сыннарың
мин күңелдән беләм, күңелдән.
Колагымда яңгырый җырлавыгыз
әткәй белән бергә парлашып.

Тормыш нинди матур булыр иде,
сездәй яши алса һәр гашыйк.
Әткәй бездән бик ашыгып китте.
Кайтып керер сыман кич белән,
ул һәрвакыт бик ашыга иде,
ул гомергә йөрде эш белән.
Инде синең китәсеңә күнми,
керим дә мин тып-тын бүлмәнә,
эндәшимче:
— Дөньяда ямь китә,
ач күзеңне, әнкәй, чирләмә...



Көнләшү

Йә мәхәббәт жинә,
Йә нәфрәтем...
Кайда, кайда гади урталык?
Көнләшүне үтә түбән хис дип,
дорфалык дип саный бар халык.

Ә мин көнлим сине —
ят күзләрдән,
иңнәреңдә яткан чал туннан,
алларына алтын чәчен сибеп,
сер бүлешкән төнге лампаңнан.

Мин бит кер кундырмый, тел тидерми,
сина гына серләр сакладым.
Икәү генә булыр чакны бүлеп,
чабып керә шигъри чаптарың! —

Алып китә...
Ah, мин беләм, беләм —
боз да эри синең караштан!
Киңәерме күңелем —

бүтән берне
мине яраткандай яратсаң?..

Сыйдырырмы күңел үзеңне дә
миннән читтә булган хисеңне?
Ул кысыла һаман, ул нечкәрә,
нечкә кыллар үтә сиземле.

Кыл очларын көмеш йөгән итәм,
кылыч болгыйм,
озак офтандык!
Көнләшү ул, бәлки, түбәнлектер, —
йөрәк — чаптар,
кайтыйк ил танып.
Мәхәббәттә
йә нәфрәттә яныйк!
Кирәк түгел гади урталык.

1974.



Кемне көтә, кемне чакыра...

Ниләр саный, ниләр сөйли икән,
белсәң иде сәгать телләрен...
Казан, Казан,
сиңа килгән саен
керфек какмый уза төннәрем.

Күзләренә тамган төн карасы,
керфек очларына — таң нуры, —
кич життисә, чатта бер сын тора,
ял-йокымны алган улмыдыр —
сынлы тылсым —
гүя Казанның ул
йөрәгеннән саркып, калкына —
тәрәз каршысында өнсез тора,
кемне көтә, кемне чакыра?..

Сулыгып-сулыгып Идел дулкыннары
кага булыр уяу жаннарга —
ярдан ярга берәү хәбәр сала,
утлар ягып ага салларда.

Карангыга күзне йомдырмыйча,
самолетлар оча төн ярып.
Ир-егетләр диңгез-таулар кичә,
канатына алып дөньяны.

Уй-дәрьялар салып күңеленә,
ай-йолдызлар алып иңенә,
уяулыкка сакчы бер сын тора,
еллар төяп вакыт геренә.

Йөрәгемә ниләр сыйдыралам —
үлчәп бара сәгать герләре...
Тәрәз каршысына Тукай баскан!
Юк, йокламый шагыйрь йөрәге.

1974.



Бәхеткәме?

Син, кайгыртып кеше кайгыларын,
кай тарафта хәзер йөрисең?
Кояш чыгыш, баюларын
каршылыйм да озатам берүзем.
Эссе җәйләр яшел ялкыннарда —
утларында яшерен дөрләвем.
Син бу хакта, хәер, белмәссең дә,
хәерледер, бәлки, белмәвең —
каерылып уңган арышлардан
аерылыр иде күңелең.
Ә сиңа бит
кеше күңелен күрү,
мәшәкатьле эшкә күмелү,
Җир күчәрен әйләндерү кирәк,
тетрәүләрен үзең кичереп.
Шундый фидай затлар көче белән
алга бара бит ул кешелек.
Бәхеткәме —
өннәрендә калып,
төшләремә килеп керүең...
Син бу хакта, хәер, белерсең дә,
хәерледер, бәлки, белүең.

Эссе җәйнең яшел ялкыннары
әйләнәләр, янып, сарыга.
Каерылып үскән арышлар да
күкрәгенә җирнең сарыла.
Сарылса да, сансыз сарыф булма,
алтын бөртек, ялкын сагышым!..
Кай тарафта хәзер йөрисеңдер
син кайгыртып дөнья язмышын?..

1974.

***

Сынаулар үттең,
сынатма,
сокланыйм, калыйм хәйран, —
буйсындыр мине —
сындырма, —
буй-сыным Урал-таудан.

Биклә дә мине үзенә,
чикләмә сагың белән, —
җыр булып ташып чыгармын, —
чыгышым Агыйделдән.

Атмый тор, оча бер лачын, —
ташкыннар, кошлар юлы.
Аккошлар күлләргә кунсын,
син Идел сыман олы.

Буй салам,
дулкын-уй салам,
буйсынам, сынмасам да,
Аккошлар юлыдай елым,
күлләрдә кунмасам да.

1974.



***

Табигать...
Җилләр, яфраклар
бер сулыш монда, бер тын.
Шәһәрләр, юллар, тузаннар
җуелган сихри бер төн...
Сагындым!
Тагын сайладым
салават күперенең
сарысын.
Утка тарыдым;
ялкында бөтереләдем.
Яшеле-яшьлеге белән
зәңгәре-гыйшкы янды.
Шәмәхә шәлнең чуклары
алланып җиргә тамды.
Сагындым.
Сиңа сарылыйм,
зәңгәр күк, яшел үлән.
Бәйгегә чыга йөрәгем
янгырлы яшен белән!
Салават күпере дуга,
кызыллы да зәңгәрле.

Кемгә күк капусы ачты
мәхәббәт пәйгамбәре?
Яфракта чыклар, керфектә...
Бер тирән сулыш, бер жан.
Тәрәзә ачык,
күңелләр —
пәрдәсез аткан бер таң.

1974.



***

Тәрәзәгә үрли ак муеллар,
чәчәкләрдә нинди язык бар? —
Тирәкләргә үрли Ромеолар,
сирень сындыралар гашыйклар.

Бу дөньяда бер табигать белә
кемгә, кайчан, нәрсә кирәген, —
гөл-сиреньнәр язын чәчәк ата,
гашыйкларның үтәп теләген.

1974.

***

Озак көттек энҗе бөртекләрен.
Уйна, юан, куан —
мә тәти!
Тәңкә карлар яуды.
Кыш урнашты.
Юл тапталды.
Салкын. Гадәти.

1974.

***

Иңнәреңә баскан дәрәҗәнең
пәрәнҗәсе төшә йөзеңә.
Дәрәҗәңә кемнәр кызыгадыр,
пәрәнҗәңә синең күзегәм.

Ачып булмый аны, ташлап булмый,
эш арасы, кеше арасы.
Һәр кешегә үз карашың кирәк,
мин дә шул ук адәм баласы.

1974.



***

Табигатьтән бар бәндәләр тигез.
Табигатьне бәндә аера:
үз йозагын сала агым суга,
үз мөһерен суга каенга.

Табигатькә бар бәндәләр тигез —
жир куенына сала кадерләп...
Юлчыларга нинди серләр сөйли
ак каенлы телсез каберләр?..

1974.



***

Кабаланып килеп життең дә бит,
пароходка кереп барышым.
Бүләргәме, әллә кушаргамы
ике жанның уртак табышын?

Син сызганып чалбар балакларын,
башмакларны алып мин кулга,
су чәчрәтеп бераз йөреп килсәк,
агып китәр микән бу елга?

Бер дулкынга ике кереп булмый,
бар да уза, бар да үзгәрә.
Дулкынннарны акчарлаклар кисә,
мин дә бүтән,син дә үзгәрәк.

Канатлары кыйгач акчарлакның
жан атуларына ис китеп,
агым уртасына кереп барыш,
соңгы гудокларны үксетеп.

1974.



Яшьлек урамы

Кайда атса, шунда балкый
яшьлек таңнары.
Бөгелә - сыгыла талгандыр ла
нечкә таллары.
Тынгы бирми җанга Тәтешле,
офыкларда сызылып киткән
җәйге таң төсле.
Урак урган, печән чапкан
болын - кырларым.
Буразнадан маңгайларга
күчкән сырлары.
Тирән эзләр салды Тәтешле,
монда узган елларымның
ачы - татлысы.
Моңлы-жырлы, яшерен серле
яшьлек урамы.
Күкрәп килде, шаулап үтте
гомер бураны.
Зифа каеннарың, Тәтешле,
яшьлегемнән яулык болгый,
назлы яр төсле.



***

Бер эретеп, бер суытып,
суларны катырса да,
кыш түгел әле, туң җиргә
кар төшеп утырмаса.

Тып-тып тамчылар тамганда
карап күзләр талса да,
Яз түгел әле, яз түгел,
Зәйдә боз кузгалмаса.

Көндезен янып пешсәң дә,
пешкән алмалар өзсәң,
җәй түгел инде, җәй түгел,
кичке салкыннар төшсә.

Йолдыз-яфрак җиргә төшсә,
көз инде бу, көз инде.
Көзге учаклар кабынгач
эзләп таптым үзеңне.

VI бүлек

Сатылмаска





Әлмәтем-мәхәббәтем[*]

(Җыр)

Әлмәт юллары якты,
чакрым саен маяклы.
Әллә нигә, әллә нигә
якын иттем бу якны.

Кушымта:
Әлмәтем, әй, Әлмәтем,
син минем яшьлек дәртем.
Синдә жан сөйгән хезмәтем,
бәхетем-мәхәббәтем.

Дала жиле искәндә
иртәләрдә, кичләрдә
кара алтын, зәңгәр ялкын
тынгы бирми хисләргә.

Кушымта.

Вышкалар басты сафка.
Тулган ай тора сакта.
Зәй буена кил син, иркәм,
фонтаннар аткан чакта.

Кушымта.

*С. Садыйкова музыкасы.



Кар ява

Бурaнланып яңа еллар керә.
Ак аргамак — давыл яллары —
аргы очтан оча бирге очка,
сыкы чәчле кышка юл ярып.
Иске елдан чыгам изге юлга —
җир карасын каплап, кар ява.
Кар өстендә, акка кара булып,
карганалар ала каргалар.
Каргышлары оча аргы очка.
Безнең очта бәйрәм-нарасый!
Аргамакның ялкын-ялын кочып,
барасы да әле, барасы! —
Зәмһәрирләр белән сызгырышып,
Зөлхиҗәләр белән биешеп!
Көтә мине кары кагылмаган
көмеш кыңгыраулы бер ишек.
Кагылырмын —
кар-бизәкләр сибәр
кыңгырауның көмеш чыңнары.
Кышкы буранларга уралып бара
серле хыял, кырыс чынбарлык.

Берәүләргә — салкын кар бөртеге,
берәүләргә — йолдыз, энҗеләр!
Карны кар дип белгән син акыллы,
ак чәчәкләр күрәм мин җүләр.
Җил-давылда җылы яңгыр күрә —
кыр-далада бүген ил күзе.
Игенченең хыялында шаулый
Уҗымнарның яшел диңгезе.
Уең нинди, шундый төскә буя —
өр-яңадан дөнья агара!
Җир карасын, кыр ярасын каплап,
өметләрне аклап, кар ява.

1975.



***

Март бураны, март бураны,
ак урам, кара буран.
Ярсыган язга тап булып,
чак аяк өсте торам.

Күренми күзгә ак-кара,
кар бабайлар, кар кызлар.
Күз ачкысыз, йә качкысыз,
жил сызгыра, кар туза,

котырына, бөтерелә:
— Ак булыйм, кара булыйм,
мин шәрран-яран булганчы,
мәңгелек яраң булыйм.

Март бураны, яз бураны,
и, соңгы буранарым! —
Онытылмас язлар ярасын
син миңа юрамале...

1977.

Айлыбикә...

Тукталам да төнге күккә карыйм:
хәйран сызылып төшкән Ай кашы.
Читтән генә безне күзәтәмсең,
мәшәкатьле җирнең юлдашы?

Мәңге шулай нурлы, мәңге серле,
үз сагышың белән ялгызсың.
Әйләнәсең һаман җир тирәли,
үкендерә әллә ялгышын? —

Утларында янып киткәнсең дә,
сайлап җирнең биек сәхнәсен,
салкын булса да бит ташламыйсың
мәңгелекнең зәңгәр сәхрәсен.

Җирең сине сагынып, сәлам юллый,
тугрылык ул ике яктан да.
Чиләкләрең тулы, Айлыбикә,
чү, карама җиде ятларга.

Сагышланган, сагынган чакларда
и, бердәнбер ялгыз сердәшем!..
Утларыннан китеп, мин дә гизәм
зәңгәр төннең салкын сәхрәсен.

1977.



Казан, күңелем һәйкәлләре иле

Барам әле, Казан, киләм әле
кош юллары буйлап, очынып.
Ай-кояшың, рәхмәт, каршы ала,
Идел яры дәшә юлчыңны.

Сөембикә сыны, ни тылсымы? —
яшерәдер сыман серләрен.
Ерак бабамнарны белгәнме ул,
әбиләрне минем күргәнме?

Сибелгәннәр урман-далаларга,
күтәргәннәр жирнең чирәмен.
Тукай моңын, Такташларның гомерен,
үткәннәрнең моңын жырга салган
Туфаннарны сагынып киләмен,

Сибгатләрне, Исәнбәтләреңне,
истә мәнге исән ядьләреңне,
үткәннәрне таптамаучыларны,
бүгенгене бирми ятларга.

Татар китабының изге йортын
якын, ерак фикердәшләрне,
замананың күкрәгенә басып,
җыр башлаган кыю яшьләрне

сагынып киләм, чорлар чорналышкан
казанында, Казан, кайнарга.
Соңгы богауларны өзгәләргә
Мусаларың чыкты мәйданга.

Яшь Ульянов безнең белән уза
йөзьеллыкның соңгы чиреген, —
хәзинәләр яткан илләремдә
киләчәкнең табып җирлеген.

Язмышларның борылышларында
шундый юлдашлары булганда,
мәңгелекнең үзәк юлларында
Җыр һәм Акыл бара иң алда.

Казан, күңелем һәйкәлләре иле! —
Кайтавазлар җавап кайтара:
— Без Вакытка хезмәт итсәк кенә
Вакыт эшли безнең файдага!

1977.



Нидер яна

Җәйнең соңгы киче. Салкын төшә.
Яшь малайлар учак яндыра.
Салкын кичнең утлы кочагында
Нидер туа, нидер җан бирә.

Хыялларның зәңгәр төтеннәре,
акшарлаган авыл мичләре...
Кайда гына безне йөртмәделәр
балачакның кышкы кичләре! —

Ялкын яллы атлар ак күбектә.
Акылларын җуйган җайдаклар
ут уйнатып, кылыч болгап чаба,
ыргылалар алга байраклар.

Үрсәләнә ялкын кочагында
аккаенның кайнар кәүсәсе.
Чү... Сузыла кайнар иреннәргә
Җиңүченең алтын касәсе...

Ыргый-ыргый кыргый җаннар бии, —
карт имәннәр ничек илерә!..

Мич алдыннан киттек
урманнарга,
яңуларның серен белергә.

Үстереште безне, саклады ул,
ышыклады яңгыр-бозыннан.
Безне яклар өчен
чыршыларның
Сөңгеләре күккә сузылган.

Суктырмады безне яшеннәрдән,
үзе янса янды каенлык...
Отты микән заман, оттырдымы,
урманнардан безне аерып?

Бетон ташта ярсып учак яна —
Әфлисуннан калган тартмалар,
Сикерешә каучук тәгәрмәчләр,
дәррәү ялкын, дөрләү, шартлаулар...

Учак яна. Кышкы ак мичләрнең
хатирәсе кабат яңара.
Атлар дулый.
Шәрә сыннар бии.
Нидер яна.
Нидер ярала.

1976.

Сүз

Сүз — тормыш,
халык гомере.
Тарихтан килгән мөлкәт.
Саклана, күчә телләргә:
дус,
  дошман,
    сөю,
      нәфрәт.

Жыенда, эштә, чиратта
күмәк көч заманында
күпләрнең тоям күкрәген
һәм сизәм жаннарын да.

Түбәндә, югарыдамы —
шунсы хак, шунсы дөрес:
гомергә төшми телләрдән
сөт,
  икмәк,
    туфрак,
      тирес.

Һәм шулар жирдән аермый,
телләргә кер кундырмый,
тарталар фани дөньяны,
күчәрдән ычкындырмый.

Сүз — икмәк.
Шагыйрь икмәге
тәмледер — үреләләр.
Минеке генә түгел бит,
ул — кызларыма мәһәр.

Хөррият, хөрмәт, дәрәҗә
кемгә аз, кемгә күбрәк —
тауларга карап, кодрәт ал,
түбәнгә карап — гыйбрәт.

Сүз — җанда. Бәлки, ирендә?
Кемгә ук, кемгә кубыз:
биегез... Кубызлар күп... Тик
белегез: тормыш кырыс.

Сүз — татлы исерткечләрдән
иң мавыктыргыч хәмер.
Сүз — тамыр. Тамыр корыса —
юк тарих һәм юк гомер.

Сүз — кылыч,
чыгар кыныдан
шөбһәсез — җиңәренә.

Сүз — икмәк.
Икмәк үсә сөргән,
чәчкән җирдә генә.

Җиргә күчә

— Сау булыгыз! — диләр киткән чакта,
борынгылар сүзе әманәт,
белгән алар киткән чакта гына:
нужа куып йөргән җир җәннәт.

Җилдә шаулый урман:
— Җир мәңгелек!
Күзгә карый күлләр:
— Күр безне!..
Ярдан чыга дәрья:
— Җир гөнаһлы...
Таштан чыга чишмә:
— Җир изге!

Изгеләре, гөнаһлысы белән
фани дөнья жирдә гаугалы.
Изге булып кала соңгы теләк,
гөнаһларны жуеп, дауларны.

Ак өметләр бодай булып шыта...
Әрнүләрне тирән күмгәннәр,
буразнада, ындыр табагында,
эш өстендә егылып үлгәннәр —

— Бай булыгыз! — диеп киткән алар,
бушка әйтелмәгән васыять, —

таш астында, тирән сандыкларда
ата-баба җыйган бай зиннәт.

Гасыр төпләрендә әллә шулай
саклаганнар янгын, яңгырдан?
Туган илнең иминлеген яклап,
яу кырында алар жан биргән.

— Дус булыгыз! — диеп киткән алар.
Әманәтләр түгел коры сүз.
Дуслык юлы сузыла илдән-илгә,
киләчәккә тоткан юлыбыз.

Уттан алып, суга салсак та бит,
жиргә күчә күңел жылыбыз;
Изге теләк илгә без юллыйбыз:
— Сау булыгыз, тату булыгыз!

Кабатлыйлар таулар:
— Бай булыгыз!
Күзгә карый күлләр:
— Күр безне!
Ярга кага дәрья:
— Жир гөнаһлы...
Җырлап ага чишмә:
— Жир изге!



***

Бөреләнә, караладыр
җир шомырт сөрмәсендә.
Алланадыр, балланадыр
алмасы-хөрмәсендә.

Тамганмы кояш тамчысы —
җиләкле аланнары.
Баллыдан туйсаң, ачысы —
миләше, баланнары.

Дөньяның түгәрәклеге —
бөрлегән мөлдерәве.
Түм-түгәрәк җир өстендә
кеше ник сөрлегәдер? —

Тапталап узмаскадырмы
асылташ-якутларны,
асылын уйларга туктап,
ашыгыч вакытларның.

Көтмиләр айлар, тәүлекләр,
көн туа да эш куа.

Бер очын тапсаң тормышның,
тәгәрәп бара дөнья.

Кемне кагып, кемне танып...
жир-күзләр сөрмәсендә.
Жиркәем, жирсүләр серен
жанымнан сөрмәсеннәр.

1977.



Аулардан арынып

Синдә генә, авылым,
тиңдәшсез дүрт фасыл.
Дулап уза кышың,
балкып килә язың.

Җәйләр — яшел яшен,
көзләр — көмеш яшем —
яшьлегемә дәшә!
Жирсеп яшим.

Карлы-бозлы таулар
канатыңны сыный.
Аерым узган айлар
яратуны сыный.

Тарлыкларда шаулый
шарлавыклар.
Тарыма син, ярым,
тарлавыкка.

Төннәр чат йолдызлы,
Аең Зөһрә кызлы.

Сирхерләнеп сызыла —
шәфәкъ-таңнар кызыл.

Аккаеннар язы,
ачык изүләре.
табигатьнең сизгер,
изге мәле.

Арулардан арынып,
кайтамын көрт ярып.
Сина килеп кушыла
дөньянын дүрт ягы.

1977.

Әкиятле үсмер чактан чыккач

Ай-ураклы зәңгәр кичләр тын да,
давыл көткән диңгез кебек шом...
Пәйгамбәрләр эзләп юлга чыктым,
җен затына барып юлыктым.

Чәче кара дегет, буе сөлек.
— Ник юлыма төштең, и егет?
Гайрәт чәчеп әйтә салды егет:
— Миннән гөнаһ, синнән изгелек!

Әкиятең күккә оча, ди ул,
актарыла дөнья, айкала,
таулар иңә, урман сирәгәя,
айлар түбән, сулар сай кала.

Яшәешкә нинди ямь бирә, ди,
шагыйрәнә уйнау сак-соклы?
Яшь каеннар кәүсәсенә салыйк
Минем көчне, синең аклыкны.

Ди ул: — Миндә мәкер, синдә акыл —
тажың салып кояш баш ияр!
Дидем: — Җеннәр безгә җан дошманы,
юлдаш булыйм дисәң, хуш, ияр!

13. Я-547

... Юлга тарак ордым — урман үсте.
Карурманны кичте жен егет.
Көзге ордым — тирән күл уелды,
күлне йөзеп чыкты ул сөлек.

Ак яулыгым салып жилгә аттым —
карлы таулар басты арага.
Жен югалды. Ак буранда калды...
Аклык хәвеф икән хәрамга.

Алмашынган су анасы сыман
айлы төнгә тәрәз кагамын:
— Сибелә чәчем, сибелә, тарый алмыйм,
кая минем алтын тарагым?

Серләр иле әкиятле урман,
зәңгәр садәлегем — көмеш күл
фани дөнья чынлыгында калды,
жен-иблисләр белән жинешеп.

Акыл-көчне салып, кичеп барам
жен кагылган дөньям давылын.
Пәйгамбәрне канатына алып,
очып бара ап-ак яулыгым.

1974.



Сатылмаска

Казан. Печән базарында
Кәвеш-ката, чалма-чапан.
Үтә маллар, китә даннар,
гөрли базар:
— Сатам, сатам!

Шыгыр-шыгыр атлы арба.
Чайкала җил искән җайга
ятим бала...
— Йә, кем ала?
Асрамакка! Бала, бала...

Әвеш-тәвеш, килеш-китеш.
Йөге калды, аты кайтты...
Нәни Апуш, үги язмыш
базарларда сине сатты.

Асрамакка. Җиде ятка...
Әңкәң каберендәге таш та
ачы җилгә ачык калды,
әйләнмәсме җаның ташка?

Җәе җылы, кышы кырыс —
туган якның табигате.
Урман тулы әкияте,
Кырлай юлы шигъриятле.

Җилкендерә дәртле Казан,
җыр тудыра якты Казан.
Акрын гына җан сыздыра
ләббәйкәгә дәшкән азан.

Күнелең назга мохтаҗ чакта
күз төбәсәң гүзәл затка,
күз алдыңа килә базар:
— Бала! Үксез бала!..
Сатам...

Тәфтиләүләр сызып сула,
Зиләйлүкләр тора чатта.
Сәүдәгәргә кәеф-сафа —
ала-сата, ала-сата

яшь кызларны, намусларны...
Кайда да бер аңа ватан,
иле ни дә, теле ни соң, —
Шул ук базар сүзе:
— Сатам...

Сатылмаска һәм сатмаска —
Тукай анты, шагыйрь анты.
Ана каберендәге ташка
тамган яше ачы, татлы.

Туган илгә, туган телгә
тугры Тукай һаман сафта.
Мәрмәр ташта
чакматаштай
тора Тукай:
— Сатылмаска!

26 апрель,
1976.



***

Ни өчендер башка төштә түгел,
Үрләрендә яшем түгәмен.
Сибгат Хәким.

Үрләр күркең,
Җилләр иркен тойгач,
Авыр, диләр, түбән төшүе.
Җырлап калыйм әле, тибрәндереп
Үзәннәрнең яшел бишеген.

Ай калыккач, авыл урамнарын
Егетләрнең җырлап уравы,
Таң атканда көтү китүе,
Яшь кызларның кичне көтүе

Күңелләрдән күчә күңелләргә...
Үзәннәрдә тормыш үзгәрәк.
Үзәннәрнең ямен күрә йөреп,
Таш үрләрдә ничек түзәргә?

Җәрәхәтле җирнең күкрәгендә
Металл космодромнар күкрәве,
Күктә бомбовозлар үкерүе,
Җир өстенә үлем төкерүе,

Аһы-зары — барысы алдан күренә,
Тизрәк ишетелә үрләрдә.
Тетрәүләргә тиңдәш аваз кирәк,
Аңлаешлы барча телләрдә.

Тыңла, дөнья!
Бу атомлы заман
Кая алып бара кешене?!
Бик җырлыйсым килә,
тибрәндереп
Үзәннәрнең яшел бишеген, —
Көтүләр дә китсен таң атканда,
Яратканы булсын яратканга.

1968.



***

Сагыныштык, әнкәй, зар-интизар.
Очрашасы килә, күрәсе.
Тәрәзәгә кат-кат карыйсыңдыр,
кайтып килмәсме дип берәрсе.

Узды кышкы, җәйге имтиханнар,
таныклыклар инде алынган.
Юл төене тотып кул очына,
менмиләрме авыл тавыннан?

Имтиханнар бар да тапшырылган...
Җиңел чаклар! Җитез, кыю чак!
Таныклыклар алу җиңел түгел,
танылулар тагын кыенрак.

Биегәя үрләр, текәләнә,
авырая йөкләр, зурая.
Җирдә, күктә юллар бинихая,
юл арасы тулы киная.

Сырганаклы, кәсле юл арасы,
тарта-куа гомер сөрәсе.
Мин үзем дә карыйм юл очына,
кайтып килмәсме дип берәрсе.

Юлаучылар күрсәм юл очында,
жиңеләймәс микән йөкләрем.
Сагыныштык инде зар-интизар,
син көт әле, әнкәй, көт әле.

1976.



Яр-Чаллы

Текә ярлы, бөдрә таллы Яр-Чаллы.
Чабыш атлар сыман Чулман чал яллы.
Тарих атлы гомер акты, моң акты,
мең дә тугыз йөз ничә ел акты.

Яр буйлары язлы-көзле парчалы,
сандугачлы, аккаенлы Яр-Чаллы.
Иген икте, көтү көтте, ау куйды.
Туган илгә ятлар керсә, яу куды.

Кышкылыкка печән чапты, мал чалды.
Җәйгелеккә карбазларга кар салды.
Эш өстендә ай-урак та, һай, чалгы!
Киләчәктән әмер көтте Яр-Чаллы!

Корыч кошлар уза кыю бөркетне.
Атом-төшләр дер селкетә җир-күкне.
Ачып җибәр табигатьнең чаршавын,
чыксын Алып-батырлары, Яр-Чаллы!

Айда эзләр. Йолдызларга буй житә.
Гасыр җиле бәреп узар — кем читтә? —
Юллар кысаң, вакытларның тар чагы,
удар хезмәт узар, җиңәр барчаны.

Ишетелсен иген шавы, жыр шавы —
Җир шарының өзик тимер кыршавын!
Тотынышсын миллион куллар — как чаңны,
әйт әмерең, сүзең саллы, Яр-Чаллы!

Кара туры атлар чаба — ут күзле,
кем күтәрә жирнең йөген — шул көчле! —
Мең тугыз йөз житмеш алты — чал яллы.
Яңа гасыр капкасын ач, Яр-Чаллы!

1976.



Заманаңың кайнар сулышы

Җәйрәп ята бодай басулары.
Язгы җилдә яшел дулкыннар.
Җир астында кайнар дәрья тоеп
кайный микән әллә ул кырлар?
Шытып чыга җиргә хәзинәләр,
алтын бөртекләргә тулышып.
Җир өстендә йөри, ил өстендә
заманаңың кайнар сулышы.
Авылларга сыймый ярсу яшьлек,
Зәй буена корды чатырлар,
сулар кичеп, ташлар кисеп йөрде
легендадан чыккан батырлар.
Разведчиклар үтте шиккә салып
үзәннәрнең тыныч тормышын.
Учаклары янды йөзгә бәреп
заманаңың кайнар сулышын.
Кыр түренә басты манаралар,
сискәндереп арыш басуын.
Кеше җирнең үзәгенә төште,
серен ачып миллион гасырның.

Хәйран чыңлап торды солы кыры —
аслы-өсле җирнең уңышы!
Ургып чыкты өскә утлы ургыл —
замананың кайнар сулышы.
Ялкынланып җирдә шул ургылдан
күтәрелде Әлмәт, КамАЗлар.
Гасыр җиле, мотор гөре белән
җырга инде яна авазлар.
Яндырса да кайчак, көйдерсә дә
замананың кайнар сулышы, —
алтын алка тагып, солы кыры
бәйрәм итә көзге уңышны.

1976.



***

Манаралар, корыч манаралар
үсеп чыккан төптән, тирәннән.
Әйтерсең лә жирдән жегәр алып,
ракеталар күккә төбәлгән.

Караңгыдан халкым яралгыда
күргән киләчәге балкуын.
Ул электән яктылыкка баккан,
хыял очларына ай куеп.

Айлар хәзер юлны очлый алмый.
Яңа мәйдан, корыч манара
тамырланып керә туган жиргә,
тамырларда тормыш яңара.

1975.

Бәйрәм көнне

Укытучыга

Майда кайный чәкчәге,
карлы көздә — чәчәге...
Гел янында, күз алдында
сабый чагың, яшь чагың:

Киләләр теркен-теркен дә
китәләр төркем-төркем.
Дөньяңда алар, әйтерсең —
елгада дулкын-дулкын.

Агыла, күздән югала...
Берәмләп хатлар кайта.
Юлларын сызып, сызылып,
маңгайда сырлар арта.

Кечелек, олылык тулы
җанында әллә тып-тын?
Дәрьялар төбенә тинлә,
аһ, укытучы холкын,

йә чәчәк тамырларына...
Корт күче кебек мәктәп!
Яшь балның әчесе белән
табында кайнар чәкчәк.

1976.



Соравыңа җавап

Кешеләрне хезмәт кеше иткән.
Кем башлаган хезмәт итәргә?
Адәм заты кичә маймыл булса,
кешедән кем чыгар иртәгә?

Саңгырау тарих
сансыз сорауларның
җавапларын күмгән хикәят.
Яралгысы нидер бу дөньяның —
галимнәргә калсын ул хәят.

Аңлы затны хезмәт тудырган дип,
җил-жил генә эшләп йөрисең,
сабый бала шунда шып туктата,
җиңел генә сорап дөресен:

— Ай тәгәрәп ничек башка төшми?
— Нәрсә белән күккә асылган?
— Авырганда доктор укол ясый,
ә докторны кемнәр ясыйлар?

Бала теле белән тормыш сорый,
уйга салып гамьсез халыкны.
Әйтеп кара: кайсы әвәл туган,
йомыркамы, әллә тавыкмы?

Әүвәл тавык туса, нидән булган?
Башта күкәй булса, кем салган?
Бала сорый. Гыйлем әһелләре
җавап эзли чиксез җиһаннан.

Кайда? Нигә? Ничек?
Соравына
төгәл җавап белмим, и сабый.
Шуны беләм: Хезмәт — иң гали зат,
тик ул чишәр тормыш хисабын.

Җавапларын кайчан, кем тапса да,
тирәнәя серләр, саекмый.
Баш өстендә Ай чекрәеп йөри:
— Йомыркамы, әллә тавыкмы?

Ә бит шул Ай ничә миллион еллар
басып йөри безнең эзләргә.
Кеше Айга, йолдызларга оча
соравына җавап эзләргә.

1976.



Хирург

В. М. Поляковка

Яши алар шомлы ак тынлыкта,
аклыклары белән саваплы.
Кешеләрнең һәр сулышы өчен,
бар тормышы өчен жаваплы.
Кан саркыган ай-балталар тотып,
газраиллар баса бер якка.
Һәр сәгатьтә яшәү белән үлем
бәрелешә пычак-пычакка.
Бу көрәштә син бит ялгыз түгел,
и оттырма, кешем, ектырма! —
кылдан нечкә сират күпереннән
кылыч тотып чыга доктор да.
Нечкәлек тә анда, житезлек тә,
Сабыр тәвәккәллек — гажәеп!
Алып атса,
шәрә шәүлә булып,
кул астында йөргән әжәлне, —
таң атуга ничә күз елмаер,
ничә йөзгә тагын нур кунар!
Кешеләрнең елмаюын күреп
яшәрәләр икән докторлар.

Ә киселгән гомер өзеп китми,
кайтып-кайтып жанны камчылый.
Берәүләрнең гүрдә яткан бәхете
тәрәз шакып төнлә жан сорый.
Табып булмый аны бер хакка да...
Үлем белән мәңге низагта,
мәңге сафта —
доктор яуга керә
ак тынлыкта
пычак-пычакка.

1975.



***

Бүлдераlмаса юл басып,
үтераlмаса дар асып,
гайбәт — дошманның
иң соңгы чарасы.

Ул сазлыкта да батмасаң,
горур жаныңны сакласаң,
мактау — дошманның
иң соңгы жәтмәсе.

Башың һаман әйләнмәсә,
телең һаман бәйләнмәсә,
дуслык — дошманның
иң соңгы хәйләсе.

1976.



***

Үткәннәр бездән корбан сорамый,
хәрабәме, коралмы —
ядь итеп, кеше баш ия.

Киләчәк алдында без —
аягүрә.
Ул бездән сабак ала,
бәя бирә.

1976.



Бүреләр

Буй житкәндә мин биш бүре белән
бер очраштым япа-ялгызым.
Елга буе. Куе әрәмәлек.
Яр сыртында ак кар яктысы.

Чаган чаңгыларым чыжлап шуа.
Җил кузгалып килә. Кар туза.
Дәрес башланырга ярты сәгать,
алда әле юлның яртысы.

Өйгә бирелгән эш — кич укылган
"Тимер ташкын" — иләс башымда.
Башымдагы уйлар кар өстеннән
агып килә мәллә каршыма? —

Бер карауда белдем: этләр түгел, —
һау-һауламый, койрык болгамый;
яр аслатып килә соры ташкын,
бер кемдә дә, гүя, юк гаме.

Килә алар, гүя, әзер булып
өскә ташланырга кинәттән...

Башны чарлап, кайный йөз төрле уй,
бозлы суга сикергәндәй — тән.

Ә бүреләр...
янәшәмнән генә
миңа карамый да уздылар...
Чангыларым чая көй сыздыра,
чигәләрдә жилләр сызгыра. —

Чабам, очам...
Хәтта сизмәдем дә
мин авылга килеп житкәнне.
Урамнарда ул көн күрмәдем дә
миңа өрә торган этләрне.

Ә дәрестә "Тимер ташкын" белән
аралашты "минем" бүреләр.
Кызлар гына түгел, малайлар да
мине батыр итеп күрделәр.

Бәлки, зәһәр куркынычтан чыгып,
кыю сөйләгәнгә сабагым?
Жинелүләр һәм дә жинүләрнең
тик мин беләм, имеш, сәбәбен.

Укытучы
уңай чагыштыру
табалмады бугай ул чакта.
дөнья балалары күп очракта
параллельләр сызмый очраша.

Алга төшеп, этләр абалыйлар,
арттан килеп кайчак тешлиләр.
Ә бүреләр горур —
куылалар,
түбәнлеккә ләкин төшмиләр.

Пошынмасны янә чыбыркылап,
ваемсызны салып борчуга,
урманнарны, җәйләү, көтүләрне
арындыра алар чир-чордан.

Һичкемдә дә хәзер шик тудырмый
Фән исбатлап биргән бу бәя.
Урманнарда бүре сирәгәйсә,
урамнарда этләр күбәя.

1976.



***

Атлан атларга
ат казанмаганда,
чык мәйданга,
йөрәкне май сармаганда,
җан асраганда
бараста,
казармаларда.

Дәрәҗә җилкәнә менеп басмаганда,
муенга лавр яфраклары асмаганда
ас таганнар,
оч, тирбәл, атын!
И, батыр, атың ялында
җилфердәр
мин чиккән тастымаллар.

Шөһрәт-мөлкәтенне кеше
күпсенмәгәндә,
ярсы, яр сөй
авыл очында төнлә ут сүнмәгәндә.
Җирсәгәндә
бас сабанга,

сөр, чәч,
кара чәчеңә бәс кунмаганда.
Дус сайла
жанындагы буш урынны
синнән тарсынмаганда.
Зонтик алгач — соң!
Атыйк
мылтык тоткан чакта.
Атланыйк, әй, атка
ат казанмаганда,
язалганда
вокзалларда, казармаларда.

1976.

Идел-Кама

Туган илгә тулган ай да тарта,
ташкын сулар яз да көз таша.
Идел-Кама — ике көчле агым,
ике язмыш монда очраша.

Кама ягы — и туган як бит ул,
акчарлаклар кунса, ак бит ул.
Таңнар аткан, сулар аккан чаклар —
сагындыра торган чак бит ул.

Ярларына тулган ил моңнарын
әллә Идел коя Камага,
әллә Кама коя Иделгә...
Ике елга килеп очрашканда
таллы ярлар артка чигенә.

Идел, Чулман. Каерылган еллар.
Ике олы язмыш, ике яр.
Елгаларның ярга тарту көче —
кыяларны кыяр ихтыяр.

Юл башлады Кама чишмәләрдән,
аккаенлы яшел тугайдан.
Озаттылар хәйран көйләр көйләп,
ерак юлга каурый-курайлар.

Агыйделкәй алкын аклык бирде,
чишмәләрнең кушып моңнарын.
Су буеннан төште су юлына
давыл чәчәкләре чыңлавы:

— Акчарлаклы язлар ак канатлы,
Агыйделкәй зәңгәр ямь генә.
Мәңгелеккә түгел китүләрем,
сагынуларым калыр мәңгегә.

Салагышлар суда сал агыза,
учак яга ярда нугайлар.
Кыйратылган кабык чатырларның
көлен саклый яшел тугайлар.

Таң кызлары тезелеп суга төшә,
таң суларын алып калмага.
Яшь кызларның яшерен уй-серләрен
Әллә Кама коя Иделгә,
Әллә Идел коя Камага...

Очраштылар тирәнлек тә кинлек.
Ике олы язмыш, ике яр.
Диңгезләргә чыксаң, илләр чиксез,
туган жирдән ләкин кем туяр.

Чигенделәр, өзелделәр ярлар,
ике исем-жисем кушылды.
Ташты сулар.

Хәерле юл, Кама!
Исемең илдә кала,
хуш инде.

Идел бит ул. Идел тирән бит ул.
Тирәнлеге белән киң бит ул.
Идел буйларында яңгыраган
күкрәк тулы жырга тиң бит ул.

Сулар ага ярга кага-кага
киң Рәсәйнең ерак түреннән.
Үткәннәре, киләчәге белән
язмышына илнең үрелгән.

Сугарган ул илнең өметләрен,
суын эчкән сувар, болгарлар.
Агым суга карап, юл юраган,
бәхет эзләп чыккан волгарылар.

Жанга ирек эзләп, яшь егетләр
алкын еллар буйлап юл алган.
Дулкын белән дулкын бәрелешкән,
бөтерелгән —
егет сыналган.

Дулкыннарга дулкын, һай, уралып,
ага сулар, жирне гөл итә.
Дулкыннарны эшкә жигәр ирләр
жегәрлеге илне ил итә.

Дулкын-дулкын сулар, еллар акты,
текә басты Кама ярлары.
Кама, КамАЗ, Чаллы!
Чулман ягы,
Кама даны илгә таралды.

Һәм агылды халык —
киң Рәсәйнең
һәр ягыннан кайтты волгарьлар.
Олы Идел бер мәл туктап торды,
чал чәчләрен салып ярларга.

Кама ягы — ил туган як бит ул,
Агыйделләр белән ак бит ул.
Сулар аккан, таңнар аткан чаклар —
сагындыра торган чак бит ул.

Көянтәле кызлар җыры белән,
таң сулары белән якты яр.
Елгаларның илгә тарту сере —
кыяларны кыяр ихтыяр.

Дулкын ага дулкын каршысына,
ярлар белән ярлар очраша.
Дулкыннары иңгә иң терәшеп,
яңа киңлек, яңа юл ача.

1977.



Сузган ике кулым

(Туу турында уйлар)

I

Җырдагыдай:
Берегез анда хәзер,
берегез инде әллә кайларда.
Тизлек чоры бөтереп алып китте
бәйгеләрдә мәйдан яуларга.

Ике улым — сузган ике кулым,
хыял кораб сезгә, хис — диңгез.
Дулкыны да кубар, давылы да,
һәлакәтсез барып җитегез.

Ә мин җирнең үзәк тәңгәлендә,
теләкләрнең теләп изгесен,
ялгыз гына бүген кичәм әле
төнге хатирәләр диңгезен.

Бүгенгедәй:
Мартның утыз бере,
Иске Әлмәтнең яна барагы,

хатыннарның изге газабыннан
иске жирдә тормыш яңару.
Һич кирәкмәс чакта искә төште —
бер дипломат ачкан эч серен:
«Гомер буе ялганладым, чөнки
туган көнем — апрельнең бере...»

Стенада сәгать. Төн уртасы.
Яңа көнгә кала минутлар...
Ашык, бала, алдау көне алда,
Ялганнарга баштук юлыкма!..

Күзләремә карап, сукма, сәгать!..
Йолып калды минут арасы...
Ышан, дөнья, бүген һич харамсыз —
жирдә яңа кеше авазы!

Улым... Гомер юлың хәл иттеме
дөнья күргән шушы сәгатең.—
Ялган белмәс ихлас табигатең,
чын дөреслек эзләү гадәтең.

Шул гадәтең ижтимагый фәнгә
юнәлдерде, үзенә эз ярып.
Кеше гомерен илләр язмышына
бәйләр өчен кирәк үз жаның.

Кабатлау, йә кабатламау өчен
һәр кешенең гомере гыйбрәтле.

Кайнар чакта салкын кала бел дип,
тормыш утка салып өйрәтте.

Кайчан гына әле өебездә
бер юаныч идең, и балам...
Йөрәгемне учыма кысамын да
салкын акыл белән юл багам.

Табигатьтә, җәмгыятьтә булсын,
газап белән туа һәр яңа.
Юл башында, юл чатындагыны
ияртерлек бул син, ир бала.

Өйрәнәсең тарих сабакларын,
күзәтәсең дөнья хәлләрен,—
кан түкмичә алу юлы бармы
ил тәненнән дошман хәнҗәрен.

Төрле кануннарның чиге була,
яңарышның гына юк чиге.
Яңалыктан безне калдырмаска
вакытын белеп килдең, төпчегем.

Без, өлкәннәр, өреккәндәй иттек
«хобби» лардан, хиппиләрдән дә.
Көн бизәген йөзгә төрләндереп,
яңа яшьләр уйный әргәндә.

Мамык жептән сугып, ярлык таккан
гади чалбар хәзер кыйммәтле.

Таушалдырып кию зәвыклы, ди,
ситсы яки киндер күлмәкне.

Кире кагу, үз-үзеңне табу,
ясалмага гомум каршылык...
Үрелгәндә бергә, жил купса да,
сыгылмый, әй, сыек талчыбык.

Кабул иттек мыек-сакалларны,
«чәчле» егетләрне, ниһаять.
Мини күлмәкләрен салып, кызлар
озын чалбар кисә, бигайбә.

Бердәмлекнең танып дөем көчен,
читкә ордың чорның чүп-чарын.
Сүндермичә саклар утлы кузын
юл башында калган учагың.

Вәсвәсәгә һәвәс диссидентлар —
ваемсызга сабак вакыйга.
Бар фәннәрдән өстен ил намусы,
Ватан кануннары катгыйлар.

Өйрәнәсең тарих сабакларын,
яу кырында бармы урталык?
Артык осталарны сөйми халык,
остазларга сизелә мохтажлык.

Оста булып, остаз булып түгел,
ана булып сина юл сабам:

— Юл чатында, юл очында булсын —
Кеше булып кал син, и балам.

Фәлсәфәләр күпме —
яңа чорда
яңа кеше туу хакында.
Кеше — сәнгать,
ижат ителәдер
яшәгәндә йөрәк катында.

Юк, аннан да алда туа кеше: —
саклаганда күңел түрендә,
мәхәббәттә, яшьлек җырында,
яралгысы йөрәк серендә.

II

Сез гел юлда, өлкәнем дә кечем,
хыял кораб сезгә, хис — диңгез.
Берегез кораб булса, берегез диңгез,
ике ярда хәзер икегез.

Илдә, көндә, еллар шаукымында
Тәрбиянең миллион чарасы.
Ин мөһиме:
кеше
күңелдә үк
хыянәтсез, шиксез яралсын.

...Карурмандай серле киләчәгем,
Агыйделдәй алкын үткәнем.
Алда нидер көтеп жилкенгән чак —
син булгансың икән, өлкәнем.

Яшәр өчен жайлы урын да юк,
кияр өчен жылы туным да.
Уй-хисләрем — укучыларымда —
көн-төн эштә, мәктәп юлында.

Май бәйрәмен жырлап озатуга —
көтмәгәнчә... көткән минутлар!..
Сүзләр көчсез сөйләп аңлатырга,
күздән чәчрәп чыккан ул утлар —

гомер буе бергә жылынырга
житәр иде, саклап яндырсак...
Сыкранмасын беркем, тын кал, дөнья —
тавыш сыный нәни ал курчак!..

Иркәләүдән иртә аерганбыз,
читтән хәзер ачык күрәмен,
мин энеңне таста юган чакта
син кыйналып кайтып керәйдең.
Һәм сайладың:
хоккей, бокс, самбо!
Без андыйга гажәп битараф;
тамак төбе белән заманча жыр,
дус-иш, өзек кыллы гитара...

Сыгылмалы сөлек гәүдәң белән
кулларында йөрдең йөзтүбән...
Бу тынгысыз дөнья төрле хәлгә
әзер итеп сине үстергән.

Ил чакырды — киттең ил сакларга.
Үз юлыңны эзләп, руль тоттың.
Бүгенгедәй: йөрәгемне кагып,
миннән тормыш даулау минутың.

Кабаланып, каударланып килдең,
әзерлексез идек, бишексез.
Сайлап алу мөмкинлеге булса,
сине сайлар идем һичшиксез,—

батырлыгың, җан хөрлегең белән.
Интеллигент — нәсел-нәсәбең,
кайчан кереп калды яшь башыңа
тимер йөкләр тарту исәбе?

Ил рейслары — шпаллар, рельслары...
Сезнең индә — фәннәр өскорма.
Тизлекләрнең корыч нигезләре,
тигезләнгән таулар, чокырлар.

Яшьлек чаба юлда җан-фәрманга,
калышлардан түгел, узардан!
Юл башлаган һәм туктаган нокта —
җирдә.

Җирдән —
җанга көч-дәрман.

Резин көпчәк җирдән аергачтын,
рейсларда, диләр, арыла —
төшеп-төшеп җиргә таян, чын ул
җиргә кагылышлы ырымнар.

Ни киңәше сиңа, ни табышы,
ай үтәсен елда үтәсе...
Шикләндермә әле, тайга төне,
сискәндермә, салкын иртәсе.

Чаңнар кагып, заман чакырганда
күтәрергә КамАЗ, БАМнарны,
шикләнүне, чикләнүне белми
жилкенәдер егет жаннары.

Алышларсыз, узыш-ярышларсыз
кызу бармый дөнья, аһ, беләм,
тик үз улкаема яшәү телим
йөрәк белән түгел, аң белән.

И өлкәнем, хисси үсмерлектән
иртә чыгып киткән яшь егет,
жәя киереп, күкләр бакkан чагың —
Яшеннәргә янәш яшьлегең.

Сак чыршылар, ят күршеләр ягы,
бик ераста бездән, читтәсен,
эш кайнаган тормыш уртасында,
ук-җәяңне тартыр чиктә син.

Тимер йөкләр белән шомлы күкләр
арасыннан эзләп урталык,
уфтанучыларны сөйми халык,
юл салучыларга мохтаҗлык.

Ике улым, сузган ике кулым,
хыял кораб сезгә, хис — диңгез.
Корабы да, дулкыны да үзегез,
маякларны барлап үтегез.

Юл бакканда сезгә әйтер сүзем —
җирдә кеше туу хакында.
Кеше — сәнгать,
ижат ителәдер
сизелгәндә йөрәк катында.

Юк, аннан да элек туа кеше,
төсмерләнә күңел серендә,
мәхәббәттә, яшьлек җырында.
Сүзем сезгә — шушы турыда.

1977ел, 31 март — 1 апрель

Ә күк зәңгәр

Күк зәп-зәңгәр.
Ак болытлар йөзә
бизәк өчен.
Төркем-төркем —
иркен һаваларны
гизәр өчен.

Күк болытлар килә,
иләс-миләс
күзләп йөри, —
сибелергә
яшел үзәннәрне
эзләп йөри.

Кара болыт явы!
Бозлы яңгыр
хәнҗәр-хәнҗәр!..
Уза-туза давыл,
ә күк кала
һаман зәңгәр.

Зәңгәр күктә
ак болытлар йөзә
бизәк өчен.
Ниләр килеп,
ниләр китәчәген
сизәр өчен.

1976.



Пляжда

Рәхәт кенә эреп бара
хатирә дә өмет тә...
Диңгез, ком-таш. Назлый кояш
оялып та, көлеп тә.

Тән сихәте җан михнәтен
оныттырган — күптәнме?
Каулый диңгез,
дулкыннарга
ыргытсаң да бу тәнне.

Шаулый диңгез, инсез-буйсыз
давыл-диңгез тинсез лә!
Хәрәкәтсез, җәрәхәтсез
ташлар да юк диңгездә.



Җирем - зәңгәр Ватан

(Нейтрон бомбасы табу уңае белән)

Ураламы, сүтеләме —
әйләнә җир шары.
Сүтелеп сибәли яңгыр,
бурап ява кары.

Табаргамы, җуяргамы —
яңа ачыш фәндә.
Кыргыйлыктан яктылыкка
ыргылучы бәндә!

Тагын таптың
тереклекне
юк итәрлек чара.
Ни кылсаң, ни кылансаң да,
әллә җир битараф?!

Кешелеген Кеше җуйса,
күпкәме җир чыдар?
Балаларын күмеп куйса,
бөкересе чыгар.

Турайса да көрәялмас,
күзе төпкә батар...
Кеше үсә. Кечерәя
Җирем — зәңгәр Ватан.

Үсеп җиткәч, өзеп китмик
аның тарту көчен,
вәхшилектән яхшылыкка
омтылучы Кеше!

1977.



Казан вальсы[*]

Сагынып киләм Идел ягын, Казаным.
Миннән башка узган җәйләр, язларың.
Шаулый Идел, кайный Казан каласы,
якыная ике күңел арасы.

Саумы, Казан,
зур хыяллар
каласы!
Якыная
ике күңел
арасы.

Мәрмәр ташта киртләч-киртләч баскычлар.
Борылмалы юллар, еллар, язмышлар.
Кайнар эзләр, кайнар хисләр каласы,
синдә кайныйм мин дә — дала баласы.

Кайнар эзләр,
кайнар хисләр
каласы,
синдә ярым,
үзем —

дала баласы.

Аланнарда көтә калды пар атлар.
Алып килде мине сиңа канатлар.
Таң атканда алсу-зәңгәр дулкыннар,
ул дулкыннар йөрәкләрдә сулкылдар.

Таң атканда
Алсу-зәңгәр
дулкыннар
онытылмас,
йөрәгемдә
сулкылдар.

Очраштырдың, дуслаштырдың, Казаным.
Алып китәм Идел буе язларын.
Якын инде ике күңел арасы,
ярым белән бер ялкында янасы.

Шаулый Идел,
кайный
Казан каласы.
Сау бул, Казан,
мин бит —
дала баласы.

1977.

*М.Шәмсетдинова музыкасы.



Чал карчыга

Комнан ташлар әвәли дә дингез,
ташларны ком итә теләсә.
Ыргылалар ташлар йомарланып,
тәгәрәтә дөнья-куласа.

Әвеш-тәвеш килеп, шомаралар.
Шомармаганнары кителә.
Беләүләнә кайсы,
кайралырга
дулкын килә диңгез читенә.

Орынудан, орылудан куркып,
медузалар ача дүрт күзен.
Комлы ярда, дымлы ярда кала
тереклекнең нәни төрткесе.

Диңгезләргә китсәң, утраулар да
офыкларда калган төртке бит.
Кемнәр белән ярышырга чыккан —
ярсу диңгез сырты — ак күбек.

Дулкын, дулкын, чал карчыга сыман
ник киләсең, җәеп канатың?
Яр читенә, таш өстенә аттың
калдыкларын кайсы корабның?

Һаваларда кошлар бик арганда,
җилкәннәргә кунып, хәл алган, —
давылларга тарган кәрваннарның
каурыйларын табам бу ярдан.

Каурыйларын җыям комлы ярдан,
кайнар ташларына баш куям.
Бу дөньяның кайсы тарафы да
кайнап торган диңгез-океан.

Чал карчыга таңда ярга куна,
алып китә орган корбанын —
беләүләрдә хәтер чарламаска,
барламаска кошлар кәрванын.

Су өстенә күк орынган сызык
акмы-күкме — читтән чын кебек.
Диңгезләргә чыксаң, кыйтгалар да
ярда калган кара төртке бит.

Чуер ташлар ярда, чуар ташлар
тәгәрәшә зәңгәр дулкында.
Чарланалар ташлар,
ә шулай да
ярашалар диңгез холкына.

Диңгез тынсез —
комнан таш әвәли,
ташларны ком итә, теләсә.
Ярлар текә — тәкәбберлек түгел,
җан хөрлеге өчен көрәшә.

1977.



***

Кыелып кергән ике тау арасы —
биек тауның тирән ярасы.
Тау яраларына баса-баса
сукмак сала адәм баласы.

Урын ала тауның итәгеннән,
ризалаша, канә, түбәнгә.
Киртләч-киртләч һаман үргә үрләп,
менеп баса аннан түбәгә.

Биекләрнең бөеклеге биксез,
иреклеге ачык яралы.
Җир көйгәндә чишмә булып ага
башларына яуган карлары.

1977.



*Диңгезче язы**

(Жыр)

Ак болытлар йөзә,
кош юллары уза,
фирүзәдәй күкне күзәтәм.
Сезнең якка, дуслар,
туган якка, дуслар,
кәрван-кәрван кошлар озатам.

Таш кыялар ягы,
олы диңгез яры,
шомлы диңгез яры давыллы.
Кайтасызмы, кошлар,
китәсезме, кошлар,
көтә сезне туган авылым.

Ак томаннар төшә,
акчарлаклар йөзә,
дулкыннарга кунмый торналар.
Ерак-ерак ярдан
оча кәрван-кәрван
аккаенлы яшел урманга.

Яшел диңгез-кырлар
тургай җырын тыңлар,
сандугачлар сайрар талларда.
Исән кайта кошлар!
Кошлар сыман, дуслар,
без кайтырбыз язгы айларда.

1977.

---

*Р.Нәгыймов музыкасы.



***

Сөңге тау очында кем яшәсен,
йөрсә йөрер уйнап кыр кәҗәсе.
Изгеләрнең, бәлки, эзе бардыр,
йә Сөләйман бабам пәйгамбәрдер, —
алып менәм зур чүмәлә печән,
аяк очым белән ташны тишәм.
Җилкәмдәге йөгем, төшмә генә!..
Төннәр буе шулай... Төшләремдә.
Өндә ташымадым индә печән,
нәнәемнең истәлеге исән.
Кызыл сыер һаман сөт биргәндәй,
ник чүмәлә күтәртәсең, нәнәй?
Үрмәлимен, таям... Такыр ташлар...
Авыр йөктән иелә текә башлар.
Күтәреләм. Канга бата тезләр...
Без көчле зат, ахры, хатын-кызлар.
Ми буразнасында йөкләр, йөкләр,
сусыл печән исе, ак чәчәкләр,
казаяклар, күк күгәрчен-күзләр...
Без кыю зат, ахры, хатын-кызлар.
Хәнҗәр жилләр генә очар жирдә
ник чәчәкләр исе, нигә гөлләр?

Елмаялар елгыр, усал ирләр.
Иңнән йөгем шуа, үзем — җиргә.
Кайнар ташта калды сусыл печән,
алда әле минем кадер кичәм.
Кыя тауда сөңге җилләр оча.
Кипкән үлән сәрхабәдкә шифа.
Үрелеп кабар аны кыр кәҗәсе.
Текә таулар — күкнең таш кәүсәсе,
йолдызларның анда юлы бардыр,
йә Сөләйман бабам пәйгамбәрдер.

1977.



Тулган айга тиңлəп

Исемнəрен шагыйрь җырга сала,
йолдызларга тинли кызларны...
Ə хатыннар тулган айга охшый,
уйчан, якты нурлы йөзләре.

Моңлы. Серле — хискə бай нəселдəн,
яшь-жилкенчəк сөйсен, сайласын, —
бар да ялга талгач, ялгыз калып,
барлап чыга олы гаиләсен.

Ул-кызлары — гомер йолдызлары.
Юл сызыла, килə сəламнəр.
Озата да ана, каршы ала
юл-сəфəрдəн, эштəн, галəмнəн.

Караңгыда йөзə янəшəндə,
күзгə ташланмый ул балкышта.
Өмет сузмый уртак алкышларга,
уртаклаша, берсе ялгышса.

Уздыра ул алга җəмəгатен,
борынгының үтəп гадəтен.

Түгәрәкли китек дөньяларны
хатыннарның сабыр гайрәте.

Хәсрәтләрен артык сиздермәсләр,
хәсрәтләнсәң, алар сизгерләр.
Хатыннарны тулган айга тиңләп,
җыр җырлагыз әле сез, ирләр!

1976.



Диләр...

Синдә план гел юк, диләр,
һәм дә нефть бик аз, диләр.
Көн кадагына сук, диләр,
рекорд куярлык яз, диләр.

Ә мин авыр,
ә мин авыл
туфрагында тамырланган.
Язмышымны шул туфрактан
ахры мәңге аералмам.

Без утадык аның чүбен,
чәчтек кичә, үсә бүген, —
шул тамырлар өстә йөртә
КамАЗ йөген, заман йөген.

Синдә нефть бик аз, диләр,
заман турында яз, диләр...

1975.

Икмәк

Кунак сыен татып, кайтып килә
миллионер колхоз рәисе.
Тансыкланган кара икмәк исе,
сагынылган куе чәй исе.

Европада, дустым, кара икмәк
деликатес, ягъни, сирәк аш.
Кәнфит урынына тешләп кенә
кабасың да, тагын йөрәк ач.

Күз алдында һаман тук башаклар,
ипекәйнең калын телеме.
Барсын оныттырып, истә калган
“эпи” сүзе француз теленең*.

Аермалар илдә күп булса да,
шушы бер сүз, нинди хикмәттер,
уртак икән. Председатель күңелен
гел игәүләп торды, икмәктер.

Бу гади сүз түгел — ил табыны.
Табын яме түгел — төбәге.
Түшкә куеп ипи телгән чакта
аның безнең җанны телгәнен
онытабыз икән.

Җир тырмалап,
безме кырда арыш икмәгән?
Бер башагы өчен, ирсез, атсыз,
баш түндереп михнәт чикмәгән?

Сабыйларның анда ач күзләре...
Әрем исе. Тозлы тир тәме.
Кара көзнең бозлы яңгырлары.
Яралардан ауган ир хәле...

Кояш назы анда. Җиңү язы!
Туфрак исе туган якларның.
Сый-хөрмәтне рәис күпләп күрде,
хуш ислерәк нигъмәт тапмады.

Яңа пешкән ипи күзәнәге,
күзләренә карап рәиснең,
төшләренә керде: "Нихәл, якташ,
ничегрәк анда кәефең?

Безнең мәгълүм: былтыр арыш онын
аударырга куштың фуражга.
Киләсе көз, туган, ни күрсәтер,
орлык көтеп ята буразна..."

Чит илләрдә йөреп гыйбрәт ал, ди,
гыйбрәт алды рәис абзаң да.
Кайтты. Өйдә кара икмәк күрми,
амбарларда йөрде, абзарда.

Кара икмәк өстәлләрдә сирәк.
Улакларда терлек симертә.
Ә ипине халык, изге санап,
“Ипекәем” диеп ант итә.

Оныттык тамыны —
сыер жигеп,
безме кырда иген икмәдек?
Бер сынығы өчен, ирсез-атсыз
бил сындырып михнәт чикмәдек?

Оныттык тамыны
валчыгы да
Әжәл даруыдай чакларны?
Сатып алсаң —
дөнья базарында
ул хәзер дә алтын хаклары.

Ә шулай да гөнаһ —
эпекәйне
алтын белән бәяләүләре, —
икмәгең юк икән, нигә анда
өелеп ятмый алтын таулары!

Шуңа да бит халык, изге санап,
“Ипекәем” диеп ант итә.
Сүзе кайда ничек әйтелсә дә,
шул ант безне жиргә беркетә.

1976.

*Эпи - тук башак (франц.)



***

Яр читләре киртләч-киртләч,
чулпы дулкыннар.
Бар да бер тиң,
уйный дулкын,
уеладыр яр.
Уелдыра, ага елга,
елгыр дулкыннар...
Ял булыр, дип,
итәгендә
тал үстерә яр.
Ай үстерә, ел үстерә, —
таянычы — тал.
Горур булсын, бөдрә булсын —
тирә-якка — дан.
Агып килде чылтыр-чылтыр
көмеш чулпылар:
— Чынмы, чынмы,
ярның талы —
таянычы бар?
Суда дулкын, ярда упкын,
чайкалма син, тал,
чайкалма, тамырың ташта,

тау башлары чал...
Айкалыплар, чайпалыплар
уйный дулкыннар.
Бөгелә-сыгыла, дулкыннарны
үбә бөдрә тал.
Бөгеләсең, билкәйләрең
таладыр бит, тал?
Горур җанга ял булыр, дип,
тал үстерде яр...

1976.



Ана белән бала

Көләч кояш, жирдә нуры —
ана белән бала.
Өмет тулы бишек жыры —
ана белән бала.

Сөт аклыгы, жан сафлыгы —
ана белән бала.
Ил яшьлеге, ир шатлыгы —
ана белән бала.

Гөл тамыры, көн чәчәге —
ана белән бала.
Киләчәге — сабый юлы,
сабырлыгы — ана.

Еллар үтеп, олыгайса да,
ана өчен — бала.
Еллар имин, елмайсалар
ана белән бала.

1976.



Бер хатирә

Бик чакырдың,
көткәнсендер,
турыбыздан үткәнсендер,
ялындырып сөйдемме?
Рәнҗеттем сине хаксызга.
Исемнәрне нахак сүздән
әллә йолмак идемме...

Алар ак. Түгел янәшә.
Идел өсләрендә рәшә.
Акчарлак хатлар гына
очарга талпына кулда,
ике күзләрем дә юлда,
янында ятлар гына.

1975.



***

Беләм инде,
тере кеше түгел,
тормышында бары бер рух мин —
үзең эзләп тапкан риваяте
хатын-кызлар дигән ыругның.

Өйрәнергә мәҗбүр хәзер үзем
ул ыругның серле тарихын,
яңартырга синең белән бергә
һәр күгәргән төсен, хәрефен.

Һәм нурлана, хозурлана бара
син табынган саен сихри зат —
алиһәләр белән жарияләр
өммәтендә туган риваять.

1976.



Сау бул, язым!

Су өсләре җем-җем көмеш дага —
кар сулары чаба дәрьяга.
Ташкыннарга төшеп агыйм әле,
ярсуларга табыйм бер дәва.

Бәхилләшми генә сау бул, язым!
Аерылабыз диеп уфтанма,
энҗе чыклар булып син кайт әле
Зәй буена җәйге бер танда.

Көзләремә кайт син, басуларда
яшь уҗымнар булып яшеллән.
Яңгыр булсаң, сагыну яшьләремнең
тамчысын да синнән яшермәм.

Араларда йөрер зәһәр жилләр,
һай, ураулы юллар, ураулы.
Кайтырыңны әйтеп, тәрәз каксын
салкын кышның шашкын бураны.

Баш орсаң да ташка, булмый икән
вакыт агымына карышып.

Су юлыннан китеп югалсак та,
ил жырына кайтып кавышыйк.

Сау бул, язым! Әйдә, бер тын алыйк,
башкайларны салып ярларга...
Су өсләре жем-жем көмеш дага —
еллар чаба чиксез дәрьяга.

1976.

***

Мөкәррәмәгә

Комсызга — ком,
безгә ташлык ярый,
бишташ уйнап үскән кызлар без.
Ком өстенә кала саласы юк,
сабый чакны таштан эзләрбез.

Шыксызларга — ышык,
безгә — кояш!
Көлә-көлә бергә йөзәбез.
Күзләренә кереп очраштылар
кояш белән диңгез йөзгә-йөз.

Диңгез юмарт —
тозсызга тоз житә,
безгә тансык зәңгәр дулкыны!
Офыкларга кояш алып китте
батыр Аргонавтлар токымы.

Дулкынлана ай да су өстендә,
тулган аймы, безме хислерәк?
Ярсызлар да очрый, әрсезләр дә —
ятсызга — ят,
безгә үз кирәк.



***

Сүз белән ышандыру да
исбатлау мөмкин түгел —
ике хис тә ике рух ул:
мәхәббәт һәм тугрылык.

1976.



***

Тынгысыз уйларым белән
серләшеп йөргән көнем.
Бер аһәң килде ерактан,
“Сагындым” дигән бер өн.

Белмимен, ышаныргамы?
Аһ, нигә ышанмаска!
Сүзе чындыр, ямансудыр
яшәве миннән башка.

Югыйсә, хәтта гөлләр дә
мин юкта сынсыз сула...
Секундлар шуышканга да
сискәнгән чаклар була.

Эзләнәм нигә шымчыдай,
юксынуларыммы чын?
Сүзенә ышаныр өчен
үземә ышаныймчы.

1975.



Уйламагыз, кызлар

Уйламагыз, уйламагыз, кызлар,
таш бәгырьле, диеп, егетләр.
Малайларны сез бит егет иткән,
сөю ялкынында илерткән.
Бер әнисе белә, тик әнисе
улкаенең яшерен газабын,
белеп ята бит ул, сизеп ята
төн сыздырып шигырь язганын.
Яза, сыза... Тиле хисләр дөрли
җәйге төннең зәңгәр чыңында.
Таң атуга җырлый ул шигырьләр
гитараның җиде кылында:
"Күзләреңне миңа төбәлдермә,
карашыңнан бүтән исермәм,
алдавыңны синең гафу итмәм,
хыянәтеңне мәңге кичермәм..."
Гитараның сыкрый җиде кылы
җиделәргә телеп бәгырьне.
Кызлар, кызлар, сез дә бик ягымлы,
ана өчен улы кадерле.
Төнне кичеп, егет чыгып китә,

ерак китә ташлап,
ташланып —
ялкыннардан сикерә дулкыннарга,
уттан суга сала башларын.
Тик баш ими...
Кайсыгыз соң аны
сөю газабында илерткән?..
Уйламагыз, уйламагыз әле,
таш йөрәкле, диеп, егетләр.

1975.

*Туй җыры**

Ай-кояш йөзләре,
кояшлы күзләре.
Табышкан, кавышкан
пар былбыл үзләре.

Карлыгачкаем ла,
сандугач каенда.
Сайратыр, һай, матур
яр булгач янында.

Тал-чыбык биллəре,
бал кебек телләре.
Гөрләшкән, серләшкән
бәхетле көннәре.

Бер генә дигәне,
юк илдә тиңнәре,
яр булсын, пар булсын,
бер булсын серләре.

Аллары, гөлләре,
гөл бакча илләре.
Узмасын, тузмасын
бәхетле көннәре.

1978.

*Ш. Кашапов музыкасы.



Боз аккында, атлар чапканда

Идел ярларында гөрләвекләр.
Идел талларында ал бөре.
Боз кузгатып, җил тузгытып килә
табигатьнең акбүз апреле.
Акбүз ат өстендә чая чапкын —
төшләремдә күргән хыялым,
җилфердәтеп чаба җитен ялын,
боз җиленнән кинәт уянып.
Ага бозлар, гөрли яз туйлары.
Җан эшеме, әллә дан эше —
актарылган хисләр ярышуы —
яшәешнең тиңсез табышы.
Бозлар аккан, атлар чапкан чакта
читтәрәк тор, акыл, үр саклап.
Ат чабышы, җыр тавышы тынгач,
соңгы хөкем синдә, аксакал.
Синең хөкем кырыс, дәвамлырак.
Бу бүген дә шулай, элек тә —
кайчак гаскәрләрнең һәм илләрнең
язмышларын мизгел хәл итә.

Фидакарьләр, фанатиклар җинә,
таң калдырып дөнья хачларын —
амбразура каплый йөрәкләре,
дарга менә фидай башлары.
Тантаналар һәм хаталар белән
йөрәкләрнең уртак язмышы.
Җырга салган Чулман-Идел ягым,
синең даның — минем җан эше.
Актарылган хисләр язмышына
син ваемсыз икән, и акыл,
боз акканда, атлар чапкан чакта
мин йөрәгем белән мөстәкыйль.

1977.



***

Бер ханымга

Диңгез аръягыннан килгән шаһның
шаһинәсе кебек атлавың.
И сылу зат, моңдый йөрешләрне
кайда күрдең, ничек ятладың?

Борын буйлап кына өстән аска
карауларың — илдә бер генә.
Каршы очраучылар синең юлдан
сөреләләр гүя сөргенгә.

Янәшәңдә — дәрәҗәсе белән
бергә йөри торган исеме —
беләсеңме, кемнәр салган ташка
басып күтәрелде, и сөекел?

Ул ташларның арасына керсә
әгәр синең үкчә кадагың?..
Кайда күреп, ничек отып алдың
күз безләрен җанга кадауны?

Урының синең сәхнә дисәм инде,
шаһинәләр сирәк уйнала.
Болай булгач, адәм арасында
урын да юк сина, и бала.

Болай булгач, тик бер теләк сина:
сабыр, тыйнак булсын юлдашың.
Исемегезне өстә йөртә торган
дәрәҗәсен берүк жуймасын.



Гамил Афзалга

Алай аяк чалды дөнья,
болай итеп карады,
ожмах белән ымсындырды,
тәмуг белән янады.

Ут йотып та, су кабып та,
сабыр гына чыдадың.
Җылытып та, көлдереп тә
дус-дошманны сынадың.

Тәмугы да өркетәлми,
ожмахы да абруйсыз.
Утта янмый, суда батмый
кеше җаны — шигъри сүз.

1970.



Шамил Бикчуринга

Дөнья сиңа күпләп биргән
мәхәббәтең, нәфрәтең дә.
Шатлыкларың мулдан булса,
кысыр түгел хәсрәтең дә.

Бу дөньяда уен түгел
ярты гасыр яшәүләре.
Ярсып, ярсып бер сөйләсәң,
телең тешләп, дәшмәүләре...

Әйтер сүзең бетмәгәнен
сизәм Җирдә атлавыңнан —
фонтан булып ургып чыга
җирнең җиде катламыннан.

Башкаладан читтә булсак,
без бит эшнең үзәгендә.
Каләм алдың син, инанып
җиңәренә, түзәренә.

Ил бакканда, җил какканда
бар кемнәрең?

Үз тиңнәрең! —
Төптән сөреп баручылар
җирнең каты токымнарын!

Дөнья сиңа күпләп биргән
мәхәббәтең, нәфрәтең дә.
Шатлыкларың мулдан булса,
кысыр түгел хәсрәтең дә.

Январь,
1978.



***

Җил исте дә, очтың, яфрак атлы
и самими яшел тереклек,
һәм берәүнең күкрәгенә яттың,
син әсирме, әллә ирекле?

Охшагансың кеше йөрәгенә,
тармак-тармак тере тамырың.
Бер кыз сине үз учына салыр,
бит алмасы белән кагылыр.

Аннан куяр китап арасына...
Тамырың җирдә, төсең бизәктә.
Күккә очтың, яфрак, җиргә төштең, —
Җырга күчтем диеп исәплә.

Яфрак-яфрак яшел ямьгә чумса,
яшеннән соң күкрәп, һәр тараф,
чыклы таңда туган моңлы җырга
бер йөрәк тә калмас битараф.

1978.



***

Тау тарта мине, тау тарта,
туган якларга кайтарта.
Исәннәр әле, исәннәр —
кыяда янәшә исемнәр.

Су тарта мине, су тарта.
Җәйләрдә җирсәтә, сусата.
Тәгәри чуер ташлары,
ярларга салып башларын.

Ай тарта мине, ай тарта, —
тукталып, тотылып торганы,
безне бер янәшә күргәне
туган якларга кайтарта...

1978.



Сабыр канатлары

Сабыр канатларым, сабыр канатларым...
Кулым сузып калдым, чапты пар атларым!
Тик ымсынып калдым, кыенсынып калдым,
сөйгәнемнән, гүя, нахак талак алдым.

Ыспай кунаклармы, оста караклармы —
чыбыркылап куды чаптар пар атларны.
Янар инде атлар сугармаган килеш,
төнгелеккә калыр тугармаган килеш...

Йөгерә-атлый китәм җәйләүләргә таба,
җәяүләргә кала, җәяүләргә кала,
сыгылмагыз әле, сабыр канатларым,
бер йотымга сусап, көтәдер атларым.

Ир канаты аттыр, кыз канаты актыр.
Ак канатка атмас, булса ул чын батыр.
Бәлки эзләп тапкан чапкын туры атларны
тугарылмый чапкан атлар яраткандыр.

Узалмыйдыр атлар тимер авызлыксыз...
Тик ямьлерәк иде дөнья явызлыксыз.
Канга тузсын тезләр, егыла-тора атлармын,
тик сынмасын гына сабыр канатларым.
Сабыр, канатларым.

1978.



Елмаю

Ләбибәгә

Очрашканда балкып елмаясың,
сөенечең синең чиксездер.
Хәсрәтләреңә бер дә юктыр дисәм,
кеше хәсрәтенә син сизгер.

Сынап кына тагын елмаясың,
ялгыш кына әллә рәнжеттем?
Елмаюың күзләрендә эри,
серләреңне белү бик читен.

Тыйнак кына һаман елмаясың,
йөрәккәең әллә яралы?
Елмаюын, дулкын кайтаргычтай,
яралаудан саклый ярларны.

1978.

***

Җил иркендә сине күрдем,
җилкендем дә илердем.
Хыялдагы сурәтеңә
җан өрдем мин, өн бирдем.

Алиһәләр аһ иттеләр,
тал-тирәкләр яшь түкте.
Кем күпсенде, кем юксынды
күккә ашкан яшьлекне.

Алып очты җил-өермә!
Ераклашты тавышың...
Ак кәгазьгә кара сөрмә
булып төште сагышым.

Алиһәләр аһ ордылар.
Тал-тирәкләр яшь койды.
Таллар — суга, су — дәрьяга,
дәрья ярга ашкынды.

Шул мизгелдә син — сәгадәт.
Сизгер җанга — чын сәнгать!
Ярдан алдым, җырга салдым
сурәтеңне, мәхәббәт.

1974.



Жил дә үтмәс

(Жыр)

Атландык икәү чаптар атларга,
язгы ташкыннар ярсып акканда.
Куллар бирештек мәңгегә
тормыш буйлап бергә атларга.

Жил-давыллардан, дустым, арала,
кеше сүзләренә карама.
Уйлар бер булса юлларда,
Жил дә үтмәс безнең арага.

Булыйм юлдашың юлсыз калганда,
булыйм сердәшең, уйга талганда.
Шатлыкны ялгыз үткәрмә,
кайгы килсә, ялгыз күтәрмә.

Уйлар бер булса юлларда,
жил дә үтмәс безнең арага.



Ерак Көнчыгыш...

Юлдаш булып көнгә,
кояш булып бергә
ашыгып кайта хатлар
синең яктан.

Көннәргә юл биреп,
җилләренә бәрелеп,
кичегеп бара сиңа
минем хатлар.



***

Без дуслармы, әллә таныш кына?
Әллә нишләп синең язмышка
карый алмыйм әле тыныч кына.
Кышлар озын, нигә яз кыска?

Эш көнендә — дөнья мәшәкате,
Бәйрәмнәрдә кеше бәйрәмчә...
Минем уйлар зилзиләсе булыр,
Синең янда җилләр әйләнсә.

Кеше сүзе кеше үтерә, ди.
Бер җылы сүз күккә күтәрә.
Дуска гына әйтеләсе сүзләр
әйтелгәндер инде бүтәнгә...

1967.



***

Фәлән вакыт гомереңкалган, диеп,
син куркытма, доктор, өркетмә, —
күреп торам: язмыш өстәлендә
имза куелмаган беркетмә.

1978.



***

Кешеләрдә этлек табыр,
жанга кытлык салыр, —
бер сөйми, бер сөелми дә
Сүнеп бара шагыйрь.

1978.



***

Кеше күңеле яктырадыр
Яхшылыгын күргән саен.
Үзең эткә әйләнәсең,
“Син көчек!” — дип өргән саен.

1978.



Кәккүк

(Җыр)

Туган якка кошлар кайтса,
урманнарда кәккүк патша.

Кәк-күк, кәк-күк.
Мин — җир, син — күк.
Кәк-күк, кәк-күк,
син — җыр, яшьлек.
Кәк-күк, кәк-күк,
җырлап яшик!

Аерылулар син юрама,
илсез, җирсез җыр югала.

Кәк-күк, кәк-күк.
Мин — җир, син — күк.
Кәк-күк, кәк-күк,
син — җыр, яшьлек.
Кәк-күк, кәк-күк,
җырлап яшик!

Туган илдә зәңгәр күкләр,
жырла, жырга юк бит чикләр.

Кәк-күк, кәк-күк.
Мин — жир, син — күк.
Кәк-күк, кәк-күк,
син жыр, яшьлек.
Кәк-күк, кәк-күк,
жырлап яшик!

1976.



***

Шул ук апрель.
Шул ук шарлавыклар.
Бөреләрен ачкан тирәкләр.
Һәм без икәү.
Ләкин сер сөйләми
күзләр — күзгә,
йөрәк — йөрәккә.

Ә без икәү балкып торган язда! —
Җиде яттай.
Сәер бу халәт.
Җеназасын озатып кайтуыбыз —
сүнде кадерлебез — мәхәббәт.

1967.



Төшен - төшкә

Берәүгә дә багышламый гына
үзем өчен язам, жан өчен.
Башта уйлар, жанда көйләр чыңлый,
очын очка килә ялгыйсым.

Жил иркенә чыгып жилгәрәсем
төшен — төшкә, чүбен — кибәккә.
Арыш басуының алкышлары
жанга иңә, тынны киңәйтә.

Башакларның бардыр бер исәбе,
күрәләрме әллә охшашлык? —
Уңыш туе өчен жилгәрелү —
ул, мөгаен, үзе бер шатлык.

Жиргә салган һәрбер бөртек тере,
яшәрерләр кабат язларын.
Башаклар бит алар тормыш өчен,
кеше өчен сала башларын.

Битне сыйпый арыш башаклары,
хатирәләр тынны киңәйтә.

Эш өстендә уйлар җилгәрелә
төше — төшкә, чүбе — кибәккә.

Яшь чакларым, алтын башакларым!..
Сорамадык, хәтта: кем өчен —
яшьтәшләрем янды яшәү өчен,
яшәү биргән туган җир өчен.

Үзем өчен генә җырлый алмыйм,
арышларым, сезгә багышлыйм.
Урган, чәчкән, яуда калганнарны
онытмасам, җырда ялгышмам.

1978.



Сер алдым

Икенче кат килдем бу дөньяга...
Көн утырды, буран басылды.
Дусның кадере артты. Дошманның да
асыл йөзе, шөкер, ачылды.

Ачыкланды төсләр! Хисләр кискен.
Әмма акыл инде өстенрәк.
Җиргә мәңгелеккә килгән кебек
яшәп калсын көнчел мескеннәр.

Якты көннән алар бер китсәләр,
белеп торам, кире кайталмас,
Очрашасы килә йөзләр-йөзгә,
сезнең белән, "яшь һәм ят алмаш!"

Һәм әйтәсе:
Яшәү — иң чын бәхет.
Үтә кырыс, үтә нәзберек,
күз дә тия бик тиз, сүз дә тия —
бәхет күпне сорый, аз биреп.

Нәфес сузсаң, бөтенләйгә кача,
эзлә,
эзәрлекләү — әсирлек.
Безнең яшәү — илгә бәхет кошын
очырып җибәрүгә әзерлек.

Очышларның ул иң хәвефлесе,—
төпкә тартса заман чоңгылы,
гәүдән белән бергә хатирән дә
илдән китә түгелме соң ул?


Канатсызны күккә чөймик әле,
егылалар, үрчи сукбайлык...
Борылдым да кинәт йөзләр-йөзгә,
өзеләсен сизеп сукмакның —


очканында күрдем бәхет кошын,
канатларның көчен сынадым;
Кемнәр эзләр, кемнәр эзәрлекләр —
киләчәктән шулай сер алдым.

1976.

“Утта янмаган ялкын”

Сажидә Сөләйманова ижаты турында каләмдәшләре





Мөдәррис Әгъләмов, шагыйрь:

«Сажидә Сөләйманова биеклеге ул ир-ат шагыйрьләр дә әйтергә курыккан чынлыкны әйтә белүдә.

Сажидә апа шигъриятkә соң килде, олыгаеп, эченнән әрнеп, янып... Өлгергән, шигъри образлар белән тәмам тулышкан иде инде ул. Җидесигез ел эчендә шуңарчы исеме дә билгесез шагыйрә баш әйләндерерлек биеклеккә күтәрелде, ир-ат шагыйрьләр өйрәнерлек, Туфаннар хөрмәт итәрлек Шагыйрь булып җитеште.

Әгәр Ходай аңа Анна Ахматова гомерен биргән булса, без аңа үлгәнче үк һәйкәл куярга тиеш булыр идек.»

"Сөембикә", март, 1997ел.

Нил Юзиев, филология фәннәре докторы:

«Сажидә Сөләймановаңың әдәбиятка килеп керүе күпләр өчен көтелмәгәнрәк һәм хәтта бераз сәеррәк тә булды шикелле. Хикмәт шунда: Сажидә укытучы да, журналист та, гаилә йөгән тартып баручы ир хатыны да, балалар анасы да. Поэзия өчен яше дә яшьләрдән түгел. Ире дә ижат кешесе—шагыйрь. Татарда исә электән килгән шундый бер язылмаган гадәт һәм әдәп бар: ир белән узышу макталмый. Шуңа күрәдер дә әле яшь чакларында шигырь язып каләм тибрәткән кайбер хатын-кызлар, язучы хатыны булгач, шигъри энҗеләр эзләүдән туктап калдылар. Сажидәнең дә озак вакытлар кулына каләм алмыйча тел яшереп йөрүе минем үземдә, менә шул әдәп белән бәйле түгелме икән, дигән фикер уята. Бәлки, алай да түгелдер—анысы ачык: гореф-гадәтләрне, тормыш басымын жиңәрлек көч таба ул үзендә. Башкалар, яшьлек жилкенүеннән, "тилелегеннән" арынып, шигырь язудан туктаган чакта, киресенчә, аңа шигырь жене кагыла.

"Сажидә кайсы өлкәдә — ижтимагый-политик мотивларны жырлаучы публицист яки вакыйгалар тезмәсен сурәтләгән эпик шагыйрь буларак-

мы, әллә шәхеснең күңел тирбәлешләрен, йөрәк мизгелләрен ачучы лирик буларакмы көчлерәк?" — дип сорасалар, һич шикләнмичә мин үзем: «Йөрәк өлкәсендә — микромирда ул күпкә көчлерәк!" — дип җавап бирер идем...

Эчке күңел тирбәлешләрен җырлауда Сажидә үз стихиясендә. Биредә ул чын мәгънәсендә виртуозлык дәрәҗәсенә күтәрелеп куя.»

С.Сөләйманова. "Сабыр канатлары", Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981 ел, кереш сүздән.

Хәсән Туфан:

«Сажидә!

Исеңдәдер, без синең әдәбиятка килүеңне сокланып, шатланып каршы алган идек. Татар поэзиясенең Анна Ахматовасы булачак бу, дип сөенгән идек. Әле дә шулай уйлыйбыз.

Бер генә язсаң да, берәгәйле яз. Чын шагыйрь юлы иң катлаулы, иң авыр, ләкин иң гүзәл, олы, бай, бәхетле юл ул...»

9 июль 1968 ел.

Сибгат Хәким:

«Сажидә шигырьләре беркемне дә кабатламыйлар. Кабатлана торган шигырьләр алар кемгәдер охшарга тырышып язылган шигырьләр. Ә Сажидәнең үз кичерешләре, фәкать үз хисләре. Алар — фәкать хатын-кыз гына тойган, хатын-кыз гына әйтә алган шигырьләр. Алар вак түгел, тар түгел, зур, ачынулы, хәтта усал.»

гыйнвар, 1975 ел.

Илдар Юзеев, Татарстанның халык шагыйре:

«... Ул — чор кызы, аның омтылышы, хисе якты, газаплары да җиңеп чыгарлык, күз яшьләре дә кояш нурында бик тиз кибәрлек. Шигырьләрнең холкы да кызларча: тыйнак, сабыр, жирдәге һәр аһәңне нечкә тоючан, әммә кирәк чакта усал, кискен дә... Хисләрен ул кычкырып әйтмәс, анысы юл арасында булыр. Яратуы артык тирән булса да, оялчан кинаяләр белән әйтер. Сөям, сагынам дигән сүзләр аз, ә бит күпчелек шигырьләр шул хакта.»

"Ян, шагыйрә, ян!", "Казан утлары", октябрь, 1976 ел.

Гамил Афзал, Татарстанның халык шагыйре:

«С.Сөләйманова әзрәк символист та кебек, әзрәк романтик та, тик ул таш бәгырьле кырыс реалист кына түгел. Аның табигате дә матур, кешеләре дә күркәм, аларның уй-тойгылары да шигъриятле, гүя ул дөньяны сафландырырга, бизәргә генә килгән диярсең.»

"Фал китабы", "Социалистик Татарстан" 28 июль, 1974 ел.

Рәдиф Гатауллин, шагыйрь:

«...Чорыбыз үзе күтәргән бу талант башта ук ике канаты белән күренде: беренчесендә — сабырлык, моң белән өретелгән наз, жылылык булса, икенчесе исә чын мәгънәсендә гражданлык бурычын, пафосын үз иткән, һич курыкмый заман йөген үзенә күтәрә алган, ир шагыйрьләргә дә үрнәк булырлык көчле канат иде. Ул ташламалар көтмәгән кырыс, үз-үзенә таләпчән шагыйрә булды.»

"Моң һәм көч канатлары", "Социалистик Татарстан", 4 октябрь, 1986 ел.

Әмирхан Еники, Татарстанның халык язучысы:

«Сажидә!

Мал иясенә охшый дигәндәй, синең үзең кебек тыйнак, сөйкемле, кешелекле шигырьләреңне мин чын күңелдән яратам һәм хөрмәт итәм.»

8 октябрь, 1986 ел.

Гомәр Бәширов, Татарстанның халык язучысы:

«Сажидә!

Шигырьләреңнән ялкынлы дәрт, эчке бер куәт бәреп тора, әйтелмәгән уйларың әйтелгәннәреннән дә күбрәк, баерак икәнлеге сизелеп тора...»

29 июнь, 1974 ел.

Зөлфия, Үзбәкстанның халык шагыйрәсе:

«Шигырьләрегез оригиналь, һичберкем шигырьләренә охшамый. Аларда зур дөнья авазы. Табигать һәм җәмгыятьтәге һәммә вакыйгаларга, күренешләргә сизгер, үз күзе белән карап, үз йөрәге белән тойган нәфис, гаять тирән чынбарлык бар аларда.»

2 август, 1974 ел.

Мостай Кәрим, Башкортстанның халык шагыйре:

«Җырлы - моңлы, сагышлы Сажидә! Кайсы чак бик матур сүзләр дә поэзиядә бушка әйтелә. Синең һәр юлыңда тойгы биографиян (эмоциональная биография), атылган бөркет канатларыннан коелган кызыл каурыйлар шикелле, көннәрең, сәгатьләрең, минутларың ята...»

3 октябрь, 1976 ел.

Гәрәй Рәхим, шагыйрь:

«Сажидә Сөләйманова — татар халкының яратkан шагыйрәсе. Ләкин ул, талантлы шагыйрә һәм киң күңелле кеше буларак, үз халкына гына түгел, ә элекке СССРда яшәүче башка милләтләргә, бигрәк тә төрки телле халыкларга да киң билгеле иде. Мин Мәскәүдә, РСФСР Язучылар берлегендә эшләгән елларда моны аеруча ачык күреп яшәдем. Мәскәүдәге шагыйрь һәм шагыйрәләрдән тыш, Сажидә апа ижаты белән Урта Азия, Кавказ, Урал һәм Идел буе төрки әдипләре кызыксына, аның поэзиясен үз телләренә тәржемә итәргә тырышалар иде.

Бүген Сажидә Сөләйманованы, һич икеләнусез, халыкара шагыйрә дип әйтеп була.»

Ренат Харис, шагыйрь:

«...Сажидә апа кеше йөрәгендәге ярату хисенең бөтен төсмерләрен, буяуларын, алай гына да түгел, аның тавышлы яңгырашын үзенең шигырьләренә сала алган. Аның һәр шигыре — төсләр поэзиясе, хисләр поэзиясе һәм, шуның өчен дә, Сажидә апаның күп шигырьләре афоризмга әйләнде:

Киткәннәрнең юллары озын,
Көткәннәрнең көннәре озын...—

Бу татар халык мәкале түгелмени?
Йә булмаса:

Якты лык суда батмый,
Ялкын утта янмый.

Бер карасаң, шигырь бик гади сүз тезмәләреннән тора кебек. Әгәр дә бу сүзләргә Сажидә апа ижаты аша карасаң, ялкын — Сажидә апа үзе, ә утта янмый торган хис — мәхәббәт хисе.

Сажидә апаның хиссиятле фикере, бер дәрәҗәдә, урта гасырда яшәгән, бүген яшәүче һәм бездән соң яшәячәк кешеләргә дә аңлаешлы, якын һәм шулай булып калачак та.

Аның ижаты безнең өчен үрнәк ижат һәм бу ижат яшәячәк.»

(1997 елның 16 мартында К.Тинчурин исемендәге Казан Дәүләт драма һәм комедия театрында уздырылган С.Сөләйманованы искә алу кичәсендә әйтелгән сүзләрдән.)

Шәүкәт Галиев, Татарстанның халык шагыйре:

«Моңлы, уйчан шигырьләре белән танылды Сажидә Сөләйманова, исеме халык күңелендә, халык телендә. Юбилейлар уңае белән генә түгел, көндәлек тормышыбызда жырлары, шигырьләре, әсәрләре яши, еллар сынавын үтеп, шигърият күгендә калды ул.»

"Кеше барыбер кошлар нәселеннән", "Сөембикә", 1997 ел.

Кояш Тимбикова, язучы:

«Бездә шундый гадәт яши — шигъриятебезнең уңышын да, кимчелеген дә, тарихка китеп, Тукай иҗаты биеклегеннән торып бәялибез. Бөек Тукай нигезләп калдырган байлыкка тагын ниләр өстәлгән? Шул мираска лаек нинди әсәрләр иҗат ителгән? Сажидә Сөләйманованың иҗаты, сүз дә юк, баштанаяк әнә шул мирасны тагын да баетуга хезмәт итә. Шагыйрә бөртекләп жыйган һәр табышын олы шигъриятебез дәрьясына тамчылап өсти, гүя шул шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр куя.»

"Тукайга — чәчәкләр", "Социалистик Татарстан", 8 апрель, 1978 ел.

Нажар Нәжми, Башкортстанның халык шагыйре:

«Бигрәк мужественный кеше син, Сажидә! Ижатта да, тормышта да; хатын-кыз мужественный булмаса, шагыйрә булалмый.

Бу хатны башлаган чагымда, синең бик каты авыру икәнеңне, аннан соң бик авыр операция кичергәнеңне белдем. Операциядән соң бик озак реанимациядә ятканынны да ишеттем. Шушы газаплардан соң да менә дигән шигырьләр яздың — болар үзе генә дә искиткеч батырлык иде.

Сажидә!

Хатымны шушы урынга җиткәч, җан тетрәткеч хәбәр килде... Бу хәбәргә ышансаң да, ышанмасаң да чараң юк — ул хакыйкать иде: син вафат булдың... Башта ни эшләргә дә белмәдем. Үлгәннәр турында, гадәттә, истәлек язучаннар, миңа да шул юлга басаргамы? Юк, хатымны дәвам итәм, чөнки ул синең гомерең турында, ижатың турында, димәк, син тереләрдән тере. Чын шагыйрьләр үлмиләр, аларның шигырьләре, үзләренең тудыручыларын үлемсез итәләр.

... Хәсән Туфан миңа бервакыт: "Шигырьдә боль булырга тиеш,— диде...— Боль! Высокая боль!"—дип өстәп куйды. Безнең телдә аны күңел

сызлануы, күңел әрнүе дип аңлатырга мөмкиндер. Шундый әрнүләрне мин Сибгат Хәкимдә күрәм... Шундый сызланулар, әрнүләр синдә, Мостай Кәримдәге шикелле, тирән яшерелгән.

... Синең китабыңны укыгач, әлеге шул әрнүләр (высокая боль) турында уйлануларым юкка түгел. Күренүенчә, бу сыйфат синең һәрбер шигыреңдә дип әйтерлек чагылмый (киресенчә, синдә сокланну күбрәк), аның шулай булуы табигый да, югарыда әйткәнемчә, алар бик өстә ятмыйлар. Бу әрнү — мин аны якты әрнү дип тә әйтер идем — синең поэмаларында ярылып ята.

... Үлгәннәргә: "Тыныч йокы!"—диләр. Чын шагыйрь мондый йокыдан мәхрүм. Әгәр дә сиңа, вафат булган кешегә, хат язып утырам икән, димәк, сиңа тынычлык юк дигән сүз. Чөнки чын шагыйрьгә үлгәч тә тынычлык юк. Гомергә шулай булсын.»

февраль — май, 1980 ел.

Нәҗибә Сафина, шагыйрә:

«Дөнья... сүздән, күздән, үздән тора. Гомер бакый йөрәкләребездә яшәячәк шагыйрәбезгә сүзләр дә, үзләр дә, читләр дә тия алмады. Андыйлардан ул өстен иде. Өстен! Аңа шигърият үзе аһ итте. Аңа шигъриятнең үз күзе тиде. Шигъриятнең күзе каты икән шул!.»

"Шәһри Казан", 4 октябрь, 1996 ел.

Тәлгат Галиуллин, язучы, академик:

«... Сажидә Сөләйманова иҗаты — татар тәнкыйтендә һәм әдәбият белемендә әлегә тиешле бәясен алмаган күренеш. Бер яктан, ул татар хатын-кыз поэзиясен яңа фәлсәфи, мәгънәви һәм тәэсири югарылыкка күтәреп, XX гасырның Анна Ахматова, Марина Цветаева кебек күренекле шагыйрәләре белән бер дәрәҗәгә ирешсә, икенче яктан, С.Сөләйманова 60-80нче еллар татар шигъри фикерләве үсешенә уңай тәэсир ясады. Аның исеме татар поэзиясендә кешенең рухи дөньясына якынаю, фәлсәфи тибар үсү белән бәйле. Вакыт агыннан бик кыска аралыкта ул татар шигърияте күгендә тирән, мәңге сүнмәс эз калдырды.

Айдар Хәлим, язучы:

«... Сажидә Сөләймановага яшел байраклар күтәреп, мәйданнарда "Азатлык" дип кычкырып йөрергә насыйп итмәде, бәлки ул аны, исән булган булса да, эшләмәгән дә булыр иде, әмма милли фикернең, милли теләктәшлекнең иң алдынгы сызыгында торган булыр иде. Шагыйрьнең алтын фикере һәм кайнар хисе кечкенә бүлмәдән торып та мәйданнарга бөек дәва булып тама ала һәм тамарга тиеш тә. Менә ни өчен бүгенге татар милли-азатлык хәрәкәте белән Сажидә Сөләймановa ижатын иң нечкә, иң тере җепләр бәйли. Моның нигезендә шагыйрәнең Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Нәжип Думави, Габдулла Тукайлардан килгән миллилеге ята.»

"Ул йөрәге белән мөстәкыйль", 1994 елның 4 нче мартында Әлмәт татар драма театры бинасында үткәрелгән С. Сөләймановa исемендәге әдәби бүләкләрне беренче мәртәбә тапшыру кичәсендә әйтелгән сүзләрдән, "Аргамак", 5/1994 ел.

ЭЧТӘЛЕК

Ә.Маликов. Табулар, югалтулар... 5

I - бүлек

Кыр казлары

Тормыш, исәнме! 15
Кеше 16
Бәхет 17
*Кеше барыбер кошлар нәселеннән 18
Җан атып кайтып киләм 19
Көзләр якты быел 21
Гел синең белән 23
Туган илгә булган тугрылыкны 25
Аланнарда балан 27
*Мин Зөһрәсе жырның 28
*Кайчагында кеше сау чагында 29
*Сайланып кала чын дуслар 30
Яшь ана 31
Ә без... 32
Вакыт үзенекен эшли тора 33
Сөюмени 34
Туган җирем дә түгел 35
Унсигез 36
Елга ага 37
Еллар аркылы 39
Ач, шигърият, серләреңне 40
Кыр казлары 42

Хатлар язам 44
Умырзая шау чәчәктә 45
*Без мәҗүси түгел (Марс Шабаевка) 46
Дөньяга килде бер кеше 47
*Колачлап инләдем 48
Су буенда шәфәкъ алы 49
Чишмә 50
Эзләреңне саклый һәр буразна 51
Үкенмимен 53
*Караңгылар алай кара түгел 54
Кечкенә йорт бар тайгада 55
Бүген монда сәер бер тынлык 56
*Бер исә җил, бер тына 57
Ай юлы 58
Диңгез ярында 59
Поезд бара 61
Сынау 63
Галәмдә иң көчле-кеше хисе 67
Без йөргән юлларда 68
Бәйрәм вальсы 70

II - бүлек

Ни белән үлчәнә гомер

Жирдәшләр 73
*Актарылып, айкалыплар 75
Юлларга чыксаң 76

Машинада атлар 77
Иртәнге җилләрдә 79
Кыш үтмәгән әле 81
Күзләреңдә 82
Киек казлар китә 83
*Нәнәй истәлегенә 84
*Тиз кайт, әни диеп калса бала 86
*Куанасың сабый бала төсле 87
Җырчы дустыма 88
Хәерле сәфәрләр 90
Янә килдем Минзәләгә 93
Безнең яшьлек җырлары 95
Саубуллашу вальсы. 96
*Болыннарда сихри бер ямь 97
*Ак конвертта адрес — Казан 99
*Кичке шәфәкъ 100
*Көн эссе 101
*Чәчәкләр аланда 102
Җырланмаган җырлар (цикл) 103
*Хисләр болыты 127
*Чәчкә хисләреңне букет итеп 128
*Ah, ник түгел җилдәй җитез чагым? 129
Йөрәк җыры 130
Янгыр килә 131
Агым сулар 132
Чуерташ 133
Каен себерке 135
Кунакчыл... 136
*Су буйларын буйлыйм 137
Урсал тауда 138
*Кар суы гөрләп-шаулап акты 139
Ерак икәнен дә беләм 140

Нефтьчеләр маршы 141
Дан турында баллада 142
Юллар, уйлар (цикл) 148
Каз канаты 155
Серләремне сиңа сөйлим 156
*Җыр ишетеп чыктым басуларга 157
*Офык диңгезендә ак җилкәндәй 158
*Ни белән үлчәнә үткән гомер 159
*Тынгысыз башкайларымны 160
Сине сагынып, төн узганын көтәм 161
*Буйга җитеп, бәлигъ булгач бала 162
Асмалы күперләре 163
*Кипаислы Кырым 165
Севастополь 167
Дулкыннар 168
Мәхәббәт фонтаны 169
*Бу диңгезгә ташеп югалмыйсың 171
Таулар кичтем, диңгезләргә төштем 172
Гомер 173
*Жилме соң бу? 175
*Күпләр беләм, гомерен корбан итеп... 176

III - бүлек

Тормыш булмый көю-сөенүсез

Ак калалар 179
Иртән 180

Кич 182
Яшьлеккә хас 184
Кама буенда 185
Син әле тәмле йокыда 187
Тәнкыйтьче дуска 188
*Тешлеләре усал тешләделәр 189
*Мәхәббәт ышаныч түгел 190
Тамчы гөл 191
Масандра 192
*Идел өсте салкын көзге сыман 194
Синең янда әле берсе атлый 195
*Сөйләп сүзләр бетмәс сыман иде 196
Укытучы яшьлеге 197
*Горур жырлар читлекләрне вата 200
Туган жирем, эчкән суым! 201
*Ел әйләнә 203
*Балкыда да сүнде 205
*Бик бәхетле елмаюларыңны 206
*Тиз узар бу мизгел 207
*Кермим кеше биләмәләренә 208
*Юлларыма якта төшсен дипме... 209
*Тормыш булмый көю-сөенүсез 210
Авыл урамы 211
*Ялгышым дип уйласам да... 213
Уфа — минем яшьлегем 214
Иөгереп каршы чыксам 216
*Тагын узды кыңгыраулы язлар 217
*Мәхәббәтне тирән яшерәләр 218
*Ачкыч табып 219
*Үзем сөяр идем 220
Каен 221
Марина Цветаевага 222

*Әй, солдатлар 224
Мәкер 225
*Матурлар — батырлар 227
*Сузган юллар аккан сулар белән... 228
*Әйләнәм дә киләм яр буена 229
*Бөтерелә, бөтерелә карлар 230
Этюд 231
*Кем әйтә сәю ләззәт дип? 232

IV бүлек

Ымсынган да, очынган да чаклар...

*Имеш, йомшакмын да мин, бик юашмын... 235
*Үз йолдызым бәхетемә 236
Син якты булсаң, киләчәк 237
*Килешле кара күлмәгең 238
Бер генә гомер аз икән 239
Безнең якта 241
*Бергә чакта каен утын яктык 242
Улыма 243
*Ераста чакта — йөрәктә 244
*Киттең. Юлларда бозлавык 245
Кичүләр юк икән язларда 246
Төш 247
Илһам 248
*Артта - жиңүле юл... 249
Киләчәгең килә үткәннәрдән 250
*Кага да кага бу йөрәк 253
Яз килә 254

Язгы күкнең йөзе кояшлы 255
И кызлар, и хатыннар 256
*Даулы еллар күкрәп, шаулап узды. 257
Учак 258
Жир әйләнә 259
Чәчләреңне җилләр тарый 261
Чаңгыда 262
*Яшьлек, гомерең кыска — ашык! 264
*Чикләүләр, читләтүләре! 265
*Китәрмен дә, үтәр, бетәр, димсең? 266
*Киткәннәрнең юллары озын 267
Хәсән Туфанга 268
*Түбәннәнме, өстәнме бу аваз 270
Янган — тау 271
Бәби туенда (шаяру) 272
*Күңел серен аңа күпләр ачты. 273
*Телим сина яшел җәйләр 274
Салават Һәйкәле 275
Шигърият язы белән 277
Жырчыларның зәңгәр күгенә 279
*Тагын язлар килде, ярсу язлар! 281
*Ымсынган да, очынган да чаклар 282
Бәйрәм киченде 283
Ирек 284

V - бүлек

Үз йолдызым

Жисми дөнья 289
Себердән 291

Тиз генә онытмале 293
Кызыл каурыйлар 296
Йортына иминлек, кардәш! 298
Чүлдә 300
Егетләр китә солдатка 301
Озатканда 303
*Җәйдән бүләк алып, көз бизәнде 304
*Эңгәр төшеп килгән кышкы көннең 305
*Сыкылы - бәсле кыш иде 307
*Син әле яшь тал сыман зифа, сылу 309
Бүтән мәхәббәт 310
*Сулар ага, күлләр күккә бага 312
Ир — егеткә 313
Таякка мәдхия 315
Печән өсте 317
*И акыл өйрәтәләр 318
*Башмакларга гына кагылдың син 319
Март 320
*Беркем гөлләр өмет итми иде 321
*Бергә булган көннәрен сөйлиләр 323
Йөрәгемә язлар ярсу салды 324
*И туган авылым яңгыры 325
*Ардык, димсең 326
*Йокы качты 328
Кайный, шаулый Казан урамнары 330
Әлмәт 332
*Аланнарның иркенлеген тоеп 334
Шагыйрә 336
Табылдык хат 337
*Хисләреңне салып дулкыннарга 338
*Утлар йорттым 339
*Бер юлыңны илдә яңгыратырга 340

*Өр-яңа тотка куйганнар (Бер гыйбарәт) 341
Ил чикләре 343
Җәлил 344
Соңгы патрон 345
Эндәшү 348
Көнләшү 350
Кемне көтә, кемне чакыра... 352
Бәхеткәме? 354
*Сынаулар үттен, сынатма 356
*Табигать... 357
*Тәрәзәгә үрли ак муеллар 359
*Озак көттек энже бөртекләрен 360
*Иңнәренә баскан дәрәҗәнең 360
*Табигатьтән бар бәндәләр тигез 361
*Кабаланып килеп життең дә бит 362
Яшьлек урамы 363
Бер эретеп, бер суытып 364

VI - бүлек

Сатылмаска

Әлмәтем-мәхәббәтем 367
Кар ява 369
*Март бураны 371
Айлыбикә... 372
Казан, күнелем һәйкәлләре иле 373
Нидер яна 375
Сүз 377
Жиргә күчә 379

*Бөреләнә, караладыр 381
Арулардан арынып 383
Әкиятле үсмер чактан чыккач... 385
Сатылмаска 387
*Үрләр күркен 390
*Сагынуштык, әнкәй, зар-интизар 392
Яр-Чаллы 394
Замананың кайнар сулышы 396
*Манаралар, корыч манаралар 398
Бәйрәм көнне 399
Соравыңа җавап 400
Хирург 402
*Булдыралмаса юл басып 404
*Үткәннәр бездән корбан сорамый 405
Бүреләр 406
*Атлан атларга 409
Идел-Кама 411
Сузган ике кулым (поэма) 415
Ә күк зәңгәр 424
Пляжда 425
Җирем — зәңгәр Ватан 426
Казан вальсы 428
Чал карчыга 430
*Кыелып кергән ике тау арасы 433
Диңгезче язы (җыр) 434
*Сөңге тау очында кем яшәсен 436
Тулган айга тиңләп 438
Диләр... 440
Икмәк 441
*Яр читләре киртләч-киртләч 444
Ана белән бала 446
Бер хатирә 447

*Беләм инде 448
Сау бул, язым! 449
*Комсызга — ком (Мәкәррәмәгә) 451
*Сүз белән ышандыру да 452
*Тынгысыз уйларым белән 453
Уйламагыз, кызлар 454
Туй жыры 456
Боз акканда, атлар чапканда 457
*Диңгез аръягыннан килгән шаһның 459
Гамил Афзалга 461
Шамил Бикчуринга 462
*Жил исте дә, очтың, яфрак атлы 464
*Тау тарта мине, тау тарта 465
Сабыр канатлары 466
Елмаю (Ләбибәгә) 468
*Жил иркендә сине күрдем 469
Жил дә үтмәс (Жыр) 470
Ерак Көнчыгыш... 471
*Без дуслармы, әллә таныш кына? 472
*Фәлән вакыт гомерең калган, диеп 473
*Кешеләрдә этлек табыр 474
*Кеше күнеле яктырадыр 475
Кәккүк 476
*Шул ук апрель 478
Төшен — төшкә 479
Сер алдым 481

Утта янмаган ялкын...

(С.Сөләйманова турында каләмдәшләре). 485

Сажидә Сөләйманова

Тормыш, исәнме!

Редактор издания Э.Маликов. Составители: А.Маликов, А.Маликова. Ответственный редактор И.Хайруллина. Литературный консультант Г.Гильманов. Оформление Ш.Насыров. Компьютерная верстка В.Порсев. Компьютерный набор И.Миннахметов. Формат 70x100 1/32. Бумага офсетная. Гарнитура Таймс. Печать офсетная. Печатных листов 16. Тираж 3000 экз. Зак. Я-547

Отпечатано в типографии Татарского газетно-журнального издательства. 420066, г.Казань, ул.Декабристов, 2.